А. Г. ЯХИН

Әдәбият



4

Беренче кисәк

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

Әдәбият А. Г. ЯХИН 4

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар телендә
башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
4 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан рөхсәт ителгән

КАЗАН · ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ · 2011

УДК 373.167.1:821.512.145*04
ББК 84(2Рос=Тат) я71
Я89

Рәссамы *Рәисә Сәйфуллина*

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Шартлы билгеләр:

?! — сораулар һәм биремнәр;

— иҗади эш.

Яхин, А. Г.

Я89 Әдәбият : татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 4 нче с-фы өчен д-лек : ике кисәктә : беренче кисәк / А. Г. Яхин.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.— 159 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02046-6

УДК 373.167.1:821.512.145*04
ББК 84(2Рос=Тат) я71

ISBN 978-5-298-02046-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2011

Иң югары сыйныф.

Сез, хөрмәтле укучылар, башлангыч мәктәпнең иң югары сыйныфына күчтегез. Бишенче, алтынчы... хәтта унынчы, унберенчедә укучылар да: «Без башлангыч мәктәпнең иң югары сыйныфында белем алабыз»,— дип горурлана алмыйлар.

Аннан соң сез бик хаклы рәвештә: «Мин менә шушы мәктәптә укыйм!» — дип горурлана аласыз. Сезнең мәктәп укучыларыннан башка, дөньядагы бер генә бала да: «Мин дә шул мәктәптә укыйм!» — дип әйтә алмый бит.

Башкалардан шундый зур өстенлеге булган укучыдан ялкаулык әллә кайчан куркып качкан, әлбәттә. Ә мактану сезне ерактан урап үтә дип уйларга кирәк. Иң югары сыйныфта укучы бала мактана димени!

Мактанмый торган бала — үзенә тәнкыйть күзе белән карый торган бала ул. Сез, билгеле, үзегезгә үзегез берсеннән-берсе файдалырак сораулар биреп торасыз. Мәсәлән: «Мин кеше алдында кыланып сөйләшмимме? Урынсыз шаркылдап көлмимме? Авыр сүз әйтеп, дусларымны рәнҗетмимме? Юкка-барга да үпкәләмимме?» — дип сорыйсыз. «Их, булгалый шул. Уйламыйча әйткән сүзләр дә, кыланган чаклар да була... Шул гадәтләрдән ничек котылырга инде?..» — дип борчыласыз. Котылу чарасын да яхшы беләсез:

«Уйларга өйрәнгән бала кылана белми»,— дисез дә тынычланасыз. Һөнәрне зиһен өйрәтә, дигәннәр безнең борынгы бабайлар. Шундый зур фикерне өч кенә сүзле мәкаль эченә сыйдырганнар. Һөнәр һөнәр инде ул. Оста кеше теләсә нинди эшне үзе дә башкарып чыга ала, нигә аңа зиһен, диярсез. Сүзегезне кычкырып әйтә күрмәгез. Зиһен ишетсә рәнҗер. Ул бит сезнең иң якын дустыгыз — һәрвакыт ярдәм кулы сузучы уегыз, белемегез.

Әнә бит ничек зурлаганнар зиһенне безнең борынгы бабайлар: һөнәр хәтле һөнәрне өйрәтә дигәннәр. Һөнәр иясе, эшкә тотынганчы, иң элек эшнең тәртибен, барлык гамәлләрен зиһене ярдәме белән күз алдына китерә. Зиһене аңа ни эшләргә кирәклеген әйтеп тора, ялгышын шунда ук төзәтергә куша. Ә иң мөһиме, зиһен, ягъни **уйлау**, һөнәр иясен иҗат итәргә өйрәтә. Шуңа күрә уй белән һөнәрне җан дуслар дип йөртәләр дә.

Борынгы бабайлар әлеге мәкальләре белән безне: «Уй билгесезне билгеле итә, башкача әйтсәк, теләсә нинди мәсьәләне чишә. Уйламыйча эшләсәгез, хур булуыгызны көтегез дә торыгыз. Уйсыз-зиһенсез һөнәр була алмаган кебек, һөнәрсез уй-зиһен дә буш хыялга әйләнә»,— дип кисәткәннәр.

Уйны ничек һөнәрнең якын дусты итәргә? Моның өчен башта уйның үзен эшкә өйрәтергә кирәк әле. Ялкау булмасагыз, зиһенегезне уятырга иренмәсәгез — әдәбият дәресләрен уегыз бик яратып тыңлаячак. Әсәр — язучының зиһен җимеше бит. Әсәргә анализ ясаганда, сезнең зиһенегез язучы зиһене белән шунда

ук уртак тел табачак. Иншалар язганда, хыял, фикер бүләк итәчәк. Уйлап табу — чиксез шатлык, бәхет ул. Әдәбият дәресләрендә баеган зиһен сезне бәхетле итәчәк.

«Менә нинди могҗизалар эшли ала зиһен»,— дигәннәр мәкаль теле белән борынгы бабайларыбыз. Әнә күпме акыллы киңәшләрен кып-кыска мәкальләре эченә сыйдырганнар. Шактый озын эчтәлекне кыска итеп әйтә алу да — һөнәрнең бер төре. Әле нинди генә — иҗат итү һөнәре ул! Бабайларны иҗат итәргә зиһеннәре өйрәткән, әлбәттә. Чөнки алар искиткеч тырыш булганнар.

Иң элек булды гыйлем, соңыннан эш,
Бик түбән булды гыйлемсез кылган эш.

«Белемсез кешенең эше эш түгел»,— дип яза шагыйрь Утыз Имәни. Беләсезме нәрсә ул белем? Эчтәлеге «белү» бит аның. Ә белү,— ятлап, күп нәрсәне хәтердә калдыру түгел, нәрсәне булса да **эшли алу** ул. Башкача әйтсәк, **эшләргә күнегү.**

Кулыгыздагы дәреслек сезне дөньядагы иң зур байлыкка — уйларга өйрәтә. Уегызны эшкә җигегез. Эзләнсен дә эзләнсен. Уегызга ирек бирсәгезме? Эшләүнең тәмен белеп алган уегыз дәреслектәге сорауларның һәркайсына берне түгел, ике-өч җавап табачак. Сезгә шуларның үзегезгә ошаганын сайлап, дәфтәргә язып кую эше генә калачак.

Быел хәтерегезне дә сынарсыз. Былтыр сез әсәргә анализ алымнары белән таныша башладыгыз.

Быел шул алымнарны файдаланырга күнегерсез. Анализның башка алымнары белән дә танышырсыз.

Нәрсә соң ул анализ? Әсәргә анализ ясау — уйлау бит ул. «Нәрсә турында? Тагын нәрсә турында?» дип, әсәрне өлешләргә бүлдегез, шул рәвешле, әсәрне өйрәндегез. Әсәр эчтәлеген табарга өйрәнгән укучы китапны укырга кирәк булган өчен генә укымый. Китап аның дустына, киңәшчесенә һәм укытучысына әйләнә.

Бу уку елында да дәресләр узган елда өйрәнгәннәрне искә төшерүдән башлана. Ни өчен үткәнне кабатлыйбыз? Бик мөһим сорау. Сезгә узган елларда өйрәнгән уйлау, анализ ясау алымнары дәрес саен диярлек ел да кирәк булачак.

Уйларга күнегү әдәбият дәресләре өчен генә түгел, башка фәннәрне өйрәнгәндә дә, тормышта да, иң мөһиме, үзегезгә үзегез акыллы кеше булып бәя бирү өчен дә кирәк.

Автор.

Беренче—өченче сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерик.

Сез беренче, икенче, өченче сыйныфларда аңлап, тиз һәм дөрес укырга өйрәндегез. Җәйге каникул озын бит ул. Рәхәтләнеп уйнадыгыз, су коендыгыз, урманнарга бардыгыз, әти-әниегезгә өй эшләрендә ярдәм иттегез... Билгеле инде, матур-матур әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр укыгансыздыр. Шунсыз ял әйбәт буламыни! Йә, кайсыгыз әйбәт ял итте? Иң дөрес сөйләүче кеше турындагы әсәрне укып, осталыгыгызны күрсәтегез әле...

Зур борынлы кечкенә генә карт башыннан кичкән искиткеч маҗаралар турында сөйли. Аны тыңлаган кешеләр эчләре катып көләләр.

— Син сөйләгән нәрсәләрнең һич булуы мөмкин түгел! — диләр.

Карт эре генә әйтеп куя:

— Кайчандыр дусларым мине дөньяда иң дөрес сөйләүче кеше дип йөртәләр иде,— ди...

Сез, хөрмәтле укучылар, курку белмәс, акыллы һәм гел дөресен генә сөйләүче Мюнхгаузенны, әлбәттә, яхшы беләсез. Аның үрдәк аягына тотынып очуын да, арыслан белән крокодилны җиңүен дә, агач башларыннан чабып йөрүен дә үз күзләрегез белән

күрдегез. Ул сөйләгәннәрне Рудольф Эрих Распе исемле немец әдибе язып алган. Шуннан соң ул язмалар китап булып дөньяның барлык илләрендә диярлек басылып чыккан. Мюнхгаузенның башыннан үткәннәре — бик гыйбрәтле һәм дөрес вакыйгалар. Дөрес, чөнки Мюнхгаузен үзе сөйли бит аларны. Ә ул үзе «мин бервакытта да ялганламыйм» ди.

ЯРТЫ АТ.

Шулай бервакыт, каты сугыштан соң, төрекләрнең зур крепостен яулап алдык. Мин крепостька беренче булып бәреп кердем һәм, төрекләрне пыран-заран

китереп, ярсыган атыма су эчертергә кое янына тукталдым. Атым эчә дә эчә, һич кенә дә туймый. Ике-өч сәгать узды, ә ул һаман коедан аерыла алмый. Гаҗәпкә калдым. Нинди тамаша бу?!

Артымда су шаулаган тавышка борылып карасам, чак кына иярдән егылып төшмәдем.

Атымның арт саны өзелгән, һәм ул эчкән бөтен су арттан агып төшә икән. Шул судан тирән күл хасил булган. Исләрем-акылларым китте. Тамаша!

Шунда бер солдатым йөгереп килде дә бу табышмакны аңлатып бирде.

Мин дошманнарны эзәрлекләп крепостька бәреп кергән чакта, төрекләр, капканы шапылдатып ябып, атымның яртысын өзеп калдырганнар. Пычак белән кисәннәр диярсең! Атның өзелеп калган яртысы бераз капка янында йөргән, тояклары белән тибенеп, төрекләрне куган, аннары якындагы болынга чапкан.

— Ул әле дә шунда утлап йөри,— ди солдатым.

— Утлап йөри? Булмас ла!

— Үзегез барып карагыз.

Атымның алгы санына атланып, болын ягына чаптым. Чыннан да... Атның яртысы тыныч кына яшел чирәм утлап йөри.

Шунда ук хәрби врачны чакырттым. Ул озак уйлап тормады: атымның ике яртысын бергә кушып, нечкә талчыбык белән тегеп тә куйды. Нишләп талчыбык белән дисәгез, янында җебе юк иде.

Ялганган алгы һәм арткы саннар бик тиз беректе, ә талчыбыклар атымның тәненә тамыр җибәрде.

Бер айдан ияреем турысында талдан менә дигән чатыр ясалды.

Шул уңайлы чатыр эчендә утырган килеш, мин искиткеч батырлыклар күрсәттем.

Эрих Распе.

?! **1.** Хикәядәге вакыйганы үз сүзләрегез белән сөйләп күрсәтегез.

Мюнхгаузен бу вакыйганы да үз башымнан кичте, үз күзләрем белән күрдем дип ышандыра. Сез, әлбәттә, ышанып бетмисез, икеләнәсез, чөнки беркайчан да мондый хәлне күргәнегез булмады. Ләкин Мюнхгаузен бу хәлне Төркиядә булды дип аңлата. Ә сезнең Төркияне күргәнегез юк. Кем белә, бәлки, Төркиядә андый хәлнең булуы да мөмкиндер. Шулай булгач, сезнең батыр сугышчы сүзен шик астына алырлык дәлилегез бармы соң?

?! **2.** Хикәянең «Ядрәгә атланып» дигән бүлеген өегездә укып килегез.

ЯДРӘГӘ АТЛАНЫП.

Сүз уңаенда әйтим: сугыш вакытында миңа атка гына түгел, ядрәгә атланып та йөрергә туры килгәләде.

Шулай без төрекләрнең ниндидер шәһәрен камап тора идек. Командирыбыз ул шәһәрдә ничә туп барын белергә теләде.

Ләкин бөтен армиядә дошман лагерена үтеп керергә йөрәге җитәрдәй солдат табылмады.

Мин барысыннан да батыррак булып чыктым.

Төрек шәһәренә төзәп ата торган галәмәт зур туп янына барып бастым да, көпшәсеннән ядрә атылып чыгуга, шуңа атланып, алга очтым. Сугышчылар беравыздан:

— Афәрин, афәрин, барон Мюнхгаузен! — дип кычкырып калдылар.

Башта бик күңелле бардым, әмма, еракта дошман шәһәре күренүгә, күңелгә шом төште.

«Һм! — дидем үз-үземә.— Шәһәргә керүен керерсең, әмма кире чыга алырсыңмы? Дошманнар синең белән күп сөйләшеп тормаслар, тотарлар да, шымчы дип, дарга асып куярлар. Юк, Мюнхгаузен дус, сиңа тизрәк кире кайтырга кирәк!»

Минем турыдан төрекләрнең безгә аткан ядрәсе узып бара иде, озак уйлап тормастан, шуңа күчеп утырдым да, берни булмагандай, кирегә очтым.

Әлбәттә, очып барышлый, дошман тупларын берәмләп санап чыктым һәм командирыма төп-төгәл мәгълүматлар алып кайттым.

Эрих Распе.

?! Авторның табышын, ягъни әкиятнең иң мөһим урынын әйтегез.

ГАДӘТ.

Бер эшкә тотынсам,
Җиде кат тирлим мин,
Бетмичә, үземә
Тынгылык бирмим мин.

Маңгайдан шыбырдап,
Әйдә, дим, тир аксын,
Тик эшем эш булсын,
Кешеләр яратсын.

Соңыннан кемнәрдер
Тиргәрлек булмасын,
Кызарып, оялып
Тирләрлек булмасын.

Фәнис Яруллин.

?! **1.** Шигырьдәге балага бәя бирегез. Аның кимчелеге бармы?

2. Шигырьне ике өлешкә бүлү өчен, кабатланган вакыйганы табарга кирәк. Табып бүлегез.

3. Шигырь герое кебек тирли-тирли, сезнең дә эшләгәнегез бар, әлбәттә. Шул эшегез турында языгыз.

Хис темасын искә төшерик.

ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ.

* * *

Без барасы илләргә,
Бодай чәчкән җирләргә;
Бодай түгел, алтын булсын —
Җитми туган илләргә.

* * *

Биек тә генә биек өйләрдән
Төтене үк чыгар кыл кебек;
Туган да илем исемә төшсә,
Бер төннәре була ел кебек.

* * *

Агыйделләр аша уклар аттым,
Аткан укларымны югалттым;
Туган илләремә очар идем,
Булса әгәр ике канатым.

?! 1. Дүртьюллыкларның өчесе дә лирик геройның хисе турында. Нинди хисе турында?

2. Беренче дүртьюллыкны дәрестә ятлагыз.

МӘКТӘПТӘН КАЙТЫП КИЛӘМ.

Мәктәптән кайтып киләм,
Сумкам тулы «биш»леләр.
Мине алга сөйриләр —
«Биш»леләр бик көчлеләр.

«Саумысез!» — дим һәркемгә.
Их, дөньялар иркен лә!
Әллә кая ашкынам,
Урамнар кояш кына.

Сумкам арытмый кулны,
Мәче дә кисми юлны,
Этләр дә чыкмый өреп,
Минем кайтканны күреп.

Кайтып барам ялгызым,
Ерык минем авызым.
Чыдап булмый, чын менә,
«Биш»леләрем көлдерә.

Фәнис Яруллин.

?! «Биш»ле алган бала «мин бик шатланам» дими. Ләкин шатлана. Ничек шатлана?

Әсәрне катнашучыларга бүлик.

Искә төшерик. Әсәрдә катнашучыларга **персонажлар** диләр.

Әсәрдә кош-корт, хайван-җәнлекләр катнашуын әйткән дә юк. Анда хәтта җансыз предметлар да кеше рәтенә кереп йөриләр. Шуңа күрә алар да — персонажлар.

«Ат тешеннән билгеле, кеше эшеннән билгеле» мәкалендә ат та, кеше дә — персонажлар. Мәкальне бүлү өчен, «Нәрсә турында?» дип, сорау бирдек. Җавап тиз табылды: «Ат һәм кеше турында»,— дидек.

«Ике өлеш арасында нинди бәйләнеш бар?» соравына җавап бирү өчен, аз гына уйларга кирәк булды. Болай уйладык: безгә башта беренче өлешне, аннан соң икенчесен өйрәнергә кирәк, дидек.

Беренче өлештә атның бер сыйфаты әйтелә. Теше таза булса, димәк, ат әле яшь, көчле. Начар булса — карт, көчсез. Теше таза атның бәясе дә кыйммәт. Әнә атның нинди әһәмиятле сыйфаты күрсәтелгән мәкальдә.

?! Икенче өлештә дә кешенең бер генә сыйфаты әйтелә: эшеннән билгеле, диелә. Эшеннән нәрсә билгеле? Мәгънәсен үзегез әйтегез.

Ике өлеш арасындагы бәйләнеш табылды. Ул **охшашлык** булып чыкты. Өлешләрне бәйләп әйтик: атның ниндилеген тешенә карап белеп булган кебек, кешенең ниндилеген эшенә карап белеп була.

* Чебен, дулап, тәрәзә ватмый.

* Иске яңаны саклый.

?! Мәкальләрне ике өлешкә бүлегез.

ЮЛДАШЫМ.

Кояш көйдергән көннәрдә
Күңел эзли күләгә.
Урманнары юлга чыга,
«Яндым инде» дигәндә.

Мөдәррис Әгъләмов.

?! Шигырьдә катнашучылар ничәү?

«Бу шигырьдә автор кайда?» соравына болай җавап бирергә кирәк: без, күнеккәнчә, *кояш бик кыздыра, күләгә эзләп, урманга керәбез,* дияр идек. Ләкин автор шул ук вакыйганы башкача әйтә.

Гадәти вакыйганы киресенә әйләндерүче кем? Әлбәттә, автор. «Минем табышымны күрдеңме?» — ди ул.

УЛ ДУЛКЫННАР.

Туган якта күреним генә үрдән,
Шатлыгыннан арыш ду кубар,
Сөенчегә бүләк өмет итеп,
Кырлар буйлап йөгерер дулкыннар.

Сибгат Хәким.

?! 1. Шигырьдә катнашучылар ничәү?
2. Шигырьдән авторны табыгыз.

КЕМ ЯХШЫ?

Безнең бабайларның бабайлары яшәгән вакытта Хуҗа Насретдин исемле җор телле бер карт булган. Аны, яратып, Хуҗа дип кенә йөрткәннәр. Беркөнне Хуҗадан:

— Күршеләрең белән тату торасыңмы? — дип со-раганнар.

— Бик тату торам,— дигән Хуҗа.

— Күршеләрең яхшылар, ахры? — дигән сораула-рына каршы Хуҗа:

— Мин үзем бик яхшы кеше,— дип җавап биргән.

?! Мәзәктә сорау бирүчеләр дә катнаша. Ләкин алар төп кат-нашучылар түгел. Төп катнашучылар — Хуҗа Насретдин белән күршеләре. Шуңа күрә мәзәкнең беренче өлеше мондый: Хуҗа күршеләре белән яхшы тора, чөнки күршеләре яхшы. Икенче өлеше беренчесенең капма-каршысы булырга тиеш. Икенче өлешен әйтегез.

БАЛАНЫҢ АТА-АНАСЫН СӨЮЕ.

Ун яшьлек бала Шәмсетдин, үз авылларында бер бай кешегә барып, үзенә хезмәт сорады.

Бай кеше моны хезмәткә алырга риза булды вә әйтте: «Ярар, мин сине хезмәткә алырмын, көтү көтәрсең һәм, әгәр син яхшы эшләсәң, аена алты тәңкә хезмәт хакы куярмын».

Шәмсетдин моңа каршы: «Кулымнан килгән хезмәтне кызганмам, ләкин минем айлык бәһамне һәр атна саен бүлеп бирерсең. Чөнки өебездә әткәем авырып ятканлыктан эшли алмый. Шул сәбәптән һәр атна саен аңар ризыкланырлык акча алып кайтып бирәсем килә»,— диде.

Бай кешегә сабый бала Шәмсетдиннең атасына бу кадәр саф мәхәббәт кыйлуы бик ошады. Ул, Шәмсетдиннең сүзенә «баш өсте» дип разый булуы өстенә, аның айлык бәһасен дә арттырды.

Габдулла Тукай.

?! **1.** Әсәрне укып чыгыгыз. Китабыгызны ябыгыз да мөмкин кадәр тулы итеп сөйләгез.

2. Ике өлешкә бүлегез.

3. *Бай кешегә сабый бала Шәмсетдиннең атасына бу кадәр саф мәхәббәт кыйлуы бик ошады* җөмләсен биш кенә сүзгә калдырып кыскартыгыз.

ИЛГӘ СӘЛАМ.

Килмә лә, җил, исмә лә, җил,
Тәрәзәдән кит әле:
Күңелләрем өйдә түгел,
Туган илдә бит әле.

Кайда гына яшәсәм дә
Түгәрәк Җир шарында,
Күңелкәем — күбәләгем —
Туган үскән ягымда.

Һавалардан очкан кошлар
Җиргә аваз салганда,
Ул авазны юра, илем,
Без тапшырган сәламгә.

Хәсән Туфан.

?! 1. Шигырьне ике өлешкә бүлү өчен, охшаш дүртьюллыкларны кушып, уртак исем бирергә кирәк. Шул эшне башкарыгыз.

2. Баштагы ике дүртьюллыкны үз сүзләрегез белән сөйләсәгез, автор катнашкан күренешне табасыз. Шул күренештә авторны табыгыз.

3. Лирик герой хисен ачыклап әйтегез. Хәсрәт, шатлык, үкенү, борчылу да түгел — нинди хис?

КӨНГӘ КҮРЕНМӘС СЫЛУ-КӨМЕШ.

Бездән ерак бер шәһәрдә бик ярлы бер карчык булган, ди. Аның бер генә баласы булган, ди. Карчыкның улы кечкенәдән үк җәядән ук атарга ярата торган булган, ди. Унбиш-уналты яшьләренә җиткәч, бу егет кырларга чыгып, урманнарга барып, кош-корт атып кайта икән дә, ди, болар шуның белән алай-болай итеп, көннәрен авыштырып баралар икән, ди.

Көннәрдән бер көнне карчыкның улы кулына җәясен-угын алган да, ди, иртүк торып, патша сарае тирәсендәге күл янына берәр кош очрамасмы дип чыгып киткән, ди.



Егет күл янына барып, җәясен җайлап утырган чагында, бер энҗеле үрдәк пыр итеп очып чыккан да, ди, егетнең баш түбәсе турыннан үтеп барганда, егет моны атып төшергән, ди.

Егет үрдәкне алган да патшага бүләк иткән. Патша бу егеткә, энҗеле үрдәк китергәне өчен, бик күп акча биреп чыгарган, ди.

Менә берзаманны патшаның якын вәзирләре, теге карчыкның улыннан көнләшеп, үзара киңәшләшкәннәр дә патшага:

— Энҗеле үрдәктән бүрегең булды, тагын энҗеле тәкәдән туның да булса, бигрәк тә яхшы булыр иде,—

дигәннәр.— Аны әнә теге энҗеле үрдәк китергән егет табып алып кайтырга тиеш,— дип тә өстәгәннәр, ди.

Патша, шул көнне үк теге карчыкның улын сараена чакыртып:

— Син миңа энҗеле үрдәк табып китерә алган идең, инде хәзер энҗеле тәкә дә табып китерергә тиешсең. Әгәр шул энҗеле тәкәне табып кайтмасаң, мин синең башыңны кистерермен! — дип әйтте, ди.

Егет патшаның нинди эш кушканын анасына әйтеп биргәч, анасы әйтә моңа:

— Улым, бер дә кайгырма. Җәяң белән укларыңны ал да юлга чык, безгә боерганы булыр,— ди.

Шуннан соң бу егет, патша казнасыннан бирелгән акчага бер ат алып, юлга чыгып китә.

Ай бара, ел бара бу, бара торгач, караңгы бер урманга барып керә. Урман эчендә кечкенә генә бер өй күрә. Өй эчендә ап-ак чәчле, тешләре төшеп беткән бөкре бер карчык утыра икән, ди. Килеп керү белән, егет бу карчыктан исәнлек-саулык сорашкан да, ди, үзенең башына төшкән эшне сөйләп биргән. Шуннан соң бу егеткә карчык:

— Улым, бүген син миндә кунак бул, син сораган нәрсәне мин белмим, аны минем тутам белсә белер, иртәгә шуның янына барырсың, ул моннан бик ерак түгел, — ди. Егет, иртәгесен йокыдан торып ашап эчкәч, карчыкка бик күп рәхмәтләр әйтеп, атына атланып, юлга чыгып китә.

Теге карчык өйрәткән юл белән көн бара, төн бара бу. Ай бара, ел бара, бара торгач...

?! 1. Әкиятне дәвам итегез.

Китәр алдыннан, икенче карчык әйтә моңа:

— Менә, улым, ди, моннан ерак түгел бер җирдә минем бер тутам бар, ди, аның җир-суы, урман-болыны киң, кош-кортлары, мал-туарлары бик күп. Сиңа кирәкле энҗеле тәкә шуның көтүләрендә булмый калмас,— ди.

Егет карчыкка бик күп рәхмәтләр әйтеп, юлга чыгып китә. Көн бара, төн бара бу. Бара торгач, барып җитә ямь-яшел болынлыкка. Шул болында йөргән көтүләр янына барып, теге карчык өйрәтүе буенча, бер энҗеле тәкәне тотып ала да ат өстенә салып кайтып китә. Атна кайта, ай кайта бу. Үзе торган шәһәргә керү белән, теге энҗеле тәкәне патша әйткән көнгә алып кайтып тапшыра. Патша бу егеткә төрле-төрле бүләкләр биреп, өенә кайтарып җибәрә. Патшаның вәзирләре үзара яшерен киңәш итәләр: «Бу егетне юк итмәсәк, тора-бара патша аны бездән артык күрер»,— диләр. Шуннан соң патшага әйтәләр:

— Әй безнең данлыклы патшабыз, менә синең энҗеле үрдәктән бүрегең, энҗеле тәкә тиресеннән теккән туның булды. Инде сиңа көнгә күренмәс Сылу-Көмеш кирәк. Шул да булса, тирә-як патшалары арасында синең даның тагын ун өлеш, йөз өлеш артачак,— дигәннәр.

Шуннан соң патша, бик уйга калып, вәзирләрдән:

— Ул нәрсә соң? Аны каян, кем табар? — дип сораган, ди. Вәзирләр:

— Әй бөек патшабыз, аның нәрсә икәнен табылгач кына белә алырсыз, аны теге карчыкның улы табып китерсә китерә алыр, башка кеше булдыра

алмас,— диләр. Патша теге карчыкның улын чакыртып ала да әйтә...

?! **2.** Патша егеткә нәрсә ди? Аннан соң егет нишли?

Егет, анасы карчык белән саубуллашып, көнгә күренмәс Сылу-Көмешне эзләргә чыгып китә.

Атна китә, ай китә бу. Бара-бара... теге беренче карчыкка барып җитә.

Аның янына кереп, үзенең кайгысын сөйли. Теге карчык әйтә...

?! **3.** Әкиятне дәвам итегез.

Уртанчы тутасы егетне бик яхшылап каршы ала, ашата, эчертә. Егет моңа да үз кайгысын сөйләп бирә.

— Әй улым,— ди карчык,— бер дә кайгырма, энҗеле тәкәне тапкан җирдә син көнгә күренмәс Сылу-Көмеш кызны да табарсың. Ул кыз әнә шул энҗеле тәкәләр хуҗасының — безнең иң карт, иң бай тутабызның сараенда, җиде кат капка, җиде кат ишек, җиде кат стена, җиде кат түшәм, җиде кат түбә, җиде кат идән, җиде кат тәрәзә эчендә көнгә-айга күрсәтелмичә утыра. Капка каравылчыларына кием-салым бирерсең, үгез алдындагы сөякне эт алдына, эт алдындагы печәнне үгез алдына салырсың. Капкалар, ишекләр ачылыр, кап-караңгы җиде төн уртасында көнгә күренмәс Сылу-Көмешне алырсың да юлга чыгарсың,— ди.

Бу сүзләрне ишеткәч, егет бик шатланып, карчыкка бик күп рәхмәтләр әйтеп, шул минутта ук юлга

чыгып китә, ди. Көн китә, төн китә, бара-бара җиде төн уртасында әлеге бай карчыкның сараена барып җитә. Капка каравылчыларына кием-салым биреп, үгез алдындагы сөякне эт алдына, эт алдындагы печәнне үгез алдына алып салуы була, капкалар, ишекләр ачыла да китә.

Егет, сарай эченә кереп, көнгә күренмәс Сылу-Көмешне күрү белән, исеннән-акылыннан китә яза, ди. Алай да үзен нык тотып, шул минут эчендә көнгә күренмәс Сылу-Көмешне күтәреп алып чыга да атына атланып, кызны үзе белән алып китә.

Карчык иртә белән торып чыкса, Сылу-Көмеш торган йортның ишекләре ачык, кыздан җилләр искән. Каравылчылар өр-яңа киемнәрдән йөриләр, эт рәхәтләнеп сөяк кимерә, үгез, мышный-мышный, печән ашый, капкалар, ишекләр ачык, ди. Карчык, ачуыннан нишләргә дә белмичә, чәчләрен йолкый-йолкый, каравылчыларга ташлана. Каравылчылар:

— Сиңа ничә ел хезмәт итеп, син безгә яңа кием алып бирмәдең. Безне өр-яңадан киендерүчегә без капкаларны, ишекләрне ачтык. Бездә гаеп юк, гаеп синең үзеңдә,— диләр. Шуннан соң карчык, эт янына барып, аны кыздыра башлады, ди. Шулвакыт эт, телгә килеп...

?! **4.** Әкиятне дәвам итегез.

Карчык, ачуыннан нишләргә дә белмичә, уртанчы сеңлесенә китә.

— Минем сараемда көнгә күренмәс Сылу-Көмеш барлыгын синнән башка беркем дә белми иде. Кемгә

сөйләдең, кем белән качырдың аны, әйт дөресен! — дип, аны кыздыра башлаган иде, ди, сеңлесе дә аңа:

— Кызма, кызма, тутам. Шулхәтле җирең-суың, малың-туарың була торып, гомерең буена син миңа бер шырпы да бирмәдең. Ә менә ул егет миңа бүләкләр биреп, рәхмәтләр әйтеп китте. Көнгә күренмәс Сылу-Көмешле дә булды. Синең белән алыш-бирешем юк, минем тирәмдә йөрмә,— ди.

Сеңлесеннән шул сүзләрне ишеткәч, карчык, нишләргә дә белмичә, сараена кайтып китә, ди.

Егет көнгә күренмәс Сылу-Көмеш белән, үзләренең шәһәренә кайтып җитеп, патша сараена барып керәләр. Патша, көнгә күренмәс Сылу-Көмешне күрү белән, исеннән-акылыннан китә язып, кызга гашыйк була. Шуннан соң, вәзирләрен чакырып, үзенең Сылу-Көмешкә өйләнәчәген әйтә. Моны ишетү белән, Сылу-Көмеш:

— Юк, син миңа тиң түгел. Мин бер ярлы кеше кызы идем. Кечкенә чагымда мине бер бай карчык, урлап алып китеп, айга-көнгә күрсәтмичә, шушы яшемә хәтле җиде капка, җиде кат стена эчендә асрады. Бәхетемә каршы, бу батыр егет, килеп чыгып, мине шул явыз карчык кулыннан коткарды. Ул мине, мин аны яратам, шуның өчен мин аңа булырга тиеш. Әгәр безгә каршы киләсез икән, менә бу батыр барыгызның башын чабып өзәр,— ди. Патша да, аның явыз вәзирләре дә егеттән куркуларыннан тәхетне ташлап чыгып китәләр. Егет шул илгә патша булып калып, болар матур гына гомер иткәннәр, ди.

Әкият укыр өчен кызык. Ул безне күз күрмәгән, колак ишетмәгән дөньяга алып керә. Без шул дөньяда яшәүче егет артыннан ияреп йөрибез. Ул кая барса, шунда барабыз. Ул ни күрсә, шуны күрәбез. Ул хәсрәтләнгәндә хәсрәтләнәбез, ул шатланганда шатланабыз. Үзебез дә сизмәстән, аңа ярдәм итеп йөрибез.

Әкиятләрне күптән, бик күптән безнең борынгы бабайларыбыз иҗат иткәннәр. Әгәр дә әкиятне кызык булганга гына укысалар, алар шушы көнгә хәтле сакланмас та иде. Димәк, әкиятләрдә борынгы бабайларыбызның безгә әйтәсе бик мөһим сүзләре бар.

?! **5.** Әлеге әкияттә борынгы бабайлар безгә нәрсә диләр?

а) Яхшылыкка яманлык белән җавап бирсәң, җәзасы озак көттермәс, диләр. Моны әкияттәге кем язмышыннан күреп була?

ә) Үзең яхшы булсаң, сиңа яхшылык эшләүчеләр дә күп булыр, диләр. Моңа мисал табыгыз.

ЭШ БЕТКӘЧ УЙНАРГА ЯРЫЙ.

Бик матур бер җәйге көн: өстәл янында бер Сабый
Ян тәрәзә каршысында иртәге дәрсен карый.

Чын күңел берлән укый ул, кат-кат әйтеп һәр сүзен;
Бик озак шунда утырды, бер дә алмастан күзен.

Шул чагында бу Сабыйны чакыра тышка Кояш:
«И Сабый, ди, әйдә тышка, ташла дәрсең, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман;
Чыкчы тышка, нинди якты, нинди шәп уйнар заман!»

Бу Кояшның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Тукта, сабрит[1], уйнамыйм, ди, уйнасам, дәрсем кала.

Көн озын ич, ул уенның мин һаман вактын табам,
Чыкмамын тышка уенга, булмыйча дәрсем тәмам».

Ул, шулай дип, кимчелек бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап ябышты дәрсенә.

[1] Сабрит — сабыр ит.

Өй түрендә шул заман сайрый ботакта Сандугач,
Ул да шул бер сүзне сайрый: «Әйдә тышка, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман,
Чыкчы тышка, нинди һәйбәт, нинди шәп уйнар заман!»

Сандугачка каршыга биргән җавабында Бала:
«Юк, сөекле Сандугачым, уйнасам, дәрсем кала.

Туктале, бетсен дәрес, ди, әйтмәсәң дә уйнарым,
Син дә сайрарсың матурлап, мин авазың тыңларым!»

Ул, шулай дип, һич зарар бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап кереште дәрсенә.

Шул вакытта өй түрендә бакчада бер Алмагач
Чакыра тышка Сабыйны: «Әйдә тышка, күңлең ач!

Бик күңелсездер сиңа эштә утырмак һәрвакыт,
Әйдә, чык син бакчага, җитте хәзер уйнар вакыт!»

Алмагачның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Юк, сөекле Алмагачым, уйнасам, дәрсем кала.

Тукта, сабрит аз гына, ди, и кадерле Алмагач,
Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куймагач».

Күп тә үтми, бу Бала куйды тәмамлап дәрсене,
Куйды бер читкә җыеп дәфтәр, китапны — барсыны.

Чыкты йөгреп бакчага: «Йә, кем чакырды, дип, мине?
Әйдә, кем уйный? Тәмам иттем хәзер мин дәрсеми!»

Шунда аңгар бик матурлап елмаеп көлде Кояш,
Шунда аңгар кып-кызыл зур алма бирде Алмагач;

Шунда аңгар шатланып сайрап җибәрде Сандугач,
Шунда аңгар баш иделәр бакчада һәрбер агач.

Габдулла Тукай.

?! 1. Шигырьдәге охшаш вакыйгаларны табыгыз. Сабыйны Кояш уйнарга чакыра... (Дәвам итегез.)

2. Охшаш вакыйгаларны кушып, исемнәр бирегез.

Габдулла Тукай шигырен тырыш Сабый турында язган. Сез андагы вакыйгаларның капма-каршысын языгыз.

ИКЕ САБАН.

Ике сабан[1], икесе бер үк тимердән, бер үк һөнәр йортында эшләнеп, базарга чыгарылганнар иде.

Боларның берсе иген игүчегә сатылып, ул аны алгач ук эшкә кушты. Аның белән җир сөрә башлады. Шул рәвешчә, бу сабан һәр җәйне эшләп, аңар тик ятарга туры килми иде.

Икенче сабан исә, бер сәүдәгәр кулына эләгеп, аның кибетендә ауналып, эшсез ята иде.

Шулай озак заманнар үткәч, бу ике сабан бер җирдә очраштылар.

Кибетчедәге сабан, күп еллар эшсез ятканлыктан, тәмам тутыгып, саргаеп, каралып беткән иде.

Иген игүчедәгесе исә күп эшләп ачылган һәм көзге шикелле ялтырап тора иде.

Тутыккан сабан, үзенең иптәшенең болай матурланганын күргәч, аннан: «Иптәш, син ни сәбәптән болай ялтырыйсың да, мин ни сәбәптән мондый тутыккан һәм каралган?»— дип сорады. Иптәше аңар: «Минем ялтыравым тырышуымнан килде. Әгәр гоме-

---

[1] Сабан — җир сукалый торган авыл хуҗалыгы коралы; сука.

рем буе кибет идәнендә кырын ятып торсам, мин дә синең төсле каралыр һәм ямьсезләнер идем»,— дип җавап бирде.

Габдулла Тукай.

?! 1. Җансыз сабаннар кешечә сөйләшеп кенә калмыйлар, кешеләрнең үзләрен алыштырып киләләр. Сабаннарның үз сыйфатларын һәм аларга автор өстәгән кеше сыйфатларын дәфтәрләрегезгә языгыз.

2. Сабаннар кешеләргә ничек охшыйлар?

3. Сабан сыйфатлары аша шагыйрь безгә нинди үгет бирә?

ИДЕЛ СУЫ КИТТЕ КЕБЕК.

Минем туган якларымда
Нинди гүзәл елгалар!
Үткәннәрне искә алып,
Ярларыннан чыгалар.

Фәннур Сафин.

?! 1. Шигырьдә автор елганың үз сыйфатын әйтә. Нинди сыйфатын әйтә?

2. Автор елгага кеше сыйфатлары да өстәгән. Исбат итегез.

КӨНЧЕЛ ҖИЛ.

Әле генә ярсу идең,
Арысландай идең, җил.
Хәтта язмышның үзенә
Карышкандай идең, җил.

Шаярасың да уйныйсың,
Әйтерсең бу син түгел.
Йөгерә-йөгерә, яфрак
җыйган
Малай кебек син бүген.

Яфракларны тузгытасың,
Тагын өеп куясың.
Ал алмалар койган кебек,
Яфрак гомерен кыясың.

Яфрак җыйган дусларыма
Кызыгасың түгелме?
(Ә аларга күзгә керү
Шундый кызык, күңелле!)

Алар эшен күреп, һәркем
Куәт өстәп эндәшә.
Ахры, шуңа җил дә бүген
Балалардан көнләшә...

Фәннур Сафин.

?! Әсәрдә катнашучылар күп, ләкин төп персонажлар икәү генә. Аңлатыгыз. Алар турында сөйләгез.

МОСАФИРЛАР ҺӘМ ЭТЛӘР.

Төнгә таба ике мосафир урамда тәмле-тәмле сөйләшеп баралар иде. Боларның бу тынычлыклары озакка бармады, кинәттән бер капка астыннан кечкенә генә курнос көчек тәф, тәф иткәч тә, аның артыннан икенчесе, аннан өченчесе, дүртенче, бишенче, алтынчы... Күз ачып йомганчы иллеләп эт җыелып та өлгерде. Сискәнеп китеп, мосафирларның берсе кулына таш та алган иде. Икенчесе: «И иптәш, син этләрне өрүдән тыя алмассың, тик эт көтүен тагын да күбәйтерсең, әйдә, алга атлыйк, мин этләрнең холкын бик яхшы беләм»,— дигәч, акрын гына илле-алтмыш адым киттеләр. Киткән саен, эт тавышлары азайды, бара-бара, бөтенләй үк ишетелми башлады.

* * *

Көнчеләр синең тәрәккыеңне[1] күрсәләр әбәда[2]. Әмма син аларга карама, үз юлың берлән бар. Өрерләр дә туктарлар.

Габдулла Тукай.

?!

1. Әсәрләрдә катнашучылар күп. Ләкин алар ике өлеш булып кына бүленәләр. Бүлегез.

2. Әсәрдә автор да катнаша. Исбат итегез.

---

[1] Тәрәккыеңне — алга китүеңне, уңышка ирешүеңне.

[2] Әбәда — туктый белмәсләр.

Төп герой.

Әсәрдә катнашучыларның тагын бер үзенчәлеген искә төшерик. Персонажлар арасында берсе активлыгы белән башкалардан аерылып тора. Аңа **төп герой** диләр. Ләкин башкалар төп геройның үзләреннән өстенлегенә аз гына да көнләшмиләр. Аның белән теләп аралашалар: яхшы булса, тату яшиләр, начар булса, яхшыртырга тырышалар. Алар безгә төп геройның холкын ачарга ярдәм итәләр.

Ләкин төп герой гел-гел яхшы кеше генә булырга теләми. Габдулла Тукайның «Су анасы» шигырендәге малай кебек, ул карак та, «Шүрәле» әкиятендәге Шүрәле кебек ахмак та була.

ЧЫПЧЫКЛАР ҺӘМ КЫЗЫЛТҮШ.

Мужик[1] тозак белән берничә чыпчыкны тотты да, аларга бармак селкеп, шушы рәвештә шелтәли башлады:

— Ә! Эләктегезме караклар! Сез җәй буе минем арышымны, борчагымны чүпләдегез. Мин хәзер сезнең һәммәгезнең муенын борып ташлармын да боткага салырмын.

Мужик, шулай орышканда, чыпчыклар арасындагы Кызылтүшкә күзе төшеп: «Ә син, Кызылтүш, ничек монда эләктең?» — диде.

---

[1] «Мужик» дип язганда, Габдулла Тукай авыл кешесен күздә тота.

Кызылтүш җавапта куркып кына ялынырга башлады вә диде: «Тыңла әле, мужик агай, мин сиңа эшнең ничеклеген сөйлим: мин, синең кырың өстендә чыпчыклар белән бергә очсам да, һич тә синең борчакларыңа зарар тидермәдем. Син азат ит мине, минем һич гөнаһым юк».

Мужик бу ялынуга каршы: «Юк, сине дә азат итмим, син дә бәлаңне үзеңнән күр, ни өчен караклар белән бергә йөрисең?» — диде.

Габдулла Тукай.

?! **1.** Мәсәлдә катнашучылар күп. Берсе тиз табыла. Ул — мужик. Башка катнашучыларны бер генә сүз белән әйтегез.

2. Мәсәлдәге төп каршылык Кызылтүштә. Ул гаепле дә, гаепсез дә. Исбат итегез.

Автор.

Һөнәре шигырь язу булган кешегә **шагыйрь,** хикәяләр, повестьлар, романнар язучыга **прозаик,** ә драмалар иҗат итүчегә **драматург** диләр. Уртак сыйфатлары әсәр язу булганга, аларны **язучы** яки **әдип** диләр.

Ике исем генә аз дип, язучыларга тагын бер исем өстәгәннәр. Үз әсәрләренә **үзе ия** исеме кушканнар. Бу исемне уйлап табучы галим борынгы грек иленнән булган. Шуңа күрә «үзе ия» сүзен үз телендә **автор** дигән. Яңа исем бөтен дөньяга таралган. Безгә дә килеп җиткән...

Тәмамланган хезмәтендә үз табышы булган язучыларга **автор** диләр.

КҮРЕНМИ.

Англиядә укучы улына әнисе шалтырата.

— Харис, һава шартлары нинди анда? — дип сорый.

— Белмим шул, әни, мондагы томан аша берни күренми,— ди улы.

?! Мәзәктәге каршылык соңгы юлда. Малай һава шартларын белмим ди, үзе урамда томан дип, һава шартларын әйтеп бирә. Авторның табышы шул каршылыкта: малай хаклы кебек — күрми бит. Ә үзе күрә — һава шартын әйтеп бирә.

Мәзәк авторы безне иҗатка, ягъни уйлаганда күнегелгән юлдан китәргә өйрәтә. Бер үк вакытта малайга да бәя бирергә куша. Малайга бәя бирегез.

ТАНЫШ ИСЕМ.

— Фамилияң нинди?

— Тукай.

— Таныш исем икән.

— Таныш булмый, минем әти кибеттә ун ел буе сатучы булып эшли бит!

?! Мәзәк төзелешен искә төшерик. Малай хаклы да, шул ук вакытта хаксыз да. Исбат итегез.

ЧУЛПАН ЙОЛДЫЗ.

Йолдызлар сүнде,
Төн узган инде.
Бер йолдыз калды,
Ул Чулпан иде.

— Кемне көтәсең
Таң саен ялгыз,
Әйт әле миңа,
Әй шаян йолдыз.

Һәм әйтте Чулпан
Дөньяга сүзен:
— Телим күрергә
Кояшның йөзен.

Шул чакта Кояш
Ал йөзен ачты.
Чулпан кызарды,
Аннан соң качты.

Нәби Дәүли.

?! **1.** Шигырь Чулпан йолдыз белән Кояш турында гына булса, автор бу шигырьне ничек язган булыр иде?

2. Әдип безгә: «Табигать турында яздым. Ләкин әсәремнең эчтәлеге башка, шул эчтәлекне табыгыз», — ди. Табыгыз.

ХӘЙЛӘНЕҢ ФАЙДАСЫ.

Мәтрүшкәләп чәй эчерә,
Үзе шелтәли әби:
— Песи төчкергән җилдән дә
Сиңа салкын тия, — ди.

Бер карасаң, шәп уранам,
Юл калдырмыйм салкынга,
Хәтта ябык форточкага
Утырмыймын якын да.

Хәер, салкын тиюнең дә
Уңай ягы бар икән —
Иптәшләр дәрескә китә,
Ә мин өйдә ял итәм.

Бик арытты бу арада,
Ник әле салкын тими?
Иртән үк торып, мәктәпкә
Бер дә барасы килми...

Хәяли хәйлә өйрәтте:
— Соң үзең дә тырыш, ди,
Салкын тизрәк тисен дисәң,
Бераз аңа булыш,— ди.

Шул көннән башлап, салкынны
Үзем чакырып кертәм —
Бүлмәмдә мин форточкамны
Ачык тотам кич, иртән.

Салкын су белән коенам
Һәр көнне юрамалый.
Бияләй дә кимим әле,
Шарф та урамадым...

Шәүкәт Галиев.

?! Шигырь тәмамланмады әле. Өзеккә «Салкын тидерү өчен тырышу» дип исем бирик. Әсәрнең икенче өлешен үзегез уйлап табыгыз.

МАРАТ БЕЛӘН МИҢНУРИ.

Зур көрәкне алып кулына,
Сукмак салды капка юлына,
Чиләкләрен алды Миңнури,
— Кая барасың? — дим мин юри.

Шаяртканны минем аңлады,
Бик хәйләкәр генә карады,
Сүзгә керми икән кесәгә,
Үзе көлми, күзе көлсә дә.

— Утынга, ди, барам бәкегә.—
Мин белмәдем нәрсә әйтергә,
Җилдәй оча гына Миңнури,
Кайтканын да көтимче юри.

Әминә Бикчәнтәева.

?! 1. Шигырь Марат һәм Миңнури турында. Марат юри сорау бирә, кызның судан кайтканын юри көтеп тора. Тагын нишли?

2. Марат турында сөйләгез.

3. Миңнури сыйфатларын әйтегез.

4. Шигырь эчтәлеген ничек аңладыгыз?

Бүленгән өлешләргә исем бирик.

Өлеш дип әсәрне бүлгәннән соң табылган кисәкләргә әйтәләр. Әсәрләрнең исеме башында була. Гадәттә, әсәр эчендәге өлешләргә автор исем куймый. Аларны без табабыз. «Нәрсә турында?» соравын бирәбез дә аңа бик кыска гына җавап эзлибез. Иң кыска җавап исем була.

Предметларны ничек кушабыз? Без аларга: «Кара, болар кабатланган бит»,— дибез дә барысына бер исем бирәбез. Иң җиңеле — бер-берсенә бик нык охшаган предметларны кушу. Мәсәлән, бер чыпчык, ике чыпчык... ун чыпчык дип санамыйбыз бит, «чыпчыклар» дип кенә әйтәбез.

«Чыпчыклар» исеме үз эченә бик күп чыпчыкларны сыйдырган. «Атлар» исеме дә төрле төстәге, төрле яшьтәге, төрле холыклы атларны эченә ала.

Өлешләргә исем бирү нигә кирәк?

Исем эзләү безне уйларга өйрәтә. Уйлауның иң күп кабатланган ике алымы бар. **Берсе — бер әйберне, өлешләргә аерып, күп итү. Икенчесе — күп әйберләрне, кушып, бергә генә калдыру.**

Әсәрне өлешләргә таркатканда, без уйның беренче алымын — таркату алымын файдаланабыз. Охшаш өлешләрне кушып, аларга уртак бер исем биргәндә, уйның икенче алымын — кушу алымын ярдәмгә чакырабыз.

Менә сез эт рәсеме ясадыгыз, ди. Рәсемдәге этне өлешләргә бүлсәк, башы, гәүдәсе, койрыгы бар, дисез. Ләкин бер аягы, ике аягы... бар дип санап китмисез, «аяклары» дип, дүрт аякны бер сүз белән әйтәсез.

Бертөрле әйберләрне кушар өчен, уйның кирәге юк. Уй төрле-төрле әйберләрне кушканда ярдәмгә килә.

Төрле әйберләргә шактый озак карап торгач, «Кара! Болар бер-берсенә охшаганнар бит!» — дибез дә шунда ук, аларны кушар өчен, уртак исем эзли башлыйбыз. «Нәрсә турында?» соравына җавапка **тема** диләр. Димәк, без өлешләрнең исемен тапсак, темасын тапкан булабыз.

?! Түбәндәге дүртьюллыкларны, уртак сыйфатларын табып, ике төркемгә аерыгыз. Төркемнәрнең икесенә дә исемнәр бирегез.

Агыйделдән су эчәләр
Күгәрченнәр, гөрләшеп;
Йокыларымнан уянам,
Синең белән сөйләшеп.

Агыйделдә йөзәр идем,
Аккош баласы булсам;
Хат эчендә барыр идем,
Каләм карасы булсам.

Агыйделнең буйларыннан
Таптым ал кашлы йөзек;
Байкал күленә төшсәң дә
Алып чыгармын йөзеп.

Агыйделгә төшкән идем,
Камышы ятьмә кебек;
Ялгыз башым чит илләрдә
Адашкан бәбкә кебек.

Агыйделгә саллар салдым,
Агарлар микән көзгә?
Шушы хатта ничә хәреф —
Шулчаклы сәлам сезгә.

Һәр дүртьюллыкның баштагы ике юлы Агыйдел турындагы сүзләр белән башлана. Шуңа күрә аларның барысына да, «Агыйдел турында» дип, уртак исем бирә алабыз. Ләкин башта килгән ике юлда җырның эчтәлеге юк. Димәк, җырларның охшаш эчтәлеге түбәндәге ике юлда.

Эзләүне дәвам итәбез. Кылт итеп, халык җырының эчтәлеге хис булуы искә төшә.

Хиснең өлешләрен искә төшерик. Хис өлешләре **хиснең сәбәбе** (ягъни хис эчтәлеге), **дәрәҗәсе** һәм **юану** дип өйрәнгән идек.

Уртак сыйфатларын белү өчен, күп әйберне берәм-берәм өйрәнәләр. Өйрәнүне беренче дүртьюллыктан башлыйк.

Лирик герой кемнедер сагына. Бик нык сагына (һаман төшендә күреп уяна). Бик нык сагыну **хис дәрәҗәсе** була. Бу дүртьюллыкның хис дәрәҗәсе турында булуын белдек.

Аннан соң башка дүртьюллыкларны укып чыгабыз. Эчтәлекләре хис дәрәҗәсе булганнарын

табабыз. Тапкач, болар охшаганнар дибез дә, «Хис дәрәҗәсе» дип, уртак исем кушабыз.

Уртак исем табу өлешләрне кушу була. Ә кушуга **гомумиләштерү** диләр.

?! 1. «Агыйделдә йөзәр идем...», «Агыйделгә төшкән идем...» дип башланган дүртьюллыкларның хис сәбәбе аерылу турында булуын аңлатыгыз.

2. «Агыйделнең буйларыннан...» һәм «Агыйделгә саллар салдым...» дип башланган дүртьюллыкларның эчтәлекләре хис дәрәҗәсе булуын аңлатыгыз.

?! Әкиятне укып чыгыгыз. Аны өлешләргә бүлеп, аларга исемнәрне бергәләп табыгыз.

ЧЕЛӘН БЕЛӘН САНДУГАЧ.

Кошлар сайрый белми торган вакыт та булган. Менә бер илдә кошларны җырларга өйрәтүче оста барлыгын ишеткәннәр. Кошлар да, җырларга өйрәнсеннәр дип, оста янына Челән белән Сандугачны җибәргәннәр.

Челәннең дөньяда иң-иң оста җырчы буласы килгән, шуңа күрә бик ашыккан. Менә ул оста өенә ишек какмыйча гына килеп кергән. Исәнлек-саулык та сорашып тормаган. Керү белән, оста колагына:

— Мине җырларга өйрәт, картлач! — дип кычкырган.

Оста Челәнне тәртипкә өйрәтмәкче булган: канатыннан тотып, тышка чыгарган да ишек кагып күрсәткән.

— Менә шулай кирәк! — дигән.

— Аңлашылды! Җыр шушы икән! — дип шатланган Челән һәм, җыры белән дөньяны шаккатырыр өчен, иленә кайтып киткән.

Сандугач, нәни канатларын җилпеп, оста янына соңрак очып килгән. Әкрен генә ишек каккан. Исәнләшкән. Өлкән останы борчып йөрүе өчен гафу үтенгән һәм җырларга өйрәнәсе килүен әйткән.

Остага Сандугачның итагатьле булуы ошаган. Ул аңа үзе белгәннең барысын да өйрәткән.

Шуннан соң Сандугач дөньяда иң оста җырчы булып танылa. Ә Челән, җырлыйм дип, томшыгын томшыкка бәрә дә башкаларны өйрәтә:

— Менә болай, менә болай җырлыйлар аны. Иң матур җыр шул! — ди.

Әйдәгез, әкият өлешләренә исемнәрне бергәләп табыйк.

Башта, «Нәрсә турында? Тагын нәрсә турында?» сорауларын биреп, әкиятне таркатабыз.

«Нәрсә турында?» соравына җавап җиңел табыла: Челән белән Сандугач турында. Чөнки автор бәясен шуларга бирә. Шуңа күрә бу өлешләргә исемне, артык уйлап тормыйча гына, «Челән» һәм «Сандугач» дип куябыз.

Андый исемнәр куйсагыз да ялгышмыйсыз, әлбәттә. Ләкин сез уйларга яратасыз бит. «Тукта әле, тагын да яхшырак исемнәр табып булмасмы?» — дип, уегызны дәвам итегез.

Уйларга иренмәсәң, хәтер ярдәмгә килергә генә тора бит ул. «Исемнәрнең ниндие яхшы? Әсәрнең

эчтәлеген чагылдырганы яхшы»,— дип ярдәмгә килә хәтер. Шуңа күрә, укытучы әйткәнне көтеп тормыйча, әкиятнең Чиләнгә турындагы өлешен тагын бер кат укып чыгыгыз. Ә укып бетергәч, «Әһә, бу өлеш Челәннең тәрбиясезлеге турында, димәк, аның исеме дә «Тәрбиясез Челән» булырга тиеш!» — дип шатланып, эчтән генә кычкырып җибәргәнегезне сизми дә каласыз.

Беренче өлеш табылгач, икенчесе, «мин монда!» дип, үзе кычкырып тора. «Гадәттә, икенче өлеш беренчесенең капма-каршысы була»,— дип, тагын хәтерегез ярдәмгә килә. Хәтерегезгә рәхмәт әйтәсез дә: «Беренче өлеш тәрбиясез катнашучы турында булгач, икенчесе тәрбияле катнашучы турында була. Димәк, икенче өлешнең исеме «Тәрбияле Сандугач» булырга тиеш»,— дисез. Сандугач турындагы өлешне тагын бер кат укыгач, үткән дәресләрне яхшы үзләштергәнмен икән, исемне дөрес тапканмын, дип шатланасыз. Сезнең шатлыкны күреп, без дә шатланабыз.

И с т ә к а л д ы р ы й к.

Беренче өлешнең исеме табылгач, «Икенчесе шуның капма-каршысы түгелме?» — дип уйлыйбыз. Өлешне тагын бер тапкыр укып, уебызның дөреслеген тикшерәбез.

КАР БӨРТЕКЛӘРЕ.

Ак чәчәк кебек
Челтәрле карлар,
Төшеп, сак кына
Җиргә куналар.

Бияләенә
Кунган бөртеккә
Карап торды да
Әйтте Фәридә:

— Гаҗәп соң: шундый
Биектән төшеп
Ватылмаган бит
Бер челтәре дә...

Күрәсең, ничек,
Җир күкрәгенә
Каты кагылмый,
Җиңел төшәләр...

Әбисе аңа:
— Алар бит, кызым,
Күрәсең, нинди
Җиңел, нечкәләр.

Күңелең дә шулай
Керсез, саф булса,
Каты җиргә дә
Йомшак кагылса,

Кеше дигән зур,
Олы исемең
Гомерең буена
Бозылмас синең.

Фәнис Яруллин.

?! Шигырьнең беренче өлеше кар турында. Икенчесе кыз бала турында. Беренчесен «Кар», икенчесен «Бала» дия алабыз. Нинди кар? Нинди бала? Исемнәргә берәр сүз өстәгез.

ВЕЛОСИПЕДЛЫ МӨНИР.

Мөниргә әтисе кибеттән өр-яңа велосипед сатып алды. Мөнир велосипедын җитәкләде дә урамга чыкты. Аның тирәсенә шундук иптәш малайлары җыелды.

— Мөнир, йөреп торырга миңа да бирерсең әле велосипедыңны? — диде Илдус. Бүтән малайлар да:

— Эх, нинди ялтырап тора!

— Бер генә тотып карыйм әле?

— Мөнир, мин дә йөрермен әле? — диештеләр. Мөнир велосипедын бик кызганды. Аның үз әйберсенә беркемне дә кагылдырасы килмәде.

— Теләнмәгез дә, берегезгә дә бирмим! — диде ул, кырт кисеп.

Ләкин Мөнир велосипедта йөри белми иде. Шуңа күрә аны, велосипедка утыргач аумас өчен, арттан кем дә булса тотып барырга тиеш иде.

— Ярар инде, алайса, син генә йөреп карарсың,— диде ул Илдуска.— Тик мин утыргач, велосипедны тотарсың... Ычкындыра күрмә... Басуга чыгып, әнә теге чыршы турысына җиткәч, мин төшәрмен дә, син китәрсең.

Илдус бик шатланып риза булды. Мөнир киртә янына килде дә велосипедның ияренә атланып утырды. Илдус велосипедны тотып торды.

Менә алар әкрен генә кузгалып киттеләр. Велосипед баштарак әле бер якка, әле икенче якка кыйшайды. Әгәр Илдус ныгытып тотмаган булса, Мөнир шундук егылып төшкән булыр иде. Шулай да ул бераздан тигезлеген саклый ала башлады, һәм велосипед такыр юлдан җиңел генә тәгәрәп китте.

Тиздән иптәшләре дә, авыл да артта калды. Алар юл буендагы чыршы турысына да якынлаштылар. Илдус бик кызу йөгерүдән тирләп бетте, кызарды.

— Тукта инде, Мөнир...— диде Илдус, ялгыз чыршыны узып киткәч.

Ә Мөнир туктамады, киресенчә, тагын да кызурак бара башлады.

— Мөнир, йөрерсең дип, үзең әйттең ич... тукта

инде,— диде Илдус, кызганыч тавыш белән.— Туктамасаң ычкындырам. Кит үзең генә.

— Ычкындырсаң әллә! Бар, китә бир,— диде Мөнир, бер дә исе китмичә.— Мин инде синнән башка да йөри алам.

Илдус бик хурланды. Мөнирнең велосипедын ычкындырды да, кире борылып, авылга таба йөгерде. Ә Мөнир, иптәшеннән котылуына сөенеп, тагын да кызурак китте.

Бара торгач, юл кисәк кенә түбәнәя башлады. Велосипед, тигезсез юлда дыңгырдап, һаман шәбрәк тәгәрәде. Хәзер инде педальгә басарга да кирәкмәде. Мөнирнең колак төбендә җил сызгырды, йөрәге куркудан жу итеп китте: ул, велосипедның йөрешен әкренәйтү өчен, тормозга басарга кирәклеген белми иде.

Велосипед очты гына. Мөнир үз алдында берни дә күрмәде, куллары-аяклары тыңламас булды, һәм коты алынган малай, үзе дә сизмәстән:

— Илдус! Тот, ычкындырма! — дип кычкырып җибәрде.

Зырылдап әйләнеп барган алгы тәгәрмәч кинәт читкә кереп китте, һәм Мөнир велосипеды-ние белән юл читендәге чокырга мәтәлеп төште. Аның янында беркем дә юк иде.

Нурихан Фәттах.

?! 1. Хикәяне укып чыгыгыз. Андагы вакыйганы кып-кыска итеп сөйләгез.

2. Өлешләргә исем табыгыз.

СЕРТОТМАС ҮРДӘК.

Бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен иярткән, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы һәрбер кош-кортына: «Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!» — дигән.

«Нигә белдермәскә кушты икән?» — дип, Үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.

Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. «Икенче көнне дә кайтмас бу»,— дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрергә булганнар. «Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар,— дигәннәр алар Үрдәккә. — Ләкин, берүк, нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!» — дигәннәр. Үрдәк күнгән:

«Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде»,— дигән.

?! 1. Әкиятнең укыган өлешенә исем бирегез.

Иртә торгач та, Үрдәк уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча, бер елгага барып төшкән. Ишкәкләре-тәпиләре үзендә булганга аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып, тәпи-тәпи дә йөгергән...

Бара-бара, куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга кереп тә киткән.

Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер Керпе килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:

— Кая барасың болай? — дигән.

Үрдәккә инде шул гына кирәк тә икән. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә, аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә онытқан, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган:

— Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр,— дигән.

— Синең өең еракмы соң? — дигән Керпе.— Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы? — дип сораган. Аның үз хәле хәл, бик нык ашыйсы килә икән.

— Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара! — дигән Үрдәк.

Өйләрендә еланнарның бөтенләй юклыгын, тычканнарга көн бирмәүче мәченең шуклыгын да сөйләп биргән.

Алар дус булышып аерылганда, әнәле кием кигән булса да, Керпе бик файдалы киңәш биргән:

— Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Серең эчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр,— дигән.

Керпенең бу акыллы киңәшенә Үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга, урман эченә атлаган.

?! **2.** Үрдәкнең Керпе белән очрашу вакыйгасын да үз сүзләрегез белән кыскартып сөйләгез. Аңа исем уйлап табыгыз.

Бара-бара, Үрдәккә озын колаклы бер Куян очраган, һәм ул да аңардан сораган:

— Әй бүрекле Үрдәк, күзге төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?

— Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды,— дигән Үрдәк, Керпегә сөйләгәнне моңа да сөйләп биргән. Куян эченнән генә: «Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән»,— дигән. Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан, теге юләр моңа да серен ачкан.

— Хуҗаңны күргәнем юк,— дигән дә Куян куаклык эченә кереп югалган.

?! **3.** Әле генә укыган вакыйгага да исем табыгыз.

Үрдәк тагын алга киткән. Бара-бара, бер аланлыкка барып җиткән. Анда бер зур соры Аю мышныймышный йоклап ята икән. Үрдәк аны да уяткан. Керпе белән Куянга сөйләгән сүзне аңа да сөйләп биргән. Сүз ахырында Аюдан сораган:

— Эт иярткән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме?

Аю:

— Күрмәдем,— дип җавап биргән. Үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган: — Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез, табарсың,— дип, юл өйрәтеп җибәргән. Ә үзе эченнән генә: «Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга бик җайлы вакыт икән»,— дип, ашыга-ашыга китеп тә барган.

?! **4.** Бу вакыйгага да исем табыгыз.

Үрдәк һаман хуҗаны эзләвен дәвам иттергән. Аның саен урманның эченәрәк керә барган.

Бара торгач, аның каршына Бүре килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:

— Әй бүрекле баш, шушындый куе урманда япа-ялгызың гына, курыкмыйча, батырланып, ничек йөрисең? — дигән.

Теге дә үзенең ник йөрүен сөйләп биргән. Хуҗаның өйдә юклыгын, этнең дә аның белән бергә ияреп китүен Бүрегә дә әйткән. Усал Бүре тешләрен шыкырдаткан, үз-үзенә: «Боларның сарыкларын барып ашап кайтырга бик җайлы чак икән»,— дигән, ә Үрдәккә:

— Андый кешене күргәнем юк! — диган дә үзе куаклар арасына кереп югалган.

Үрдәк һаман туктамаган. Хуҗасын эзләүне дәвам иткән.

Бара-бара, аның каршысына көлтәдәй койрыклы бер Төлке килеп чыккан. Теге ахмак бит, моңа да сүз кушкан:

— Багалмакай, матур апакай, минем хуҗамны күрмәдеңме? — дигән.— Янында эте, кулында балтасы бар иде,— дип тә өстәгән. Хуҗасыз һәм этсез өйдәге хайваннарның тынычсызлануларын, алардан башка куркуларын да сөйләп биргән.

— Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре[1], күрдем мин аны! — дигән Төлке.— Янында кәкре койрыклы эте, билендә корыч балтасы да бар иде,— дип өстәгән. Үрдәкне үзе белән ияртеп киткән.

?! **5.** Укый торгач, тагын ике вакыйга белән таныштыгыз. Аларга да исем бирегез.

Алар бик озак барганнар һәм куак белән капланган елга буена килеп туктаганнар. Шунда Төлкенең оясы янында балалары уйнап йөриләр икән.

Алар:

— Әни, безгә азык алып кайттыңмы? — дип, аның тирә-юнен сырып алганнар, ә ул, авызын ерган килеш, Үрдәккә күрсәткән...

— Менә, бәбкәләрем, сезгә тәмле үрдәк ите,—дигән һәм шул минут Үрдәкне буып, балаларына бүлеп

[1] Гәүһәр — кыйммәтле таш.

тә биргән. «Үрдәк ите бигрәк тәмле була икән!» — дип, алар, авызларын ялый-ялый, аны ашап та бетергәннәр, ләкин туймаганнар, аналарыннан тагын да сораганнар.

— Хәзер, бәбкәләрем, авылга барам, берьюлы берничә үрдәк алып кайтам,— дигән Төлке. Балаларын калдырып, авылга киткән.

?! **6.** Бу өзек нәрсә турында? Аңа нинди исем биреп була?

Бер сертотмас Үрдәк аркасында бу хуҗалык тәмам туздырылган булыр иде, ләкин хуҗа уяу кеше булган, дошманнарына каршы һәр җирдә киртә куйган.

Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган. Аю бәрәңге базына төшкән. Бүрегә дә сарыклар эләкмәгән, хуҗалык абзарына ул бөтенләй керә алмаган. Төлке хәйләкәр булса да сыза алмый калган, үрдәк ите ашыйм дигәндә генә, капкынга эләккән, ә хуҗа, кайткач инде, аның кирәген биргән... «Тагын берничәне тоткач, толып тектерермен»,— дигән һәм тиресен киптерергә амбарга элгән.

Хайваннар эшнең нидәлеген хуҗага сөйләп биргәннәр. Сертотмасны шундый зур эшкә кушуларына алар бик үкенгәннәр.

Абдулла Алиш.

?! **7.** Әкиятне башыннан ахырына кадәр сөйләп чыгыгыз.

1. Рәсемдәге күренешне вакыйга итеп языгыз. Рәсем вакыйганың беренче өлеше булса, икенче өлешен үзегез уйлап чыгарыгыз.

2. Яза башлаганчы, «Нәрсә турында? Тагын нәрсә турында?» дип, үзегезгә үзегез сораулар бирегез. Төп катнашучыларны табыгыз. Шулар турында гына языгыз. Аннан соң, «Икенче өлеш нәрсә турында була ала?» дип, сорау бирегез һәм хикәягезне дәвам итегез.

ӘЛЛӘ КАЯН КҮРЕНЕП ТОРА.

Иптәш малайның дәфтәреннән сүзгә-сүз күчердем югыйсә. Алай да укытучы апа «ике»ле куйды. «Ике»леләр моңа кадәр дә миннән ерак йөрми иде йөрүен. Ләкин элеккеләре аның үткән заман инде. Ә бүгенгесе бөтенләй башка. «Тагын бер генә «ике»ле алып кара, яңа велосипедны колагыңны күрә алма-

ган кебек күрмәссең»,— диде әти. Кызганычка каршы, минем әти әйткән сүзеннән кайта торган кеше түгел. Велосипед алмыйм дисә, күпме ялынсаң да алып кайтмаячак.

Кыскасы, «ике»лене ничек кенә булса да төзәтергә кирәк. Укытучы апа янына килеп, эшне аңлатып бирдем. Шундый-шундый хәл, әгәр билгемне төзәтмәсәм, быел да велосипедсыз калам, дидем.

— Шула-ай...— диде ул.— Бер изложениеңдә җиде хата. Алай да, әйдә, тырышып карыйк. Менә сиңа китап. Өеңә кайткач, шушы хикәяне ике тапкыр укып чык. Ике тапкыр гына укы. Аннары китабыңны яп та хәтереңдә калган вакыйганы үз сүзләрең белән яз. Кара аны, китабыңны бүтән ачасы булма.

— Китапны ачу-ачмавымны кем карап тора?

— Берәү дә карап тормый. Мин сиңа ышанам. Һәр адымыңны күзәтеп торырлык кечкенә баламыни син?

— Ә мин китапны ачып карасам? Ачам да карыйм.

— Карамыйсың.

— Нигә карамыйм?

— Шулай килешкәнгә карамыйсың. Намусың кушмаячак.

— Шулаен шулай, ләкин минем китапка карамавымны кем беләчәк соң?

— Ярый, сүз бетте дип исәплик,— диде укытучы апа.— Кайт та эшкә тотын.

Кайтып эшкә утырдым. Хикәяне ике генә тапкыр укып чыктым да китапны яптым. Бик ачасы килсә дә,

бүтән ачмадым. Язу кыен булды. Сыйныфта язсам да, бу хәтле кыен булмас иде. Анда укытучы үзе дә ярдәмгә килер иде, кешедән дә күчереп булыр иде.

Алай да, хәтердә калган хәтлесен язып, укытучы апага укыттым.

— Намуслы кеше син. Апа мактады дип, әтиеңә дә әйтә аласың, — диде ул.

— Ә «ике»ле?

— Эш «ике»ледәмени! Син аны төзәттем дип исәплә.

— Ә сез минем намуслы яки намуссыз булуымны ничек белдегез?

— Изложениең әйтеп тора.

Виктор Голявкиннан.

?! 1. Хикәяне ашыкмыйча, аңларга тырышып укыгыз. Кыскартып сөйләгез. Хикәядәге вакыйгаларны хәтердә калдыру өчен, сезгә бер генә тапкыр укып чыгу да җитә. Китабыгызны ябыгыз. «Нәрсә турында? Аннан соң нәрсә турында?» сорауларына җавапларыгызны дәфтәрегезгә кыска гына итеп язып куегыз.

2. Автор хикәясен ни өчен «Әллә каян күренеп тора» дип атаган? Аңлатыгыз.

План үрнәгендә хикәя языгыз.

Чаган җыры.

1. Мине кистеләр, киптерделәр.
2. Юнып, кыл суздылар.
3. Мине җырлаталар.
4. «Шатлык җыры җырлый»,— дип уйлыйлар.

«КУРКАК» БАТЫР.

Ул көнне укучылар «Кем булырга? Нинди булырга?» дигән темага инша яздылар. Балалар иксезчиксез хыял диңгезенә чумып, киләчәк турында уйланып утырганда, ишек шакыдылар.

Һәммәсе, сискәнеп, башларын күтәрде.

Ишектән кырыс йөзле милиционер килеп керде. Погоннарында икешәр кечкенә йолдызчык. Лейтенант, димәк.

Балалар, яза башлаган иншаларын онытып, лейтенантка текәлделәр.

— Сездә булырга тиеш ул малай...— диде лейтенант. — Без аны, дөнья бетереп, башка мәктәпләрдән эзлибез, ә ул менә кая кереп поскан... Качып котылам дип уйлаган, күрәсең... Шалишь, бездән әле беркемнең дә ычкына алганы юк... Сездә диделәр ул мыштым малайны... Исеме — Ризван, фамилиясе — Корбангалиев. Бармы шундый малай?

Укучылар, аптырап, Ризванга таба борылдылар.

— Әйе... бар... Бездә укый,— диде укытучы апа, каушавын яшерә алмыйча.

Тәрәзә янында утыручы Ризван исә, иелә төшеп, кемнеңдер җилкәсе артына ышыкланды.

Малайның башыннан «Тәки эземә төштеләр бит!..» дигән уй яшен тизлеге белән узып китте.

Лейтенант:

— Чык бирегә! Вакыт тар! — диде.

Ризван парта арасыннан, кыйналган кешедәй өстерәлеп, такта янына чыгып баскач, лейтенант сорау бирә башлады:

— Ризван Корбангалиев! Син шушы айның унбишендә райүзәктә булдыңмы?

— Булдым.

— Анда нишләдең? Ни дип барган идең син анда?

— Әтине исполкомга чакырганнар иде, әти безнең урманчы, мин дә ияреп бардым. Апаларга кунакка...

— Тәк. Киттек алга таба... Сәгать унбер белән унике арасында кайда идең, хәтерлисеңме?

— Унбер белән унике арасындамы?.. Әйе, мине ипи алырга кибеткә җибәргәннәр иде...

— Йә, шуннан?

— Шул... Бер бөтен ипи алдым да кайтып киттем...

— Юк, кайтып китмәдең син! — диде лейтенант.— Ипине өйгә кайтармагансың ич... Дөресен сөйлә! Беләсең килсә, синең аркада районның җиде мәктәбен айкап чыктым. Сезнеке сигезенче. Ярый әле күрүчеләр булган, танып калганнар үзеңне...

Сөйлә! Балалар, сез дә тыңлагыз!

?! 1. Хикәянең беренче өлешенә исем табыгыз.

— Балалар бакчасы яныннан узып бара идем, беренче кат тәрәзәсеннән төтен аралаш ут көлтәсе ургылып чыкты. Янгын. Эчтә кычкырыш, елаш, сабый балалар тавышы. Кемдер: «Коткарыгыз!» — дип кычкыра. Башта куркып калдым. Чабып эчкә кердем. Ул арада янгын сүндерүчеләр дә килеп җитте, мин тәрәзәне урындык белән бәреп ваттым да балаларны тәрәзә аша биреп тордым...

Ризван тынып калды. Лейтенант, ирен читләре белән генә көлемсерәп:

— Шулай итеп, курыктым дисең, ә? — диде.— Әйбәт курку бу, дускаем! Киләчәктә дә шулай «курыкырга» язсын!..

Лейтенант кесәсеннән кечкенә генә тартма чыгарды. Кулына ялтырап торган медаль алды:

— Котлыйм сине, «куркак» батыр! — дип, Ризванның күкрәгенә әлеге медальне беркетеп куйды...

Вахит Монасыйпов.

?! **2.** Хикәянең икенче өлешенә дә исем уйлагыз.



1. Йөгерештә катнашучыларга сирәк очрый торган яки бөтенләй очрамый торган исемнәр уйлап табыгыз.

2. Рәсемгә исем уйлап табыгыз.

3. Шәүләләргә карап, йөгерешчеләрнең аермасын аңлатыгыз.

4. Сез икенче йөгерешче, ди. Нәрсә уйлап чабасыз? Соңгы йөгерешче нәрсә уйлый икән дипме? Шул турыда хикәя языгыз.

Автор телəген табарга өйрəник.

Искə төшерик.

Автор телəгенең **идея** дип аталуын беләсез. Әсәрләрнең бер ишендә аны табасы юк. Идея, «мин монда» дип, үзе күз кысып тора.

Мəсəлəн, «Юкка кəпрəймə — вакытсыз кəкрəерсең» мəкалендə автор телəген эзлисе юк. Əнə бит автор безгə бармак яный: «Кəпрəймəгез!» — ди.

«Иптəшең үзеңнəн яхшы булсын» дип, безгə бик матур телəк тели мəкаль авторы.

Аклы күлмəк тектерсəгез,
Өлге алып кисегез;
Җилгə чыгып каршы торам,
Сез җил булып исегез,—

дип җырлый автор. Яраткан кешесе белəн очрашырга тели.

«Ач булса ята, тук булса торып утыра» дип, табышмак əйтə берəү. Шундый хикмəтле нəрсəнең *капчык* булуын таптыра. Бу табышмакта автор телəге юк кебек. Лəкин, табышмагын əйткəндə: «Их, җавапның капчык булуын тапсалар иде балалар!»— дип тели автор.

Авторлар безгə берсеннəн-берсе матуррак телəклəр телилəр.

«Безнең балалар ялкау, үзсүзле, йомык, кыланчык... булмасалар иде»,— дип тели автор һәм гыйбрәт алырлык малайлар, кызлар турында яза. Бу юлы ул борчылып тели.

Сез әсәрне, «Нәрсә турында? Тагын нәрсә турында?» сораулары биреп, өлешләргә бүлдегез. «Нәрсә турында?» соравына җавап тапсак, әсәрнең **темасын** тапкан булабыз. Ә тема белән идея әсәрнең **эчтәлеге** була.

«Ашыкмасаң, ат арбасына утырсаң да, куян артыннан җитә алырсың» мәкалендә автор теләген табыйк.

1. Мәкальне өлешләргә таркатыйк. Мәкаль нәрсә турында? Ашыкмый торган кеше һәм тиз чаба торган куян турында.

2. Ике өлеш табылды. Алар арасындагы бәйләнешне ачыклыйк. Автор кеше белән куянны чагыштыра. Кеше ашыкмыйча әкрен генә бара, ә куян ашыгып чаба, ди. Без куянның җан-фәрманга чапкан атны да узуын яхшы беләбез. Ләкин мәкаль әйтүче безнең белән килешми. Юк, чаба торган куянны атлап бара торган ат уза, ди. Каршылык туды. Ике өлеш арасындагы бәйләнешнең каршылык булуы ачыкланды.

Автор безгә әнә шул каршылыкны чишәргә куша. Ни өчен әкрен баручының тиз баручыга караганда ераграк китүен үзең бел, ди.

Болай уйлыйбыз. Вакыйганы күз алдына китерик. Кеше дә, куян да бер юлдан каядыр баралар. Узышсалар, кеше артта кала. Димәк, алар узышмыйлар. Әһә, ди укучы, алар, мөгаен, ерак баралардыр. Кеше

атын чаптырмый, аты арыса, ерак китә алмаячак, ди. Шуңа күрә кирәк җиренә барып җитә. Ә куян чаба. Арый, ял итә-итә, артта кала.

Истә калдырыйк.

Автор теләген табу өчен, әсәрдәге авторны һәм өлешләр арасындагы бәйләнешне дә табарга кирәклеген белдек.

* Кунакка барсаң, казаныңны юып кит.

* Әдәпле булырга әдәпсездән өйрән.

* Карап кына өйрәнә торган булса, эт күптән ит чабучы булыр иде.

?! Мәкальләрдә автор теләген табыгыз.

«Миннән никадәр алсалар, шулкадәр зурая барам»,— ди безгә табышмак авторы.

Табышмак балаларны көлдерү өчен генә әйтелгән кебек. Чөнки алу — киметү дигән сүз. Савыттан балны ашаган саен, ул артып торса иде. Артмый бит, кими генә.

— Алгач, нәрсә арта? Табыгыз,— ди табышмакны уйлап чыгаручы.

Сезнең әллә чокыр казыганыгыз юкмы? Әлбәттә, шунда ук уйлап табасыз:

— Чокыр казыганда шулай була! — дип җавап бирәсез.

?! Табышмак авторының теләге нинди?

ӨЙДӘ ЮК.

— Шул савытларны тиз генә
Юып бир әле, улым.
Пилмән пешерәм үзеңә —
Буш түгел минем кулым!

— Әни, дим, әни, күр инде,
Вакытым юк минем дә:
Гулливер белән йөрим мин
Лилипутлар илендә.

Бүлдермә инде, бүлдермә,
Бик кызык җиргә җиттем —
Гулливер белән бергә мин
Мең лилипутны ектым.

Мин бит әллә кайда йөрим,
Мин бит өйдә юк, әни.
Башладым — укып бетерим,
Минем эшем күп, әни...

Кыскасы, Камил күнмәде,
Китабын куялмады,
Кухняга якын килмәде,
Савытлар юалмады.

Онытты эшне, ашларны,
Утырды, китап укып...
Бераздан йөри башлады,
Кулына кашык тотып.

Бик-бик ашыйсы килде дә
Камил кухняга керде,
Ләкин анда бернинди дә
Пилмән юк! — Шуны күрде.

Һәм бер җавап ишетте ул:
— Тукта, улым, туктале,
Гулливер белән китте ул,
Камил өйдә юк әле!..

Зәки Нури.

?! 1. Шигырьнең беренче өлешендә Камил әнисенә ярдәм итми. Ул ничек уйлый?

2. Беренче өлешкә исем уйлап табыгыз.

3. Шигырьнең икенче өлешен әйтегез. Анысына да исем уйлап табыгыз.

4. Камилнең әнисе улына нинди теләк тели?

КАРАМАРЫДАГЫ ИШӘК.

Иртән Деннины әнисе мәктәпкә озатты.

— Юлны аркылы чыкканда, берүк, сак була күр, улым. Уңга-сулга күз салгач кына кузгал,— дип, көн дә әйтә торган үгетен кабатлады.

— Бик акыллы киңәш, — дип сүзгә кушылды әтисе. — Як-ягыңа күз ташлап йөрсәң, күп нәрсә күрерсең. Юлда хуҗасыз песиләрдән алып корольләргә кадәр очратып була.

— Ярый, як-ягыма карап йөрермен,— дип, Денни мәктәбенә юнәлде.

— Юк-бар нәрсә сөйләп, бала башын катырасың,— дип елмайды иренә хатыны.

— Бала башын әкият белән тутырудан ни зыян,— диде эшкә китәргә җыенган ире.

Ул якындагы гына театрда эшли. Былтыр Денни Яңа ел алдыннан театрга барды. Аңа король кызына өйләнгән егет тә, аның сөйләшә торган песие дә, туңдырма белән сыйлаган билет сатучы апа да бик ошаган иде. Ә искиткеч матур киенгән әтисен күргәч, шатланып туя алмады ул. Әтисенең җиңел машина ишеген ачып җибәрүләре, тамашачыларны залга озатулары, такси чакырып сызгырулары әле дә күз алдыннан китми.

?! **1.** Хикәянең укылган өлешенә «Кереш» яисә «Таныштыру» дип исем биреп була. Өч катнашучының автор күрсәткән төп сыйфатларын әйтегез.

— Минем әтинең пинжәге алтын белән чигелгән,— диде ул, икенче көнне мәктәпкә килгәч.

— Алтын булмый ни?! Синең әтиең пинжәге бит ул! — дип үртәде Альберт исемле малай.— Ул әкиятеңне әбиеңә кайтып сөйлә.

Денни Альбертны яратмый. Шуңа күрә җавапсыз калмый:

— Әллә сөйләмәс дисеңме? Кайтам да әбигә минем әти җилкәсендә алтын погоннар, түше тулы алтынлап чиккән чәчәкләр дип сөйлим...

— Юк нәрсә лыгырдаганчы, әтиеңнең туган җирен әйт,— дип көлде Мэйзи.

— Минем әти Карамарыда туган,— дип кычкырды Денни. Бәхәсне тыңлап торган балалар шаркылдап көлделәр. Алар, «Карамары» сүзен ишеткән саен, шулай көләргә гадәтләнделәр.

— Ә бит Карамары дигән авыл дөньяда юк,— дип үҗәтләнүен дәвам итте Мэйзи.

— Бар!

— Син бит ул исемне уйлап кына чыгардың.

— Уйлап чыгармадым! Әтинең пинжәге дә алтын белән чигелгән!

— Әкиятеңне әбиеңә кайтып сөйлә,— дип кабатлады Альберт.

Бәхәсне кыңгырау тавышы өзде.

?! 2. Хикәягә яңа катнашучылар килеп керде. Аларны, гомумиләштереп, «балалар» диик, чөнки барысы да Деннидан көләләр. Аерма шунда гына: арада котыртучылар да бар.

Бу өзектәге катнашучыларга да бәя бирегез.

3. Өзекне бик кыскартып сөйләсәк, аның нәрсә турында икәнен беләбез. «Нәрсә турында?» соравына «Мыскыл итү турында» җавабын бергәләп табыйк.

Җәй җитте. Балалар каникулда кайларга бару турында гәпләшә башладылар.

Денни бу юлы да, әнисенең киңәшен тотып, юлны аркылы чыкканда сул ягына, аннан соң уң ягына карады. Өч-дүрт минут та үтмәгәндер, үзләренең башлангыч мәктәп ишегалдына килеп керде. Капканы үтүе булды, әтисенең бүген иртән песи турында әйткәне кылт итеп исенә төште. Урта бер җирдә Мэйзи басып тора. Аны бер төркем бала уратып алган. Барысы да, Мэйзи кулындагы муенына кызыл тасма бәйләнгән песинең башыннан сыйпар өчен, кулларын сузалар. Көмеш йонлы, зәп-зәңгәр күзле бик матур песи иде ул.

— Шиншилл песие,— дип горурланып аңлатты Мэйзи. Денни, арага кереп:

— Мин дә башыннан сыйпыйм әле? — диде.

— Сыйпасын инде, юл бирегез,— дип үртәде Альберт.— Аның шиншилл песиен күргәне юк бит. Карамарыга андый песиләр каян килсен!

— Карамарыда әллә ниләр бар! — дип, аңа каршы төште Денни.

— Мәсәлән, ниләр бар?

— Әйтмим, иртәгә әйтермен,— диде Денни. Анда ниләр барын ул үзе дә белми иде.

— Иртәгә дә, берсекөнгә дә әйтә алмыйсың, чөнки Карамары дигән авылның дөньяда булганы юк,— диде тантана белән Альберт.

Балалар гадәттәгечә кычкырып көлделәр.

Укучылар ул көнне дәресләрен юньләп тыңламадылар. Бар сүзләре әлеге зәңгәр күзле, көмеш йонлы песи турында булды. Песи хуҗасы Мэйзи данга күмелде.

?! **4.** Катнашучылар үзгәрмәде. Аларга яңа сыйфатлар өстәлдеме?

5. Бу өзектә вакыйга нәрсә турында?

Көндезге аштан соң Денни әтисеннән:

— Ул Карамарыда ниләр бар? — дип сорады.

— Иң яшел таулар, иң киң болыннар, өстендә болытлар йөзә торган иң чиста күлләр бар.

— Анда песи балалары да бармы?

— Үзең баргач күрерсең.

— Кайчан барабыз соң?

— Кайчан да булса кузгалып чыгып китәрбез. Шунда бабаңның йортын да карап кайтырбыз.

Атасы Деннины шулай, «Кайчан да булса бер...» дип, күп тапкырлар ышандырды инде.

— Ә анда синең үз песиең бар идеме соң?

— Минем үз ишәгем бар иде. Песинең кирәге булмады.

— Ишәгең?

— Нинди ишәк диген әле! Күзләре янып тора, үзе алма чәчәгедәй ап-ак! Йөгәне кызыл күннән. Чаба башласа, артыннан җил дә җитә алмый.

— Альберт әйтә, Карамарыда шиншилл песиләре юк, ди.

— Ул Альбертыңа миннән сәлам әйт тә: «Минем үз ишәгем бар!» — диген.

— Минем үз ишәгем бармыни?

— Мин аны сиңа бүләк итәм.

— Исеме бармы соң аның?

— Аның исеме,— улым, Финниган О' Флэнеган!

Денни кичке догаларын ишәккә багышлады.

?! **6.** Өзек нәрсә турында? Анда катнашучыларга яңа сыйфатлар өстәлдеме?

Икенче көнне ул аннан-моннан гына ашады да мәктәпкә чапты. Альбертны залда эзләп тапты. Янына килеп:

— Карамарыда ишәкләр бар! Шуларның берсе — минеке! — дип кычкырды.

— Нәрсә, нәрсә?

— Минем үз ишәгем бар. Аның исеме — Финниган О' Флэнеган...

Тәнәфескә чыккан балалар ишәк хәбәрен барысы да беләләр иде инде.

— Карамары кебек юк авылда ишәк ничек яши алсын? — дип сорадылар Денниддан.

Денни аларга:

— Аның ияре зәңгәр, йөгәне кызыл, йолдызы көмеш, үзе ап-ак, исеме — Финниган О' Флэнеган! — дип читләтеп җавап бирде.

— Кара син аны, ишәгенең исеме — Финниган О' Флэнеган! Ә үзе ап-ак, ди! Дөньяда ак ишәк буламыни? — дип кабатлый-кабатлый, эчен тотып көлде Альберт.

Денни сүзенә ышанмаучылар күбәйгәннән-күбәйде. Укучылар ишәкнең хикмәтле исемен кабатлый-кабатлый, коридор бетереп чабып йөрделәр.

Дәрес башлангач, укытучы апалары Деннига елмаеп ишарә ясады: ишарә «борыныңны кулъяулык белән сөрт» дигәне аңлата иде. Денни алдагы партада утыра. Ул борынын учы белән сөртергә җыена иде. Борыны борын, үртәү-мәсхәрәләрдән аның күңеле тулды. Борын мышкылдавын сыйныф гафу итә ала. Мышкылдаучылар аларның үз араларында да җитәрлек. Ә менә елавыңны күрсәләр — беттең, мәсхәрәле кушаматтан мәңге котыла алмыйсың. Денни күз яшьләрен көч-хәл белән генә тыеп торды.

Укытучы, аңа карап, тагын бер тапкыр елмайды. Дәресне башлап җибәрсә дә, Деннины елатырлык сәбәпләр турында уйланды. Бу баланы ярата иде ул.

Озын тәнәфестә ул Деннины чакырып алды да түшенә яшел клевер кадады.

— Яшел клевер бәхет китерә,— диде.

— Рәхмәт, апа. Сорау бирергә мөмкинме?

— Рәхим ит, сора.

— Сезнең ак ишәк күргәнегез бармы?

— Бер дә очратканым юк шул, Денни.

— Ак ишәк буламы?

— Була, билгеле. Ләкин бик сирәк очрый,— диде укытучы. Бәхет китерә торган клеверы белән канатланып, Денни урамга йөгерде. Альберт яныннан үткәндә:

— Мисс Дейли әйтте, ак ишәкләр бик сирәк очрый, диде. Ишетәсеңме? Финниган О' Флэнеган да — сирәк очрый торган ишәк. Аның тояклары алтындай ялтырый. Ә койрыгында — гөлчәчәк! — дип кычкырып үтте.

Шул көннән башлап, мәктәптә ишәк турында Деннига әтисе сөйләгән яңадан-яңа хәбәрләр ишетелеп торды. Ышанучылар да, ышанмаучылар да яңа хәбәрләрне бик кызыксынып тыңладылар. Ак ишәкнең чабышта катнашып җиңүе турында да, урам чатында король кызын ярсыган үгездән коткарганы өчен медаль алуы турында да, төннәр буе акырып, өйдән төрле җен-пәриләрне кууы турында да, ун юньле кеше арасында бер генә юньсезе булса да, аны шунда ук абайлап алуы һәм янына якын да китермәве турында да ишеттеләр.

— Әллә-лә,— диделәр ышанучылар.

— Үллү-лү,— диделәр ышанмаучылар.

Ләкин тегеләре дә, болары да яңа хәбәрләрне яратып тыңладылар. Матур хәбәр, — хәтта бик үк дөрес булмаса да, барыбер матур хәбәр бит ул. Ак ишәкнең барлыгына ышанмасалар да, хәзер ул тиңе булмаган батырга әйләнде.

Тагын җәй житте. Быел да каникулларын кайсы кая үткәрү турында сүз кузгата башладылар. Деннидан да:

— Ә син кая барасың? — дип сорадылар.

— Беркая да бармыйм,— диде Денни.

— Әһә, алай беркая да бармагач, син үзегезнең Карамарыга китәсең икән, — дип мыскыл итте Альберт.

— Хәзер үк тукта, Альберт! — дип, көтмәгәндә Деннины яклады Мэйзи. Капкадан ул Денни белән бергә чыкты. Житмәсә, ак ишәкнең барлыгына ышануын белдереп, Финниган турында сөйләвен үтенде.

Деннига шул гына кирәк тә. Үз-үзен белештерми сөйләде дә сөйләде:

— Берзаман әти урманда адаша. Төн уртасы. Күзенә берни күренми. Аны ишәге коткара. Финниганның күзләре фонарь кебек яктырта башлый. Әти шул ут яктысында кайтыр юлын таба. Аның тамагы ача...

Альберт артларыннан килә икән.

— Нигә соң ул куян атмаган?

— Ул чакта әти минем яшьтә генә булган әле.

— Әтиеңә хәзер ничә яшь? — дип, һөҗүмен дәвам итте Альберт.

— Илле ике.

Альберт, башкаларга карап:

— Алайса, ул ишәк әллә кайчан гүрдә ята инде. Ишәкләр егерме ел гына яши,— диде.

?! **7.** Альбертка бәя бирегез. Аның ни өчен Деннига шулай ярсып каныгуын аңлатыгыз.

8. Өзектә Деннины яклаучылар барлыкка килде. Укытучы белән Мэйзи ни өчен аны яклыйлар?

Денни җавап таба алмады. Альбертның күзенә туп-туры карап торды-торды да купкан шау-шудан качты. Өйләренә ул елый-елый кайтып керде. Алай була алмый. Ишәк әллә кайчан үлгән булса, әтисе аның турында сөйләр идемени?

Икенче көнне аның ни өчен мәктәпкә килмәвен укытучыга Мэйзи сөйләп бирде.

Укытучы Денниларга шул кичне үк килде. Әнисен күргәч:

— Деннины хәлен белергә килдем. Без бик борчылабыз. Хәле бик начармы? — дип сорады.

— Әйбәт түгел шул. Бер дә әйбәт түгел. Теләсәгез, күрә аласыз.

Денни укытучысын танымады. Ул, берөзлексез «Финниган» сүзен кабатлап, нидер сөйләнде дә сөйләнде. Укытучы күзенә бераз карап торгач:

— Үлмәде Финниган! Үлмәде! — дип кычкырды. Мисс Дейли хәлне аңлады. Чыгып барганда, Деннины әтисе очрады. Ул укытучыга, берни яшермичә, барын да сөйләп бирде. Ишәк койрыгындагы гөлчәчәктән башлап Финниганны үзе уйлап чыгаруына хәтле әйтеп бирде.

— Денни ак ишәк хыялы белән шулхәтле мавыгып китте. Кызганычка каршы, мин аңа яңадан-яңа

җыен тузга язмаган нәрсәләр сөйләдем дә сөйләдем.

Улына юк нәрсәләрне бар итеп сөйләгәне өчен үкенүен әйткәндә, әти кеше күз яшен тыя алмады, елап җибәрде. Укытучы да түзмәде, ул да елады.

— Мин иртәгә авылыма кайтып китәм. Аннан хат язармын,— дип чыгып китте.

?! 9. Өзек нәрсә турында?

Авылында Дейли Фрэнк исемле ялга кайткан хәрби егет белән танышты. Күп тә үтмәде, алар бер-берсен яратып та өлгерделәр.

Фрэнк бик оста фотограф булып чыкты. Алар каникулның җиденче көнендә торф кисүчеләрне фотога төшерергә килделәр. Торфчыларның шактый картайган ишәкләре бар икән. Шуны чирәм белән сыйлаганда, кинәт Дейлиның вәгъдәсе исенә төште. Ул хат язарга оныткан иде.

Ә тагын өч көннән ул үзе хат алды. Хәлне Фрэнкка сөйләде.

— Денни — минем яраткан укучым. Аны больницага салганнар. Бертуктаусыз Финниганны чакыра икән. Ул әкиятләрдә генә була ала торган кызыл күзле, алтын тояклы, гөлчәчәкле ишәгенә шулкадәр ияләшкән, хәзер шул үлде дип саташа икән. Әгәр шундый ишәгем булса, мин аңа һичсүзсез бүләк итәр идем, — диде дә күз яшьләрен тыя алмыйча, кычкырып елап җибәрде. Бераз тынычлана төшкәч:

— Аны хәзер исән ишәк рәсеме генә тынычландыра ала,— дип өстәде.

— Кулдан килми торган эш түгел бит ул. Иртәгә кояшлы көн булсын дип телә. Ә көндез шушы урынга кил, берәр җаен табарбыз,— диде Фрэнк.

Икенче көн кояшлы, аяз булды. Сөйләшкән урында аны Фрэнк көтеп тора иде инде. Дейли шаккатты. Фрэнк янында кызыл күзле, алтын тояклы ап-ак ишәк басып тора. Ә тегесе аның койрыгына ефәк гөлчәчәк бәйли.

— Сезгә теп-тере Финниган О' Флэнеган бүләк итәргә рөхсәт итегез. Тик кулыгыз белән кагыла күрмәгез, буявы кибеп җитмәде әле. Йә, ошыймы?

Дейли аның ниятен шундук аңлап алды.

— Искитмәле! Фотоаппаратың мондамы?

Фрэнк аңа ишәк койрыгындагы чәчәкне иснәп торырга кушты.

— Янына син дә бассаң, ак ишәкнең исән-сау булуына бала берсүзсез ышаначак,— диде.

Укытучы, ишәк койрыгындагы гөлчәчәкне кулына тотып, фотога төште.

— Бик шәп! Ике данә эшлик тә берсен укучыңа җибәрик.

Көзен укулар башланганда Денни терелеп җитмәгән булса да, аның дәрескә кайчан киләсен балалар белә иде инде. Укытучы апалары, авылдан кайту белән, Денниларга сугылган иде.

Култыгына шактый зур пакет кыстырып, сыйныфка Денни килеп керде.

— Нәрсә ул? — дип сикереп торды Альберт.

— Минем ишәк. Финниган О' Флэнеган! — диде Денни.

Аны урап алдылар. Денни пакетыннан алма чәчәгедәй ап-ак ишәк фотосын тартып чыгарды. Балалар гаҗәпләнүдән телсез калдылар. Рәсемдә кызыл күзле, алтын тояклы ишәк басып тора иде. Койрыгындагы чәчәкне үз укытучылары иснәп торуын да күргәч, ишәкнең чынлыгына берәүнең дә шиге калмады.

— Әллә-лә,— диделәр берьюлы ышанучылар да, ышанмаучылар да.

— Кара-кара, монда укытучы апа да басып тора бит! Апа, рәсемдә чынлап та сезме? — дип сорады Мэйзи.

— Әлбәттә, мин,— диде арттан бу күренешне елмаеп күзәткән апалары.

— Сезнең яндагы ишәк чыннан да Финниганмы?

— Шул үзе, әлбәттә,— диде укытучылары һәм Финниган турында үзе уйлап чыгарган әллә никадәр матур вакыйгалар сөйләп алды. Аның сүзләренә ышанмаска мөмкин түгел иде. Ул бит ишәкне үз күзләре белән күргән кеше!

Альберт кына, уйларының очына чыга алмыйча, читтә басып торды. Ниһаять, түзмәде:

— Денни ишәген Карамарыда дигән иде, ә сез Бәллинахка китәргә җыенган идегез бит,— диде.

— Шуны да белмисеңмени, Альберт?! Карамары — Бәллинахның борынгы исеме бит.

— Карамары авылы чыннан да бармыни? — дип төпченде Мэйзи.

— Бар, әлбәттә. Мин үзем шул авылда тудым.

Альбертның соңгы дәлиле дә расланмады. Ул үзенең оттыруын аңлады. Аның хур булып җиңелүен бөтен сыйныф күреп торды.

Ләкин Денни тантанасы аның белән генә дә тәмамланмады әле. Балалар укытучы апаларының бармагында алтын балдак күреп алдылар. Өч-дүрт көн үтүгә, мәктәпкә хәрби офицер килеп керде. Аның Финниган турында сөйләгәнен ишетсәгез, исегез-акылыгыз китәр иде. Ул Денниның әтисеннән дә, хәтта укытучы апаларыннан да уздырып җибәрде. Өстәвенә кунак офицер, Яңа ел бүләге булсын дип, балаларны театрга чакырды.

Гыйнвар шимбәсе иде. Ул көнне Альберт, балаларга урын күрсәтеп йөргән алтын пинжәкле кечерәк буйлы кешене күргәч, гаҗәпләнүеннән егылып китә

язды, чөнки Деннинең: «Сәлам, әти!» — диюенә теге кеше елмаеп күз кысты. Ул, чыннан да, Деннинең әтисе булып, пинжәге дә, нәкъ Денни әйткәнчә, алтын белән чигелгән иде.

Элинор Фарджон.

?! **10.** Менә сез соңгы өзекне дә укып чыктыгыз. Хәзер хикәя өзекләрен кушып, бер вакыйга итеп сөйләгез.

11. Хикәяне ике өлешкә бүлсәк, беренчесенә «Ялганчының матурлыгы», ә икенчесенә «Хаклының ямьсезлеге» дип исем биреп була. Шуны исбат итегез.

12. Бу хикәядә авторның теләге нинди?

СЕҢЛЕМ АК КАЕН.

Дөньяның мин күрдем суын, күлен,
Урманнарын, тавын, чүлләрен...
Тик күрмәдем, Идел, синең кебек
Сагындырган ягын күрмәдем.

?! **1.** Беренче дүртьюллыкны үз сүзләрегез белән әйтегез. Аңа исем бирегез.

2. Дүртьюллыкны ике өлешкә бүлегез. Өлешләр арасындагы бәйләнешне табыгыз.

3. Шигырьнең бу дүртьюллыгын дәрестә ятлагыз.

Читләтмәде мине, кимсетмәде
Җир йөзенең һичбер имәне;
Тик берсе дә сезнең кебек итеп:
«Улым, бәгърем, бәбкәм», — димәде.

Ак каеннар азмы далаларда,
Яландагы олы юлларда?..
Беркайда юкләкин сезнең сыман
Сагындырган каен,— беркайда!

?! **4.** Икенче, өченче дүртьюллыкларга да беренчесе кебек анализ ясагыз.

Арыды бугай сезне сагынып йөрәк,
Арыды бугай газиз башкаем.
Яшел шәлең белән күләгәләп
Ял иттер бер, сеңлем ак каен.

Хәсән Туфан.

?! **5.** Шигырьне тулы көе укып чыгыгыз. Баштагы өч дүртьюллыкны, кушып, бер генә өлешкә калдырыгыз. Ягъни барысына бер уртак исем бирегез.

6. Соңгы дүртьюллыкны өйдә ятлагыз.

7. Авторның теләген әйтегез.

БАЛЫКЧЫ ҺӘМ БАЛЫК ТУРЫНДА ӘКИЯТ.

Зәңгәр диңгезнең нәкъ кырыенда
Карт белән карчык яши булганнар;
Искереп беткән бер землянкада[1]
Нәкъ утыз өч ел бергә торганнар.
Карт балык тоткан зур җәтмә белән,
Җеп эрли булган аңарга карчык.
Бервакыт картка диңгез төбеннән
Чыккан җәтмәдә бары тик балчык;

[1] **Землянка** — җирне казып эшләнгән өй.

Икенче тапкыр җәтмәсе чыккан,
Диңгез үләне белән чорналып;
Өченчесендә бер Балык чыккан,—
Тик гади түгел, ә Алтын балык.
Кеше күк шунда ул телгә килгән,
Картка ялынган: «Җибәр, дип, мине!
Ни теләсәң дә бирермен, дигән,
Җибәрсәң мине диңгезгә кире».
Куркуга төшкән карт, моны күреп:
Нәкъ утыз өч ел балык тоткан ул,
Ләкин балыкның кешеләр кебек
Сөйли торганын очратмаган ул.
Шунда Балыкны җибәргән суга,
Ягымлы итеп, карт җавап биргән:
«Бар, Алтын балык, хәерле юлга!
Бернәрсә дә мин сорамыйм, дигән.
Үзеңнең, дигән, диңгезеңә кит,
Иркенләп шунда рәхәт гомер ит!»
Бу зур хикмәтне кайтуы белән
Сөйләп биргән карт, хәйранга калып:
«Бер Балык тоттым бүген мин, дигән,
Тик гади түгел, ә Алтын балык.
Шунда кеше күк ул телгә килде:
Җибәр син мине диңгезгә, диде;
Бирермен, диде, теләгән нәрсәң,
Зәңгәр диңгезгә кире җибәрсәң.
Әйбер сорарга күңел бармады,
Шул килеш кенә җибәрдем аны».
Шунда карчыгы тиргәгән картны:
«Юләр син, дигән, ахмак, беркатлы!

Алтын балыктан, һич юк дигәндә,
Яңа тагарак сорыйсың калган.
Күреп торасың инде үзең дә,—
Тагарагыбыз тәмам ярылган».

Диңгез буена карт тагын барган
(Диңгез аз гына чайкала икән),
Алтын балыкны чакыра башлаган,
Балык шунда ук килеп тә җиткән.
«Ни кирәк сиңа, карт кынам?» — дигән.
Аңа баш иеп, карт җавап биргән:
«Кызган син мине, Алтын балыгым!
Бик нык тиргәде мине карчыгым.
Мин карт кешегә тынгылык бирми,
Яңа тагарак кирәк миңа, ди.
Ярылып беткән безнең тагарак».
Ә Балык әйткән, аңарга карап:
«Бар, хәерле юл! Кайгырма бер дә!
Яңа тагарак булыр өеңдә».

Карт кайткан икән карчык янына,
Яңа тагарак — карчык алдында.
Карчык ныграк кыздырган картны:
«Юләр син, дигән, ахмак, беркатлы!
Тагарак сорап алып кайткансың!
Аннан кешегә күпме файда соң?
Балык янына хәзер тагын бар,
Барып, баш иеп, бер өй сорап ал!»

Диңгез буена карт тагын барган
(Зәңгәр диңгезнең өсте болганган),
Алтын балыкны тагын чакырган,
Ә Балык килеп сораган аннан:
«Ни кирәк сиңа, карт кынам?» — дигән.
Баш иеп тагын, карт җавап биргән:
«Кызган син мине, Алтын балыгым!
Тагын тиргәде мине карчыгым.
Мин карт кешегә бирми тынычлык:
Бер өй кирәк, ди, ул явыз карчык».
Ә Балык әйткән: «Бер дә көенмә,
Бар, тынычлап кайт, булыр өең дә».

Землянкасына карт кайтып киткән,
Ә землянканың эзе үк беткән.
Аның урынында инде тора, ди,
Кирпеч морҗалы, чарлаклы[1] бер өй.
Имән генә, ди, капкалары да,
Карчык тора, ди, тәрәз янында.

---

[1] Чарлак — йортның алгы ягында бизәп ясалган балкон.

Шунда ул тагын тиргәгән картны:
«Юләр син, дигән, ахмак, беркатлы!
Ни дип сорадың аннан бу йортны?
Бар, тагын аңа баш иеп сөйлә:
Булмыйм мин надан авыл хатыны,
Зур бер байбикә буласым килә».

Диңгез буена карт тагын барган
(Диңгезнең өсте тынычсызланган),
Алтын балыкны чакырып алган.
Балык шулчакта сораган аннан:
«Ни кирәк сиңа, карт кынам?» — дигән.
Тагын баш иеп, карт җавап биргән:
«Кызган син мине, Алтын балыгым!
Тәмам котырды минем карчыгым,
Авыл хатыны буласы килми,
Булырга телим зур байбикә, ди».
Ә Балык әйткән: «Бер дә көенмә,
Барсы да булыр, бар кайт өеңә».

Карт тагын кайткан карчык янына.
Ни күрсен: бай йорт тора алдында.
Баскычка чыгып, карчыгы баскан:
Муенына ул энҗеләр аскан,
Кыйммәтле камзул аның өстендә,
Укалы калфак баш түбәсендә,
Бармакларында — алтын йөзекләр,
Аякларында — кызыл читекләр,
Хезмәтчеләре торалар алда,
Үтиләр аның йомышын бар да,
Кыйный аларны, өстерәп чәчтән.

Шунда карт аңа болай дип дәшкән:
«Нихәл, байбикә, исәнме, саумы?
Ничек соң хәзер, күңлең ризамы?»
Карчык аңарга акырган гына,
Эшкә җибәргән ат абзарына.

Атна артыннан атналар үткән,
Карчык бөтенләй котырып киткән:
«Бар,— дигән картка,— тагын диңгезгә,
Башыңны иеп, Балыкка сөйлә:
Буласым килми байбикә генә,
Ирекле патша буласым килә».
Карт куркып әйткән: «Нәрсә сөйлисең,
Тилердең мәллә бөтенләй, карчык?
Йөри белмисең, сөйли белмисең,—
Көләр үзеңнән бөтен патшалык».
Карчык бу сүзгә ярсыган гына,
Салып җибәргән бер яңагына:
«Ничек кыясың тарткалашырга
Мужик башыңнан минем каршымда?
Юньләп әйткәндә, тизрәк барып кал,
Юкса якалап алып барырлар».

Диңгез буена карт тагын барган
(Диңгезнең өсте тәмам каралган),
Алтын балыкны тагын чакырган,
Ә Балык килеп сораган аннан:
«Ни кирәк тагын, карт кынам?»— дигән.
Тагын баш иеп, карт җавап биргән:
«Кызган син мине, кодрәтле Балык!

Тагын гаугалый бит явыз карчык,
Байбикә генә буласы килми,
Ирекле патша булсам иде, ди».
«Кайт,— дигән Балык,— теләп изге юл,—
Карчыгыңа әйт, булыр патша ул».

Карчык янына карт кире кайтса,
Патша сарае тора алдында.
Сарай эчендә, булып зур патша,
Карчык утыра өстәл янында;
Боярлар[1] белән дворяннар[2] шунда
Хезмәт итәләр аның каршында;
Эчә кыйммәтле эчемлек кенә,
Ашый пичәтле прәннек[3] кенә.
Усал сакчылар балталар тотып
Басып торалар тирә-ягында;
Бу хәлне күргәч, карт тәмам куркып
Егыла аның аякларына:
«Гайрәтле патша, исәнме, саумы?
Әйт инде: хәзер күңлең ризамы?»
Күз дә салмаган карчык аңарга,
Күз алдыннан ук кушкан куарга.
Шунда боярлар һәм дворяннар,
Җилкәләп алып, картны сөргәннәр,
Ишек төбендә торган сакчылар
Чак кына чабып үтермәгәннәр.

---

[1] Боярлар — аеруча бай дворяннар.
[2] Дворяннар — элеккеге байлар, җир хуҗалары.
[3] Пичәтле прәннек — өстенә бизәкләр төшерелгән прәннек.

Ә халык көлгән, аңарга карап:
«Шул кирәк менә, юләр, сиңа, дип,
Киләчәк өчен булыр бу сабак.
Утырма кеше чанасына»,— дип.

Атна артыннан атналар үткән,
Карчык котырган, үтеп бар чиктән:
Боерган беркөн хезмәтчеләргә
Тизрәк тагын картны эзләргә.
Һәм алар картны эзләп тапканнар,
Карчык янына алып кайтканнар.
Шунда карчыгы боерган картка:
«Бар, башың иеп, Балыкка сөйлә:
Буласым килми ирекле патша,
Диңгез патшасы буласым килә,
Океан-диңгездә торасым килә.
Ә Алтын балык булсын хезмәтчем,
Йомышка йөрсен, үтәп һәр эшем».

Карт аңа каршы бер сүз әйтмәгән,
Каршы килергә көче җитмәгән.
Диңгез буена тагын барган ул.
Барса, диңгездә кап-кара давыл:
Йөгерә анда зур-зур дулкыннар,
Ачулангандай ярсый, улыйлар.
Тагын Балыкны чакырып алган.
Балык тиз килеп сораган аннан:
«Ни кирәк булды, карт кынам?» — дигән.
Тагын баш иеп, карт җавап биргән:
«Алтын балыгым, кызган син мине,
Явыз карчыкны нишләтим инде?

Ирекле патша буласы килми,
Диңгез патшасы булсам иде, ди,
Океан-диңгездә торсам иде, ди.
Алтын балык, ди, булсын хезмәтчем,
Йомышка йөрсен, үтәп, ди, эшем».
Җавап бирмәгән Балык һич моңа,
Күрсәтеп аңа койрыгын гына,
Диңгез төбенә чумган да киткән.
Карт шунда аны бик озак көткән.
Чыкмагач кайткан карчык янына,
Тагын землянка күргән алдында;
Карчык утыра, диңгезгә карап,
Алдында ята ярык тагарак.

Александр Пушкин.
Әхмәт Исхак тәрҗемәсе.



?!

1. Әкиятне тулысы белән сөйләп чыгу өчен, план төзегез.
2. Авторның теләген әйтегез.

Мәкальләр.

- Башка берәүдән гаеп табып сөйләгәнче,
Башта үзеңнең аяк киемеңә кара.

- Минем арттан йөрмә:
Минем алдынгы булмавым бар.

Минем алда йөрмә:
Минем яхшы иярүче булмавым бар.
Янымнан барсаң — без тиң булырбыз.

?! Менә шундый үзенчәлекле мәкальләрнең авторлары — Америкада яшәүче индеецлар. Алар үз ыругдашларына нәрсә әйтергә телиләр? Мәкальләрне үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

МОҢСУ БӘЙРӘМ.

Яз сулышы белән бергә
Бәйрәм йөри авыл буйлап.
Тик әбием нигә болай
Яшен сөртә авыр сулап?

Ник моңая бүген әбкәм?
Нигә болай кайгыра ул?
Җиңү көне — моңсу бәйрәм,
Куаныч та, кайгы да ул.

Мин чәчәкләр җыям аңа —
Бүлмәсенә ямьнәр тулсын.
Җиңү белән бергә илгә
Улы кайткан кебек булсын...

Резеда Вәлиева.

?! **1.** Җиңү бәйрәме ни өчен куаныч?

Бу бөек бәйрәмнең ни өчен куаныч булуын аңлатыгыз. Моның өчен шигырьдәге әби һәм үзегезнең әбиегез булып уйларга тырышыгыз. Алар сугыш

бетте дигән хәбәрне дүрт ел буена көттеләр. Сугыш бетсә, ирем, балаларым исән-сау кайтырлар иде, дип өметләнделәр һәм якыннарының сугыштан кайтуын түземсезлек белән көттеләр.

Шул вакыттагы шатлыклар, якты өметләр, түземсезлек белән көтү хисләре — барысы да безнең әбиләрнең күңелендә мәңге онытылмаслык куаныч булып саклана. Җиңү бәйрәме якынлашкан саен, ул хисләр кабат көчәя.

?! 2. Җиңү бәйрәме ни өчен кайгы?
3. Лирик герой теләген әйтегез.

БАЛТА НИЧЕК ҮЗЕНӘ САП ЯСАГАН?

Балта үз хуҗасына
Бик озак хезмәт иткән.
Сабы аның ахырда
Ярылып, бушап беткән.

Хуҗасы кызып кына
Юнып яткан чагында,
Төшә башлаган балта,
Тора алмый сабында.

Телгә килеп беркөнне
Әйткән ул хуҗасына:
— Минем белән эшләве
Җайсыз бит, хуҗам, сиңа!

Болай булса, безнең эш
Беркөн туктап калачак.
Иске сапны ташла да
Куй син миңа яңа сап!

— Шулай,— дигән хуҗасы,—
Дөреслек бар сүзеңдә.
Уйлый идем мин күптән
Бу турыда үзем дә.

Ләкин син бит, балта дус,
Барсын эшли аласың:
Агачын да кисәсең,
Тактасын да ярасың.

Теләгәндә син үзең
Хәтта йорт та саласың.
Неужели үзеңә
Бер сап ясый алмассың?..

Бу сүзләрне ишеткәч,
Балта, барып урманга,
Кисеп кайткан бер саплык
Һәм керешкән юнарга.

Эшләгән ул шулкадәр
Дәртләнеп һәм тырышып,
Тирә-якка йомычка
Очкындай торган очып.

Баш-башларын кисәргә
Пычкы дусты булышкан.
Тигезләргә ян-янын
Ышкы дусты булышкан.

Сап ясалып бетүгә,
Шкурка белән игәү
Шомартканнар бар җирен,
Тырышып шунда икәү.

Яңа сапны шуннан соң
Хуҗасы кулга алып,
Матурлыгына аның
Карап торган сокланып.

— Афәрин! — дигән хуҗа,
Балтаның эшен мактап,
Һәм тотынган эшләргә,
Куеп аңа яңа сап.

Һәм әйткән оныгына:
— Шундый тырыш ул менә!
Нинди матур яңа сап
Ясап куйды үзенә!

Син дә, улым, үрнәк ал
Шушы тырыш балтадан:
Үзең эшли алганны
Көтеп ятма башкадан!

Әхмәт Исхак.

Шагыйрь Әхмәт Исхак та теләген турыдан-туры әйтеп биргән. Дөрес, үгетне ул улына бирә, ләкин без бит «Улым, сиңа әйтәм, кызым, син тыңла» мәкален яхшы беләбез.

Автор теләге мәкаль белән мәсәлләрдә генә күренеп тора. Башка жанр әсәрләрендә аны эзләп табасы бар әле.

ӨЧ СОРАУ.

Борын-борын заманда бар иде, ди, бер ятим егет. Бар иде моның ике өе: аның берсе кешенеке, икенчесе күршенеке иде, өйләре салам белән мукләгән, күк белән терәткән иде, ди. Көннәрдән бер көнне менә шушы егет, эш эзләргә дип, читкә чыгып китә. Көн китә бу, төн китә. Шулай бара торгач, барып җитә ашлык чәчеп йөрүче бер кеше янына. Егет әйтә:

— Эшләрең уң булсын, уңышларың мул булсын, абзый кеше,— ди.

— Шулай булсын, улым,— ди теге кеше. Аннары юлчы егеттән сораша башлый: — Каян киләсең, кай җирләргә барасың?— ди.

Егет:

— Эш эзләргә чыктым, абзый кеше,— ди. Шуннан соң игенче әйтә:

— Ярар, егет, ди, эш кешесенең эштә, юл кешесенең юлда булуы яхшы, ди. Уйлана-уйлана барсаң, юлың кыскарак булыр, мин сиңа бер-ике хикмәтле сүз әйтим, җавабын уйлап таба алсаң килеп әйтерсең,— ди.

— Ярар, абзый,— ди егет,— әйтеп кара,— ди. Теге кеше, тубалын асып, ашлык чәчәргә тотына. Уч тутырып, ашлык ала да чәчеп җибәрә.

— Менә бер тапкыр чәчтем, бусы бурычымны түләргә булыр,— ди. Икенче мәртәбә сибеп җибәрә дә: — Менә монысы бурычка биреп торуым,— ди. Шуннан өченче тапкыр чәчеп җибәрә дә: — Монысы кадерле кунакларым өчен,— ди.

Егет уйга кала: «Бу нәрсә булыр икән?» — ди.

— Ярар, абзый,— ди егет,— син миңа бераз гына уйларга бир,— ди.

— Уйла-уйла, улым,— ди игенче, шулай ди дә ашлыгын чәчеп китә. Озак та үтми, әйләнеп килеп җитә дә егеттән сорый:

— Йә, нихәл, улым, ниләр уйладың?— ди.

— Абзый кеше,— ди юлчы егет,— синең соң эти-әниләрең бармы?

— Бар,— ди теге.

— Яшь вакытыңда алар сине тәрбияләгәндер бит? — ди егет.

— Тәрбияләделәр,— ди игенче.

— Алайса, беренче чәчкәнең аларны тәрбияләү өчен булды.

— Дөрес әйтәсең, улым, беренчесен шулай бурычымны түләр өчен чәчтем.

— Синең ир балаларың бармы? — ди егет.

— Бар,— ди теге кеше.

— Алай булгач, икенче тапкыр чәчкәнең, чыннан да, бурычка биреп тору була, хәзергә син балаларыңны тәрбиялисең, ашатасың-эчертәсең, алар сиңа бурычлы булып калалар,— ди.

— Бусын да бик дөрес әйттең,— ди игенче.

— Синең кызларың бармы? — дип сорый егет.

— Бар,— ди.

— Алар синең кадерле кунакларың кебек кенә, үсеп җитү белән, синнән китәләр бит алар,— ди егет.— Өченче тапкыр чәчкәнең әнә шул кадерле кунакларың өчен булды,— ди.

— Бик дөрес әйтәсең, тапкыр егет икәнсең,— ди игенче, егетне мактап.

?! Әкият авторы безгә нинди теләк тели?

БАТЫР БЕЛӘН МАЛАЙ.

Кайчандыр берзаман Кытай императоры сараенда Алып батыр яшәгән.

Тәнгә бик көчле булса да, акыл ягы сай икән моның. Ник дисәң, дөньяда миннән дә куәтлерәк кеше юк дип уйлый икән.

Көннәрнең берендә моның янына буе билдән дә булмас бер малай килгән. Исе дә китмичә, әйдә, көчләрне сынашыйк, ди икән малай.

— Бу кадәр дә ахмак кешене күргәнем юк иде әле. Бармагым белән чиртсәм дә, бу дөньядан юк буласың бит! — дип гаҗәпләнгән Алып.

— Алай да, әйдә, көчләрне сынашып карыйк әле, — дип кабат әйткән малай.

Алыпның ачуы чыккан. «Кайдан килгән бу хәчтерүш мактанчык? Ярый, сынашырбыз. Ялгыш имгәтәнитә калсам, үзенә үпкәләр», — дип уйлаган Алып. Һәм көч сынашырга риза булган.



Малай ярыш шартын әйткән: «Менә шушы биек койманың аргы ягына салам ыргытыйк. Кем ыргыта ала, шул җиңгән була»,— дигән.

Алып батыр саламын киерелеп торып ыргыткан. Җил җиңел саламны, шунда ук өреп, бу якка чыгарган.

Малай саламны, бөкли-бөкли, учына җыеп туп иткән дә үлән белән бәйләп куйган. Аннары, салмак кына атып, койманың аръягына төшергән.

— Йә, кем көчлерәк булуын белдеңме инде? — дип сораган малай. Алып хурланган, малай ягына әйләнеп тә карамаган.

— Ышанмыйсыңмы әллә? Әйдә, алайса, көчеңне күрсәт. Әнә теге таш өстендәге кырмысканы үтер,— дигән малай.

Алып күп уйлап тормаган, ачу белән, ташка берне шундый итеп тондырган, уч төбенең авыртуына түзә алмыйча бөгелеп төшкән. Ә кырмыскага берни булмаган. Үз юлыннан чаба биргән.

Малай ташка бармак очы белән йомшак кына итеп баскан — кырмыска юк булган. Моны күреп, Алып шундый хурланган, шундый хурланган, артына да әйләнеп карамыйча, патша сараена кереп киткән.

?! 1. Әкиятнең идеясен әйтегез.
2. Әкияткә башка исем уйлап табыгыз.

НАДАН.

Фәрит мәктәптән кайтып килә иде. Каршы якта урам чатында юлны аркылы үтмәкче булып талпынган бер этне күреп туктап калды. Менә туп-туры тәгәрмәч астына ташланырга тора, юләр маэмай!

Малай, юлны кисеп, теге якка йөгерде. Урам буйлап зур тизлек белән килүче машиналар шунда ук шып туктадылар. Автобуслар, троллейбуслар, хәтта трамвайлар да тормоз бирде. Йөртүчеләре тәрәзә аша йодрык яный. Берсе, ишегеннән башын чыгарып:

— Тапталасың бит, малай актыгы! — дип кычкырды. Урам хәрәкәтен күзәтеп торучы милиционер абый, каты итеп, сыбызгысын сызгыртты. Чын таптала иде бит, каһәр суккыры эт! Ярый әле Фәрит вакытында күреп калды.

Тротуарга чыкканда да әле теге тәртипсез маэмай выж-выж үтеп торучы машиналар арасыннан урамны аркылы үтмәкче булып азаплана иде.

— Нәрсә син, ахмак! — дип, Фәрит аңа төртеп җибәрде, эт шыңшып, шунда ук тротуарга менеп басты. Үзе тагы качмый да, гафу үтенгән сыман, күзләрен мөлдерәтеп, Фәриткә карап тора, кыяр-кыймас кына, койрыгын болгый. Кызганып куйды Фәрит аны. «Нинди башсыз эт икән соң бу? Каян килеп чыккан ул монда, шаулый торган үзәк урамга?» — дип баш ватты малай. Аннан «Урам тәртибен дә белми, авыл этедер, адашкандыр» дигән фикергә килде.

Тигәнәккә батып беткән ала эт белән күзгә-күз карашып торганда, Фәрит янына милиционер килеп туктады. Шул, сыбызгы сызгыртып, тәртип саклап торучы абый. Ул Фәритләр сыйныфына кереп, балаларга урамда йөрү кагыйдәләрен дә өйрәтеп чыккан иде.

— Ни өчен тәртип бозасың?

Бу сүзне милиционер эткә әйтте дип уйлады Фәрит һәм:

— Ул, абый, адашкан булырга кирәк, авыл эте,— дип тезеп китте.— Ул белми... Аның гаебе юк... — дип, этне якларга ук керешге.

— Сиңа әйтәләр: ни өчен урам тәртибен бозасың? — дип кабатлады милиционер.

Аның кырыс йөзен күргәч, бөтенләй коелып төште Фәрит.

— Минме? Мин бозмадым... Эт тапталмасын дип, аны коткарырга гына чыктым...

Милиционер, ни әйтергә белмичә, Фәриткә карап торды да: «Белмим инде сезнең белән нәрсә эшләргә?»— дип, мыгырданып, сумкасыннан блокнотын чыгарды.

— Кайда торасың?

Малайның әйткәннәрен милиционер язып куйды. Фәритнең кулындагы портфеленә күзе төшкәч, тагын сорады:

— Кайда укыйсың?

— 8 нче мәктәптә. 2 нче сыйныфта.

Малайның чаялыгы милиционерны шиккә төшереп куйды, күрәсең:

— Ялганламыйсыңмы? — диде, Фәриткә туп-туры текәлеп.

— Сез үзегез дә безгә кергән идегез... Тактага түгәрәкләр сызып күрсәттегез... Светофор ясап...

Милиционер, шартлатып, сумкасын ябып куйды.

— Светофор, светофор! Өйрәткәч тыңлыйлар аны! — дип, үз урынына китеп барды.

Ә эт һаман шул тирәдә буталып йөри иде әле. Бичара, берничә адым китә дә тирә-ягына карап тора, аннан тагын килә, эзләрне, узган-барган кешеләрнең аякларын, киемнәрен иснәп ала һәм үзе әкрен генә шыңшый иде. Елый...

Хуҗасын югалткан икәненә Фәритнең шиге калмады. Янына килгәч, эт шатланып киткәндәй булды, күптәнге танышыдай малай тирәсендә сырпалана, койрыгын болгый башлады. Фәрит аның башын сыйпады, сыртындагы алама йоннарын рәтләп куйды, тигәнәкләрен алып ташлады.

— Исемең ничек синең? Дәшмисеңме? Ничего, кайгырма, табарбыз! Әйдә, калма минем арттан!

Күрәсең, эт урамда шактый адашып йөргән, арыпталып беткән, аңа ачык чырай күрсәтүче дә, игътибар итүче дә булмаган — һичкарусыз малайга иярде.

Фәрит, этне ияртеп, өйләренә таба китте. Башка вакытта булса, трамвайга гына утырып кайтыр иде дә бит, этне кертмиләр. Эт үзе дә, машина янына барырга булса, теше-тырнагы белән каршы. Тартыша, чиный башлый. Авыл эте авыл эте шул инде.

— Сиңа, йонлачкаем, шәһәр эте булу өчен, бик күп кирәк шул әле, бик күп! — дип, Фәрит этнең борынына төртеп куйды.

Алар халык тулы урам буйлап бик озак бардылар. Эт өчен таныш булмаган зур-зур йортларны, кибетләрне, ашханәләрне үттеләр. Вакыт-вакыт малай белән маэмай бөтенләй туктап калалар. Фәрит, бармак янап, этне ачуланырга керешә:

— Тротуарның уң ягыннан йөрергә кирәк дим ич! Күпме өйрәтергә инде сиңа!

— Каршы килгәндә, олыларга юл бирәләр! Эх, син, надан!

Маэмай мескен, аңларга тырышкандай, туктап, Фәритнең күзенә туп-туры итеп карап тора, ачуланса да, ерак китәргә тырышмый иде.

Урам чатына килеп җиткәч, Фәрит этне туктатты да светофорны күрсәтте:

— Светофор диләр моны! Аңладыңмы? Әнә күрәсеңме кызыл ут яна? Димәк, дүрт аягыңның берсен дә атлама, дигән сүз. Бераздан сарысы янар. Анда да ашыкма! Әйе, әнә теге погонында ике йолдызлы милиционер абый мәктәптә шулай диде, яшелен көтәргә кушты!

Моңарчы Фәритнең яшелен көтеп торганы юк иде югын, юлда машиналар күренмәгәндә, тизрәк урамның теге ягына йөгерә иде. Ә хәзер, теләсә-теләмәсә дә, яшел утка буйсынды. Эткә үрнәк күрсәтергә кирәк.

Светофорның яшел күзе ялтырау белән, чатта көтеп торган халык төркеменә ияреп, алар урамның икенче ягына чыктылар. Биредә бизәкле тимер рәшәткәләр белән уратып алынган бакча башланып китә иде. Фәритләрнең өе якын, әнә шушы бакча артында гына иде.

Бакча капкасына барырга ераксынып, Фәрит һәрвакыт турыдан, рәшәткә арасыннан гына чыгып йөри иде. Бу урында инде ул сукмак салып, рәшәткә тимерләрен ялтыратып бетергән. Тимерне генә түгел, үзенең пальтосын да кырып, шомартып бетергән иде. Гадәте буенча ул бүген дә үз сукмагыннан китте, кысыла-кысыла, рәшәткә арасыннан бакча эченә

төште. Артына әйләнеп карады, эт мыштым гына аның янында басып тора иде инде.

— Болай ярамый!— диде Фәрит, этне ачуланып.— Капка ни өчен? Йә, әйт, ни өчен? Надан!

Башта этне куып чыгарды, аннан кергән җиреннән кире үзе чыкты. Әйләнгеч булса да, бүген Фәрит, беренче тапкыр бакча капкасыннан үтеп, өйләренә урам яктан кайтып керде.

Этнең хәлен аңлатып биргәч, өйдәгеләр соңарган өчен ачуланмадылар тагын. Фәритнең әнисе улына да, эткә дә җылы аш салып бирде, икесенең дә талымсызланып ашауларын күзәтеп торды.

— Син эттән дә ныграк ачыккансың икән,— дип көлде Фәриттән. Ә Фәрит, тамагы туйгач, үзенең табышы турында сөйләүне дәвам итте:

— Ниндидер оялчан эт бу. Трамвайлар янына да бармый, автобуслардан да курка... Авылдан килеп адашкан булса кирәк...

— Кем белсен, бәлки, шәһәрдәндер, — диде Фәритнең әнисе, улы белән килешмичә.

— Түгел инде! Күренеп тора: өстенә тигәнәк ябышкан... Бернәрсә урам тәртибен белми!..

— Син үзең дә белеп җиткермисең икән әле!

— Минме?

— Син шул! Өйгә шалтыратып әйттеләр!..

Фәритнең әнисе сумкасын ачты, аннан зәңгәр тышлы китап чыгарды.— Менә сиңа «Юл хәрәкәте кагыйдәләре». Хәзер үк утыр да укы, өйрән!

Фәрит тәртип бозуда үзенең һич кенә дә гаепле түгеллеген, әлеге дә баягы шушы эт аркасында

икәнен аңлатып биргәч, әнисе бераз тынычланган кебек булды.

— Алайса, эттә икән гаеп...

— Эттә шул. Шәһәрдә бөтенләй йөри белми. Өйрәтәм мин аны, әни. Жучка кебек итеп...

Шул көннән башлап, Фәрит эткә дәрес бирергә тотынды. Мәктәптән кайту белән, зәңгәр тышлы китабын ала да Табылдык өчен иске-москы такталардан ясап куйган оя янына китә. Китабын ачып, эт янына барып утыра, аңа урамда йөрү кагыйдәләрен укый башлый:

— «Урамда һәрвакыт тротуарның уң ягыннан гына йөрергә кирәк. Тротуар булмаган җирдә юлның сул кырыеннан, транспортка каршы барырга...» Аңладыңмы? «Урамны рөхсәт иткән җирләрдән генә аркылы чыгалар». Төшендеңме?



Табылдык исә борынын Фәритнең аягына салган да күзен солы кадәр генә ачып, изрәп ята бирә. Аның хәзер тамагы тук, урыны җылы, синең юлыңда да, тротуарларыңда да эше юк.

— «Йөргәндә чәчәк түтәлләрен, газоннарны, клумбаларны таптама, агачларны сындырма!» Ишетәсеңме, Табылдык? Ә син теге көнне бакчада туп-туры чәчәкләр өстеннән киттең! Надан син!

Табылдык инде хәзер күзен йомып, аякларын сузып җибәргән, рәхәтләнеп хуҗасы итәгендә йоклап ята. Фәрит китапның яңадан-яңа битләрен ачып укый бирә:

— «Дусларыгыз белән тротуар уртасында туктап сөйләшмәгез, кискен хәрәкәтләр, борылышлар ясамагыз, ашыгып баручы кешегә юл бирегез. Үзегез ашыксагыз, алдагы кешеләрне этмәгез-төртмәгез, кагылмыйча узарга тырышыгыз...»

Фәрит, бу урында туктап, эткә күз төшерде.

— Кара, ялкау, йоклап та киткән! Ну гамьсез дә син, Табылдык!

Малай этне төртеп уятты да, аның колагына иелеп, кычкырыбрак укырга кереште:

— Бу китапта, машина артына ыргак башлы тимерчыбык белән тагылып, тимераякта шуарга да, велосипедта тротуар буйлап йөрергә дә ярамый икән. Тегесе дә ярамый, монысы да. Нәрсә генә эшләргә соң?

Тәмам кәефе кырылган Фәрит китабын өйгә кертеп куя да, Табылдыкны ияртеп, урамга чыгып китә. Монысы инде — практик дәрес. Фәрит этенә кабат-

кабат газоннарны, светофорларны, юлны аркылы чыгу өчен ясалган шакмакларны күрсәтә. Табылдыкны урамнар, мәйданнар, бакчалар белән таныштыра. Хәтта Фәрит эткә үзе белгән кадәр юл билгеләрен өйрәтә. Монысы шоферлар өчен генә булса да, белүнең зыяны тимәс, янәсе.

Бераз йөргәч, яңадан шул урынга әйләнеп киләләр. Фәрит инде хәзер Табылдыктан сынау ала:

— Монысы, түгәрәк тактага аркылы сызганы, нәрсәне аңлата?

Ә эт башын да күтәреп карамый — иярүен белә!

— Түгәрәк тактага аркылы сызганы — машиналар туктарга ярамый дигән сүз!

Йөри-йөри, Фәрит белән Табылдык юл буенда өндәү билгесе төшерелгән, быргы рәсеме ясалган такталар янына килеп чыгалар, икесе дә нәрсә икәнен белмичә аптырап карап торалар. Ахырда анысын да белделәр — постта торучы милиционер абый әйтте. Өндәве — шоферларга юлда сак булырга кушкан билге, быргысы урамда машиналарга сигнал бирергә ярамаганлыкны аңлата икән.

Тагын китәләр. Бер тактада «30 км» дип язылган. Фәрит, төшенмичә, эткә карый, эт — Фәриткә.

— Ну надан да инде син! — дип сүгә башлый этне аннан Фәрит.

Өч-дүрт сәгать йөреп, эт белән малай өйгә «эт булып» хәлдән таеп кайталар. Шулай һәр көн.

Фәрит инде хәзер Табылдык аркасында бөтен урам кагыйдәләрен, юл тәртипләрен өйрәнеп бетте, барлык билгеләрне танып, андагы таләпләрне

төгәл итеп үти башлады. Ә Табылдык? Табылдык һаман шул көенчә ияреп йөри. Бернәрсә белми. Надан...

Шамил Бикчурин.

?! **1.** Хикәянең беренче вакыйгасында кем гаепле? Фәритме, этме?

2. Автор безгә әйтәсе теләген ничек яшергән?

АКЫЛЛЫ КЫЗ.

Ярлы гына бер кеше яшәгән. Аның бер кызы була. Картны патша чакырта, ә ул бармый.

— И әти, нигә бармыйсың? — ди кызы.

— Куркам,— ди атасы,— килгән бер кешене астырып тора, мине дә астырыр,— ди.

— Асмас,— ди кызы,— бар, ди. Ул сиңа берничә сорау бирер, ди, шуларга җавап бирсәң, бер нишләтә алмас,— ди.

Беренче сорау: йөгеректән-йөгерек дөньяда ни йөгерек, дип сорар. Син, йөгеректән-йөгерек куян, аннан да йөгерек күңел, дип әйтерсең.

Икенче сорау: катыдан-каты ни каты, дип сорар. Син, катыдан-каты таш, аннан да каты баш, дип әйтерсең.

Өченче сорау: татлыдан-татлы ни татлы, дияр. Ә син, татлыдан-татлы бал, аннан да татлы җан татлы, дип әйт. Син шул җавапларны әйтсәң, берни дә булмас. Шуның өчен чакыра ул сине, ди.

Китә карт патша янына. Курка-курка, җавапларны әйтә.

— Бу җавапны кем өйрәтте сиңа, әйтмәсәң, мин сине астырам,— ди.

— Әй, кызым әйткән иде лә,— ди карт.

— Синең кызың бик күп белә икән,— ди, бер беләк буе җеп бирә дә,— шуннан миңа такыя[1] сырсын, күлмәк тексен,— ди патша. Елый-елый кайтып китә карт, шушы беләк буе җептән кеше әйбер тегә аламыни дип.

Өйгә кайтып кергәч, кызы әйтә: «Бер дә кайгырма, әти, ди, бер агач сындырып алып керә дә, ул миңа шуннан киндер суга торган станок ясап бирсен, ди, бүтән төрле агач кертмәсен, бертөрле генә булсын»,— ди.

Патша кыз җибәргән агачны алып карый да: «Ай-яй, кызың күп белә икән, ди. Алай булгач, мин алты кәҗә тәкәсе җибәрәм, таң атканчы шуларны бәтиләтеп җибәрсен»,— ди.

Карт тагын елый-елый алып кайтып китә инде тәкәләрне. Кыз кәҗә тәкәләрен күргә шатлана башлый.

— Безгә яхшы булды бу, без аларны берәмберәм суеп ашарбыз,— ди.

— Әй, сиңа көлке, патша ул тәкәләрне бәтиләтергә кушты,— ди.

— Бер дә кайгырма, әти, ди, рәте табылыр,— ди кыз.

Патша бер көн көтә, икенче көн көтә, кәҗәләр дә юк, үзләре дә килмиләр. Патша үзе китә. Кыз, патшаның килгәнен күргәч, этисенә әйтә: «Бар, хәзер үк мунчага, мин үзем җавап бирермен»,— ди.

Карт мине алырга килә икән инде дип йөгерә генә мунчага. Патша килгәндә, кыз килегә тары салган да тары төеп тора.

---

[1] Такыя — бизәлгән түбәтәй сыман баш киеме.

— Үзең тары төясең, килеңдә ничә бөртек тарың барлыгын беләсеңме? — ди патша.

— Әй падишаһым-солтаным, хәзер генә килеп кердең, сездән безгә хәтле ничә адым булды, санадыңмы? — ди кыз.

— Санап атламадым шул,— ди патша.

— Мин дә тарыны санап салмадым,— ди кыз.

— Атаң кайда? — ди.

— Мунчада, бәбәйләргә китте,— ди.

— Әй ахмак, ир кеше бәбәйлиме инде, ди. Кая соң кәҗә тәкәләре? — ди.

— Бәй, карт кешегә синең йомышка йөргән өчен аяк ялы кирәкмимени? — ди кыз,— суеп ашадык,— ди.

Патша уйлый: «Тукта, ди, мин бу кызны, яучы җибәреп, үземә кәләшлеккә ала алмам микән»,— ди.

Бер дә бер көнне патша яучы җибәрә. Кыз риза була, ә карт:

— Бара күрмә, кызым, икебезне дә астырып үтерер,— ди.

— Юк,— ди кыз,— мин барам, бармасам, икебезгә дә начар булыр,— ди.

Патша кызны алып китә.

Азмы-күпме бергә торгач, патша яланнарны карап кайтам дип чыгып китә. Чыкканда әйтә: «Миннән башка беркемгә дә хөкем итмә»,— дип. Патша чыгып киткәч, кыз чарлакка менә дә карап тора. Патшаның хезмәтчеләре эшли. Кайсы кибән куя, кайсы җыя, кайсы нишли шунда. Ике кеше килделәр дә атларын тугарып җибәрделәр, үзләре печән чабарга киттеләр.

Әбәткә кайтсалар, тегеләрнең атлары колынлаган. Колын ике тәртә арасында басып тора, ә ат печән ашап йөри. Болар икесе дә килгәннәр дә карап торалар. Берсе әйтә: «Бәй, бия колынлаган бит»,— ди. Икенчесе: «Бияме соң, колын тәртә арасында басып тора бит, арба колынлаган»,— ди. Сугышып, кара канга баталар болар. «Әйдә, хөкемгә патшага барыйк»,— диләр. Киләләр патшага:

— Патша өйдәме?

— Юк,— ди хатын.

— Кая китте соң?

— Тау башына тары чәчкән идек, шул тарыны көн дә күлдән чуртан чыгып чүпли, ди, шуны карарга китте,— ди.

— Бәй,— дигән берсе,— тау башына чуртан чыгып, ничек чүпли ул тарыны?

— Чүпли шул,— дигән хатын,— әле сез килдегез бит, бия колынламый, арба колынлаган дип. Кайчаннан бирле шуның өчен сугышасыз. Ничек инде арба колынласын? Барыгыз, кайтып китегез,— ди.

— Без ялгышканбыз икән,— дип кайтып китәләр болар.

Кайтып керә патша.

— Хөкемгә килгән кеше булмадымы? — ди.

— Килделәр, ди, печән чабучыларның биясе колынлаган, ди. Шуңа арба колынлаганмы, бия колынлаганмы икәнне белергә хөкемгә килгәннәр, ди. Безгә килгәндә, сугышып, каннары агып тора иде, ничек хөкем итмисең инде,— ди.

— Син нәрсә дип әйттең соң? — ди.

— Мөнә тарыны күлдән чуртан чыгып чүпли, шуны куарга китте дип әйттем,— ди.

— Әй,— ди патша,— син миннән узып хөкем иткәнсең, ди, мин кайткач килерләр иде,— ди.

— Эш кешесен ничек көттереп торыйм инде, хөкем иттем дә җибәрдем,— ди.

— Юк, ди, безнең сөйләшкән сүз миннән башка хөкем итмәскә иде, ди, мин моңа риза түгел, бүгеннән үк аерылабыз, үзең теләгән әйбереңне ал да кит,— ди патша.

— Ярар,— ди хатыны,— бер атнага рөхсәт бир, аннан китәрмен,— ди.

Хатын яхшы иттереп бал куя да беркөнне әйтә:

— Инде миңа китәр вакыт та җитте, ди, әйдә, китәр алдыннан икәү, утырып, чәй эчик,— ди.

Хатын эчерә патшаны, теге исереп тә китә. Хезмәтчеләргә әйтә: «Ат җигегез дә патшаны чыгарып салыгыз»,— ди. Ат җигелгәч, патшаны чыгарып салалар. Хатын үзе ат башына менеп утыра да алып китә патшаны. Әй ат белән йөри бу, әй йөри чокырлы җирләрдән — патшаны айныта инде. Патша айнып, сикереп тора да:

— Бәй, нишләп йөрибез без бу яланнарда? — ди.

— Сине үземә алып кайтып барам. Син бит үзең теләгән әйберне ал да кит диден. Минем теләгәнем син, шуның өчен сине алып китеп барам,— ди хатын.

— Их,— ди патша,— минем хатын үземнән акыллырак икән, миңа шундый хатын кирәк тә. Әйдә, бор атыңны, өйгә кайтабыз,— ди.

Болар яңадан яхшы гына тора башлыйлар. Килгән кешегә икесе дә хөкем итәләр, киңәш бирәләр. Хатын иренә караганда да тугры хөкем итә икән, ди.

?! Әкият авторы безнең нинди булуыбызны тели?

БЕР ХАКЛЫК ҺӘМ ЙӨЗ ЯЛГАН ТУРЫНДА.

Итәгенә ут капкандай, бер ялган
Тыр-тыр чабып бара икән урамнан.
Шул вакытта дусты куып җиткән, ди,
Хәтта әле аны узып киткән, ди.
— Хаклык куа! Тизрәк! — дигән ул аңа,—
Әллә качып карыйк микән урманга.
Анда безне, бәлки, таба алмас ул.
Йөри торгач, адашмыйча калмас ул...
— Әйдә, үзен кызык итик әле бер:
Ул булганда, көн юк безгә барыбер...

Шуннан болар әй тотынган чабарга.
Башкалары кушылган, ди, аларга.
Шулай итеп, болар йөзгә тулган, ди.
Йөзесе дә бер-берсенә туган, ди.
Ә урманда, котылдык дип Хаклыктан,
Пырых-пырых көләләр, ди, шатлыктан.
Шатлыклары тик озакка бармаган,
Берсе хәтта «ах!» дип әйтә алмаган.
Поскан икән карт карама артына,
Хаклык аны тотып алган ялт кына.
Ялган шундук куык сыман шартлаган,
Дус-ишләре хәтта эзен тапмаган.
Нишләргә дә белмәгән, ди, ялганнар.
Җыелышып, киңәшеп тә алганнар.
Берсе әйткән: «Үзен тотып алыйк без,
Һәм, богаулап, янган утка салыйк без.
Шуннан башка һич котылу юк аннан.
Йә, әйдәгез, тәвәккәллик, туганнар».
Шуны гына көткән икән ялганнар
Һәм Хаклыкны уратып та алганнар,
Шундук аны бәйләп утка салганнар.
Ә бераздан тагын хәйран калганнар.
Богау янган, Хаклыкка ут капмаган.
Ә ялганнар керер урын тапмаган.
Аптыраудан авызлары ачылган,
Кайсы башын, кайсы сыртын кашыган.
«Нишләргә?!» — дип, бар да башын ваткан, ди.
Кинәт болар күлгә таба чапкан, ди.
Хаклык очып чыккан да, ди, ялкыннан,
Куа киткән ялганнарның артыннан.

Өчесен ул шундук тотып алган, ди,
Тоткан берсе шарт-шорт шартлап барган, ди.
Күл тирәли йөргән чакта куышып,
Ата ялган яннан килгән шуышып.
Хаклыкны ул аяк чалып еккан, ди,
Шап иттереп, башына да суккан, ди.
Шуннан болар аны күлгә атканнар
Һәм, тынычлап, ял итәргә ятканнар.
«Шәп иттек!» — дип көлсәләр дә үзләре,
Күлдә генә икән һаман күзләре.
Хаклык шулчак судан калкып чыккан, ди,
Ялганнарны гүя яшен суккан, ди.
Кайсы кая таралышып беткән, ди.
Хаклык исә тагын куа киткән, ди.
Безне шулай ялганнардан саклый ул.
Утта янмый, суга салсаң — батмый ул.
Юлдаш безгә борын-борын заманнан.
Ышанмасаң, сора әнә бабаңнан.

Хәкимҗан Халиков.

?! Күрдегезме? Әсәрдә, ялган, хаклык кебек, кешедән аерылып яшәүче яман һәм күркәм сыйфатлар да персонажлар була алалар. Шигырьне, эчтәлеген бер генә җөмләгә калдырып, үз сүзләрегез белән әйтсәгез, авторның теләген, ягъни әсәрнең идеясен табасыз.

КЕМ ЭШЛӘМИ...

Матуш исемле корольнең кызы күз явын алырлык чибәр, ләкин искиткеч ялкау була. Таң атуга, көзге каршына килеп утыра икән дә көне буе урыныннан кузгалмый икән. Кызны кияүгә бирер вакыт җиткән.

Король илгә мондый хәбәр тараткан: кызым — ялкауларның ялкавы. Шул ялкауны өч ел эчендә эшләргә өйрәткән егеткә кызымны кияүгә бирәм, дигән. Көн артыннан көн үткән, кызны эшкә өйрәтергә теләүчеләр күренмәгән. Король ялчыларын кияү эзләргә чыгарып җибәргән. Ил буйлап эзли торгач, боларга үгезләр көтүче егет очраган. Король ялчылары егеткә: «Сине король чакыра», — дигәннәр. Егет куркып калган. Ләкин нишләмәк кирәк, король хәтле король чакыргач, карышып булмый бит инде. Боларга ияреп киткән бу.

Тәхет каршына килеп баскан егет. Король шартны бәйнә-бәйнә сөйләп биргән. Аннары: «Кызым — ялкауларның ялкавы. Шул ялкауны өч ел эчендә эшләргә күнектерә аласыңмы?» — дип сораган.

— Алам, нигә алмаска! — дип җавап биргән егет.

Көтүче король кызын өенә алып кайткан. Әнисе, киленнең чибәрлеген күргәч, боларны бик шатланып каршы алган.

Икенче көнне егет үгезен җиккән, сабанын арбасына салган да җир сөрергә киткән. Кузгалыр алдыннан әнисен:

— Үзе белеп эшләмәсә, кунакка эш кушма,— дип кисәткән.

Кичен егет эштән кайтып ашарга утырган. Әнисеннән:

— Бүген кем эшләде? — дип сораган.

— Син дә мин,— дип җавап биргән әнисе.

— Алайса, кем эшләгән, шул ашый ала,— дигән егет.

Кыз, ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җитеп, йокларга кереп киткән.

Икенче көнне дә шул хәл кабатланган.

Өченче көн тугач, яшь килен каенанасыннан эш сораган.

— Әнкәй, тик утырасым килми, миңа бирәр эш бир әле,— дигән.

Каенанасы утын ярырга кушкан.

Кичен ашарга утыргач, егет:

— Бүген кемнәр эшләде? — дип сораган.

— Мин, син, килен эшләде,— дип җавап биргән әнисе.

Бу юлы өчесе бергә утырып тамакларын туйдырганнар.

Шулай итеп, король кызы тора-бара эшкә өйрәнгән.

Өч ел үткәч, кызын күрергә дип, король килеп төшкән. Кызының каенанасы белән чөкердәшә-чөкердәшә эшләүләрен күреп бик шатланган.

— Эшләргә күнектеңмени, кызым? — дип сораган.

— Өйрәндем шул,— дип җавап биргән кызы.— Бездә гадәт шундый, әти: кем эшли, шул ашарга утыра ала. Ашыйсың килсә, әнә балта, утын яр,— дип тә өстәгән.

?! **1.** Әкиятләрнең күбесендә беренче вакыйга нинди булса, соңгы вакыйга шуның капма-каршысы була. Бу әкияттәге шул каршылыкны әйтегез.

2. Әкият авторлары безгә әйтәсе теләкләрен әкиятнең исеме иткәннәр. Исемдәге мәкальнең дәвамын әйтегез.

Автор көлүе.

Әсәрдә авторның бәясе, хисе, теләге бар, дидек. Хәзер инде без аларны күрергә өйрәнеп киләбез. Үткән дәресләрдә язучының безнең белән елмаеп сөйләшкәнен сизгәләдек. Авторлар шактый әсәрләренә көлә-көлә килеп керәләр. Көлеп-елмаеп торган кеше янында басып тору гына да күңелле бит ул. Ә автор, үзе генә елмаеп кына калмый, көлкеле вакыйга да уйлап таба. Без дә автор белән бергә елмаябыз, көләбез. Бер сәбәпсез көлү — тәрбиясезлек, билгеле. Ә үткен фикерне аңлап көлгән бала — бәхетле бала ул. Галимнәр әйтәләр, еш көлгән кеше озак яши, диләр.

Хиснең чиксез күп дәрәҗәсе булган кебек, көлүнең дә дәрәҗәсе чиксез күп. Аларны күреп аера белергә генә кирәк. Автор бер әсәрендә кычкырып көлә, икенче әсәрендә сизелер-сизелмәс кенә елмая, ә өченчесендә хәтта хәсрәтен көлүе эченә үк яшергән була.

Язучылар төрле кош-корт, хайваннар, җәнлекләр турында әсәрләр язалар. Әйдә, минем яраткан укучыларым башта кош-кортларның яман сыйфатларыннан көлсеннәр. Аннан соң үзләре турында уйлансыннар. Мин аларның еш көлүләрен, ләкин көлкегә калмауларын телим, диләр.

Мәсәлән, әтәчнең тәкәбберлегеннән, маймылның кыланышыннан, кәҗәнең кирелегеннән көләбез.

Аларга карыйбыз да үзебездә дә шундый сыйфатларның барлыгын абайлап алабыз. Кара син аны, мин үзем дә кайчак әтәч кебек кәпрәям, кәҗә кебек киреләнәм, маймыл кебек кыланам, попугай кебек, кеше сүзен кабатлап йөрим бит. Читтән күзәтеп торучы: «Күр инде моны! Тач әтәч; кәҗәдән бер аермасы да юк; маймыл да маймыл, ул да маймыл»,— дип көлә торгандыр, дибез. Үзенә башка берәү булып бәя бирергә өйрәнгән бала шулай уйлый.

Автор әсәрләрендә укучыларын үз итеп елмаеп торса, андый әсәрләргә **юмор әсәрләре** диләр.

Кайбер әсәрләрендә автор: «Ә менә бу кешенең яман сыйфатлары бар. Минем ул кеше белән елмаеп, үз итеп сөйләшәсем килми. Әйдә, бу әсәрдә үзен күреп оялсын әле, хур булуын аңласын»,— дип тели. Андый әсәрләргә **сатира әсәрләре** диләр.

Юмор һәм сатира әсәрләрендә автор үзе көлә, ләкин аның теләге — безне, укучыларын көлдерү. Ул безне ничек көлдерә соң? Берничә дәресне көлдерү алымнарын өйрәнүгә багышлыйк.

Кайбер әдипләр бик матур дуслык турында да, мәхәббәт турында да, хәтта хәсрәт турында да елмаеп яза алалар. Андый әсәрләрне без аеруча яратып укыйбыз. Ә кызгана белүче бала булсак, без дә, автор белән бергәләп, күзебездән яшь тамганны сизми дә калабыз. Кызгана, ярата белгән бала үзенең хәсрәте белән дә бәхетле ул.

Әнә нинди көчкә ия ул юмор белән сатира. Елмайта да, көлдерә дә, елата да, хәтта бәхет тә бүләк итә.

ӘКИЯТ БАШЫ.

Борын-борын заманда,
Безнең әби-бабайлар
Атынганда таганда;
Җир кирегә әйләнгәндә,
Җәен карлар яуганда,
Кошлар кышын бездә калып,
Язын китеп барганда;
Без коенган елгадагы
Сулар үргә акканда;
Кояш, көнбатыштан чыгып,
Көнчыгышка батканда
Яшәгән, ди, яшәгән...
Яшәгән, ди, шул менә...
Кем яшәгән? Нишләгән?
Мин башладым.
Син сөйлә!

Мәдәррис Әгъләмов.

?!

1. Автор уйлап тапкан көлке урыннарны табыгыз.

2. Шагыйрь үтенечен үтик. Әкият башын дәвам итегез. Кем яшәгән? Ул теләсә кем, теләсә нәрсә була ала. Тик аның һөнәрен,ниләр эшләвен, кемнәргә яхшылык кылуын, кемнәрне җиңүен уйлап табыгыз.

БАШМАК.

Борын заманда бер бабай яшәгән. Аның бер малае булган. Әтиле-уллы яшиләр болар бер начар гына өйдә. Үләр вакыты җиткәч, әтисе улына әйтә: «Балам, ди, минем сиңа калдырырлык бернәрсәм дә

юк инде, тик бер башмагым гына бар. Кая барсаң да, шуны калдырма, ул сиңа кирәк булыр»,— ди.

Озак та үтми, әтисе үлә, улы ялгыз кала. Егеткә, әтисе үлгәндә, унбиш-уналты яшьләр була.

Егет уйлый-уйлый да дөнья гизәргә чыгып китә. Әтисенең сүзен исенә төшереп: «Тукта, ди, кая барсаң да, башмакны калдырма үзеңнән дип әйткән иде бит»,— ди. Башмакны сумкасына салып, юлга чыгып китә бу. Аягына кияргә бернәрсәсе дә булмый, яланаяк китә.

Бара-бара, моның аяклары авырта башлый да, сумкасындагы башмагы исенә төшә. «Тукта, ди, башмакны алып киим әле»,— ди. Башмакны алып киюе була, аягына җиңел булып китә. Башмак үзе атлап китә, музыка да уйный башлый. Моның күңеле күтәрелеп китә хәзер.

Ярый, бу бара шулай уйный-уйный, моңа бер кеше каршы очрый. Карап тора малайга — шулхәтле шәп килә бит. Исе китә моңа. «Тукта,— ди теге кеше,— миңа башмагын сатмас микән»,— ди. Әлеге кешенең кулында бәләкәй генә капчык белән алтын булган икән, башмагын бирсә, шушы алтынымны да бирер идем дип килә инде бу. Килеп туктыйлар кара-каршы, ял итәләр. Бу кеше егеткә әйтә:

— Башмагыңны миңа сат, мин сиңа аның өчен алтын бирермен,— ди.

— Ал,— ди егет, сата бу башмагын.

Теге кешенең башмакны аягына киюе була, китә бу чабып, мин сиңа әйтим, һич туктый алмый, ди. Көч-хәл белән бер тал янына барып ава да башмак-

ны салып кулына тота. Йөгертеп килә дә башмакны егеткә атып бәрә:

— Мә башмагыңны, шайтанлы икән, үзеңә булсын,— дип әйтә дә үзе йөгерә бирә. Егет тегенең артыннан кычкыра:

— Мә, алтыныңны ал,— дип. Теге артына-алдына карамый китеп бара, алтынны да алмый, башмакны да кире бирә.

Егет, башмагын киеп, уен-көлке, музыка белән барып җитә бер шәһәргә. Бер бәләкәй генә өйгә керә. Өйдә бер карчык утыра. Егет сорый:

— Шәһәрдә нинди хәлләр бар, әби? — ди.

— Ханның бер малае бар иде,— ди әби.— Шул малае үлде. Аның үлгәненә унбиш ел инде, ди, бөтен шәһәр халкы кайгыда, көләргә дә ярамый. Хан үзе дә сөйләшми дә, көлми дә,— ди. Егет әйтә:

— Ничек инде алай, аны юатырга кирәк, үлгән кеше кире кайтмас, аның күңелен ачарга кирәк. Мин анда барыйм әле,— ди.

— Белмим, улым,— ди карчык,— хан йортына барсаң, аның вәзирләре сине шәһәрдән куар,— ди.

Ярар, китә бу урам буйлап хан йортына таба. Башмагын киеп, уен-көлке, музыка белән бара бу. Шәһәр халкы моны күреп исе китә. «Бу нинди кеше болай уен-көлке белән килә?» — диләр. Хан йортына җиткәндә, ханның атка атланган, кылыч таккан вәзире моны куа башлый: «Халыкны бозып, уен-көлке белән нишләп йөрисең?» — дип. Егетне тәки шәһәрдән куып чыгарды бит вәзир. Шәһәр читенә чыккач, утырып уйлана егет: «Мин нишләп вәзир куганга карап киттем

әле, тукта, яңадан барыйм. Мин ханның күңелен табарга тиеш»,— дип, яңадан хан йортына таба китә.

Ханның капка төбенә килеп туктый уен-көлке белән. Тагын вәзир күреп куып җибәрде моны. Шәһәр читенә чыгып, бераз утыра да яңадан китә егет: «Мине вәзир генә куды бит әле, мин ханның үзен күрергә телим»,— дип, уен-көлке белән хан капкасы төбенә барып туктый. Хан берүзе баскычка чыгып утырган икән. Хан сорый солдатлардан:

— Бу нинди тавыш?— ди.

— Ә, бер малай килгән, шулай уен күрсәтеп йөри,— диләр.

Хан чакырта моны, йортка керсен дип. Кертәләр. Хан үзенең халкын җыйдыра. Мәйдан ясатып әйтә халыкка:

— Болай яшәргә ярамый, халыкның күңелен күтәрергә кирәк инде,— дип. Егетне куган вәзир дә килеп чыга мәйданга. Килеп чыга да вәзир әйтә:

— Әллә бу малай үзе уйныймы?! Аның аягында шайтан башмагы, шул башмак уйный бу музыканы, уен-көлкене, аны шәһәрдән куарга кирәк,— ди. Хан әйтә:

— Алай булгач, син шул башмакны киеп биеп кара әле,— ди.

Әлеге вәзир башмакны алып кия дә биергә төшә инде. Биергә дип бер аягын күтәрсә, икенче аягын кузгата да алмый бу.

— Ә,— ди хан,— башмак биетә дип әйтәсең, нигә үзең биемисең, башмак биеткәч?— ди. Унбиш ел буена көлмәгән ханның күңелен ачкан, көлдерткән өчен,

хан егетне үзенең йортына ала, кызын бирә. Хан үлгәч, халык егетне аның урынына утырта.

Вәзир ханның үлгәнен көтеп йөргән икән. Ул үлгәч, аның урынына үзе утырып, кызын алмакчы булган. Хан вәзирне йортыннан куган, ди.

?! Әкияттә көлү күп. Ләкин без көлмибез. Нигә көлмибез?

Көлке ничек туган?

Безнең иң-иң борынгы бабайларыбыз башта сөйләшә белмәгәннәр. Сөйләшер өчен, сүзләр уйлап чыгарырга кирәк булган. Арада иң акыллысы бармагы белән иптәшенә төрткән дә «бу» дигән. Борынгы галимебез беренче сүзне шулай уйлап тапкан. Кызганыч, без үзебезнең иң беренче галимебезнең исемен белмибез, чөнки ул чакта исемнәр дә булмаган.

Борынгы галим үзе шатланган. Ничек шатланмасын, зур ачыш ясады бит ул. Ләкин иптәшләре, аның шатлыгын уртаклашасы урында, егыла-егыла көлгәннәр. Кулына таш балта тоткан иптәшләре «бу»ның кеше дә, агач та, ут та булуын берничек тә күз алдына китерә алмаганнар. «Бу» аларга, күрмәгән-белмәгән нәрсә булганга, бик кызык тоелган.

Иң беренче көлү шулай туган. Аннары, борынгы галимнәр бар нәрсәгә дә исем бирә башлагач, «бу» сүзе дә, «җир», «диңгез», «су», «үрдәк» сүзләре дә гадәти исемнәргә әйләнгән. Шуңа күрә, «бу» дисәләр дә, «җир» сүзен ишетсәләр дә, берәү дә көлмәгән.

Адәм баласы көлмичә яши аламы?

Балаларның «Җир кайдан килеп чыккан?», «Җил нигә бер исә, бер исми?» кебек бетмәс-төкәнмәс

сорауларына җавап урынына борынгылар күз күрмәгән, колак ишетмәгән вакыйгалар сөйли торган булганнар. Табигать белеме дәресләрендә шундый кызыклы фәнни ачышларны ишеткәч, балалар егыла-егыла көлгәннәр.

Күз күрмәгән, колак ишетмәгән нәрсәләрне уйлап чыгару көлке алымын уйлап табу булган да инде.

Моннан ике мең биш йөз ел элек Аристотель исемле бөек галим яшәгән. Ул шул дәрәҗәдә бөек булган, сәнгать алымнарын барлап, аларга аңлатмалар язган. Аның аңлатмалары, кагыйдә, билгеләмәләре бүген дә әдәбият фәненең нигезен тәшкил итә. Менә нинди бөек галим булган Аристотель.

Көлке алымының берсен ул хаклы рәвештә менә болай аңлаткан: «Дөньяда була алмый торган күренешкә кеше гаҗәпләнә. Гаҗәпләнү исә күңелне күтәрә, күңел күтәрелсә көләсе килә. Шуңа күрә дөньяда юк нәрсәләр, вакыйгалар сәнгать әсәрләрендә яшәргә хаклы».

Шундый алымның барлыкка килүенә багышланган заман ачышларының берничәсе белән танышыйк.

ҖИР ЯРАЛУ.

— Бик борынгы заманнарда, әле җир дә, кеше дә булмаганда, хәзерге Җир шары гел судан гына торган. Кая гына карама, бар җирдә дәрья-су булган, давыллар уйнаган, дулкыннар күккә тоташкан...

Дәрьяда каз-үрдәкләр йөзеп йөргән. Алар, су төбенә төшеп, азык эзлиләр икән. Шунда бер үрдәк дәрья төбенә чумган да томшыгына азык алырга

теләгән. Томшыгын тирәнгәрәк батырганмы, су төбеннән бик күп ләм-балчык күтәреп алып чыккан. Бу ләм шулкадәр күп булган, хәтта әлеге үрдәкнең томшыгыннан коелып, су өстендә җир-утрау булып өелеп калган. Коры җир әнә шулай барлыкка килгән, дигән борынгы галим.

Борынгы бабайлар галимне шундый зур ачышы өчен бик мактаганнар. Мактарсың да: җир кадәр җирнең ничек барлыкка килүен әйтеп бирсен әле. Акылы белән башкалардан аерылып торган өчен, аңа «профессор» исеме кушканнар.

Борынгы профессор, бер кызып киткәч, «Бу нәрсә?» соравына «Ни өчен?» соравын да өстәгән. Мәсәлән, «Җил ничек барлыкка килә? Ни өчен ул әле исә, әле исми? Ни өчен тургай биектә сайрый-сайрый да кинәт атылып җиргә төшә? Тагын менеп сайрый-сайрый да, сөңге кебек, җиргә атыла?» кебек сорауларны үзенә үзе бирә башлаган. Сорауларына җавап тапкач, ачышларын иптәшләренә сөйләгән.

Шул ачышларның икесе белән танышыйк.

?! Үрдәк батырлыгын ишеткән укучылар ни өчен көлгәннәр?

ҖИЛ ИЯСЕ.

Кайдадыр, дөнья читендә, Каф таулары дигән тылсымлы таулар артында, Җил иясе дигән бик карт бер әби бар. Ул үзе сукыр. Җилне шул истерә. Аның дөнья зурлыгы бер мичкәсе бар, бөтен булган, буласы җилләрне шул мичкәдә ябып саклый. Җил истерергә вакыт җитү белән, Җил иясе мичкәнең бөкесен кирәк

кадәр генә ача да, менә китә, мин сиңа әйтим, җил дулап! Зур итеп ачса — давыл, буран куба!.. Кирәк кадәр истергәч, карчык мичкә тишеген бөкесе белән томалап куя. Дөнья тып-тын кала...

— Ул әби, шулай бик карт та, сукыр да булгач, савытның бөкесен югалтмасмы соң? — дип сораганнар галимнән иптәшләре.

— Юк, югалтмый. Ни өчен дисәң, бөкесен кулыннан бер дә ычкындырмый. Шулай да, күзе күрмәгәч, кайвакыт мичкәнең тишеген тиз генә табып ябып куя алмый. Менә шул чакта атналар буе котыра җил-бураннар,— дигән галим.

?! Хикәятне тыңлагач, балалар ни өчен көлгәннәр?

ТУРГАЙ ҺӘМ КОЯШ.

Бермәлне Тургай, күктә сайрый-сайрый арыгач, җиргә ял итәргә төшкән. Сукыр тычкан оясыннан башын чыгарган да:

— Тургай дус, сиңа бер йомышым бар иде, үтәмәссеңме? — дигән.

— Булдыра алсам, нигә үтәмәскә, үтәрмен,— дип җавап биргән Тургай.

— Кояш миннән бурычка өч тиен акча алып торган иде. Син бик биеккә менәсең, Кояштан шул тиеннәрне алып төшә алмассыңмы?

Тургай Сукыр тычканның көлеп әйткән сүзләренә ышанган. Кояш янына менгән дә:

— Өч тиен-тин-тин-тин-тин, тиеннәрне кайтар. Тин-тин-тин, тиеннәрне кайтар! — дип сайраган.

Кояшның Тургайга ачуы чыккан. Ачуыннан хәтта янәшәсендәге болытларны яндырып ташлаган.

— Ялганчы! Минем кемнән акча алганым бар, йә әйт, әйт! — дип кычкырган. Шундый итеп кычкырган, Тургай куркуыннан, таштай атылып, җиргә төшкән. Бераздан, куркуы басыла төшкәч, кабат Кояш янына очып менгән:

— Өч тиен-тин-тин-тин... Сукыр тычканнан алган тиеннәреңне бир!

— Тукта, хәзер күрсәтәм мин сиңа ул тиеннәреңне! — дип, күзеннән очкыннар чәчрәткән Кояш.

Тургай куркуыннан тагын җиргә атылган. Шулай Кояштан әҗәт сорау аның гадәтенә әйләнгән. Яз җитте исә, күккә очып:

— Өч тиен-тин-тин-тин-тин... Әҗәтеңне бир, әҗәтеңне бир! — дип, болытлар өстенә менеп сайравын дәвам иткән.

?! 1. Тургай белән Кояш турындагы мифта көләрлек урын бармы?

2. Сүз Сукыр тычканнан башланган иде. Соңыннан ул әсәргә тагын килеп керергә тиеш. Ул Тургайдан да, Кояштан да көлде. Нигә көлде?

3. Сукыр тычканга, Кояшка, Тургайга бәя бирегез.

Безнең иң-иң борынгы бабайлар да, аларның уллары да борынгы галимнәрнең бу ачышларына чынлап торып ышанганнар. Ә безнең бабайлар: «Шул әкиятләргә ышанганнар бит»,— дип егыла-егыла көлгәннәр. Ләкин уйлап-уйлап торганнар да: «Ә бит алар ачыш ясаганнар икән. Көлке уйлап тапканнар»,— дигәннәр һәм җирнең каян килеп чыгуы,

җилнең ничек исүе турындагы «фәнни ачышлар»ны онытмаганнар. Улларына сөйләгәннәр, уллары үз улларына сөйләгән. Тагын да соңрак шул ачыш-әкиятләргә **мифлар** дип исем биргәннәр. Борынгы бабайлар көлүнең кешегә бәхет китерүен белеп алганнар да, улларын һәм оныкларын көлдерү өчен, кызыклы әкиятләр иҗат иткәннәр. Ә көлке тудырырга алар мифлардан өйрәнгәннәр.

Көлке ничек халык авыз иҗатына килеп кергән?

Заманалар үткән. Борынгы бабайларыбыз уйлап тапкан кызык вакыйгалар артканнан-арта барган. Галимнәр әнә шул көлке вакыйгаларга **халык иҗаты** дигәннәр.

Әкият уйлап чыгаручылар хәзер юкны бар дип ышандырмыйлар. Җирне үрдәк ясаган дигәнгә кем ышансын?! Бабайлар, кеше сыйфатларына сарык сыйфатлары кушып, күз күрмәгән, колак ишетмәгән нәрсә уйлап чыгаралар. Аңа «Шүрәле» диләр. Әкият тыңлаучылар үзе кеше, үзе сарык шүрәлене күз алдына китерәләр дә көләләр. Нигә көләләр? Әкият авторларының шаяртуын белгәнгә көләләр.

Тау хәтле, бер генә күзле нәрсә уйлап чыгаралар да «гыйфрит» дип исем бирәләр. Тау хәтле гыйфритне берәүнең кече улы тукмавын ишетәләр дә тагын көләләр. Ә маймыл кебек койрыклы, кәҗә кебек мөгезле, ишәк кебек ахмак, үзе кешечә сөйләшә, балык кебек, су төбендә яши торган пәриләр турын-

да әйткән дә юк инде. Безнең халык аларны, «әнем белән чабыш» дип, куян белән чабыштырып та алдый. Эшләпәсенең төбен тишеп, аңа бер капчык алтын сыйдырып та алдый... Пәриләрне алдау әкият егетләренә чүп тә түгел. Шуңа күрә безгә кызык була.

Кеше хыялы уйлап тапмаган бернәрсә дә юк. Иң әһәмиятлесе, әкият иҗат итүчеләр җирдәге тормыш белән янәшәдә тагын бер дөнья — хыял дөньясы уйлап чыгаралар. Ул дөнья җиргә охшаган да, охшамаган да. Кызык, көлке һәм шул ук вакытта елата да ала торган дөнья. Әкиятләрдәге ул дөнья, безнең күңелләргә күчеп, безнең үз дөньябызга әйләнә. Ул дөньяга күчеп ял итүләре нинди күңелле!

КАРТ БЕЛӘН КАРЧЫК.

Борын-борын заманда бер карт карчыгы белән, бер бабай әбие белән яшәгәннәр, ди. Аларның уллары да, кызлары да булмаган, бала-чагалары гына булган. Аларның өйләре яп-яңа, этсәң аварлык, төртсәң түнәрлек булган. Карчык шундый чибәр булган, ди, тәрәзәдән караса, кешеләр күзләрен йомып китә торган булган, ди. Мөгезле хайваннары күп булган: ике песи сугымлык, бер песи савымлык; койрыксыз этләре, койрыклы тычканнары сайгак төбендә ятканнар, ди. Икмәкләре күп булган, тик пешмәгән — суык тешләгән, ди. Балалары елый, хатыны тирги, ире капка төбенә чыга да: «Их, бездә нинди күңелле!» — дип җырлый, ди.

?! 1. Беренче җөмләдә автор ничек көлә? Ата-ананың уллары белән кызларын башкача бала-чага диләр. Автор эчтәлекләре охшаган сүзләрне каршылыкка китерә. Уллары белән кызлары юк, бала-чагалары гына бар, ди. Картларның балалары бар да, юк та булып чыга.

2. Әкиятне укучы бала авторның шаяртуын күреп ала да елмая. Әкияттә андый урыннар шактый. Шуларны табып аңлатыгыз.

Мәзәкләр.

ГАФУ ҮТЕНҮ.

Укытучы:

— Нигә дәрескә соңга калдың?

— Әни битне, аякны, кулларны юдырды. Гафу итегез. Башка болай эшләмәм.

?! Вакыйгада автор уйлап тапкан көлке бар. Шул урынны табыгыз.

ӘЙБӘТ ЙӨРИ.

— Сеңлең яхшы укыймы?

— Ул чаңгыда да, велосипедта да бик әйбәт йөри.

?! Җавап бирүче хәйләсен аңлатыгыз.

Әдәби әсәрләрдәге көлке.

Язучылар көлкеле әсәрләр язарга халык авыз иҗатыннан өйрәнгәннәр.

Халык бер мәкалендә: «Көлке кеше көлдән күмәч пешерер»,— ди. Шулхәтле дөрес әйтә. Көл көл инде ул. Дөньядагы иң оста пешекчеләр дә, аны изеп, күмәч түгел, коймак та пешерә алмыйлар. Ә көлке

уйлап табучы хәтта әнә шундый эшне дә булдыра. Язучы көлне күмәч итү өчен **шаяртырга** тиеш була. Башкача әйтсәк, юкны бар итеп ышандыра.

Ике төрле көлүнең аермасын мисалларда тикшерик.

МЕНӘ НИНДИ ИКӘН ЯЗ.

Бар җир чәчкә, гөл генә,
Кояш елмая, көлә —
Менә нинди икән яз!

Өскә-башка кимисең,
Өшемисең, туңмыйсың —
Менә нинди икән яз!

Җиргә ятып ауныйсың,
Көлеп туя алмыйсың —
Менә нинди икән яз!

Нурия Измайлова.

Шигырьдә кояш та, лирик герой да көлә. Лирик герой (автор дип уйлыйк) көлүенең сәбәбе бер генә — салкын кыштан соң, көттереп, яз килгән. Нурлы, чәчәкле, җылы яз. Матур яз. Лирик герой яз матурлыгына хозурланып шатлана. Бу очракта көлү сәбәбе — шатлык.

КЫШКА БЕР СҮЗ.

Кит әле син, аксакал кыш! Күр, әнә таудан туры
Тәгәридер ул матур кыз — язның алтын фәйтуны[1].

Тиз югал, и Кыш бабай, син ал да тиз кач карт башың,
Барыбер, күрсәң качарсың, язны — гөлләр патшасын!

Бер дә юк ул патшаның мылтык, кылыч-алмаслары[2],
Һәр ягында аллы-гөлле күбәләктән гаскәре.

Габдулла Тукай.

Габдулла Тукай кемнең дә булса яз килүенә шатланып көлүе турында берни дә әйтми. Бу шигырьдә автор, үз табышына куанып, үзе елмая. Сәбәбе? Укучы аны аңлар һәм ул да елмаер дип шатлана. Ничек елмаймыйсың? Без бит язны матур итеп кенә күрергә күнектек. Ә монда яз — кыш патшасының котын алырлык гаскәре булган сугыш чукмары.

Менә хәзер уйның серен белә башладык. Уй матур, ягымлы язны куркыныч сугыш чукмары итә. Әсәрдәге вакыйга әкият түгел. Уйлап карасак, яз,

---

[1] Фәйтун (фаэтон) — көймәле экипаж, җиңел арба.
[2] Алмас — алмаз.

чыннан да, кышны җиңә бит. Автор уе менә шул «җиңү» сүзен уйната. Җиңүе булгач, сугышы да, гаскәре дә, юлбашчысы да була. Тик менә сугыш башлаучы гөлләр патшасы язның гаскәре юк. Гөлләре, чәчәкләре, күбәләкләре бар, ә гаскәре юк. Автор уе тота да дөньядагы иң зәгыйфь җан иярләрен — күбәләкләрне — коточарлык куркыныч гаскәр итә.

Әйдәгез, шул алымны фән теле белән әйтик.

Әсәрдәге көлү алымы — нәрсәнедер үзенең киресенә әйләндерү ул.

Шундый кызык әкият кебек вакыйганы Габдулла Тукай үзе уйлап чыгарган. Автор туп-туры безнең күзгә карап тора сыман: елмаерлармы, юкмы, янәсе. Без елмайганны күргәч, үзе дә шатланып елмая.

МАКТАНЫРГА ЯРАТМЫЙ.

Мине беләсездер инде! —
Мәрдиев мин, Марат мин.
Мактанырлык малай булсам да,
Мактанырга яратмыйм.

Миннән дә шәп укучы юк,
«Биш»ле алдым бүген дә.
Шуңа мактанып торырга
Мин мактанчык түгел лә!

Мактанырга була, ләкин
Кирәк түгел ваклану.
Минем кебек шәп малайга
Килешми дә мактану.

Әгәр дә бик кирәк икән,
Иптәшләрем мактасын.
Йә килеп карый аласыз
Безнең мактау тактасын!

Башка малайлар шикелле,
Бәлки, мактаныр идем,
Болай да һәркем белә бит
Әйбәтлегемне минем!

Роберт Миңнуллин.

Әдипләр бердәнбер катнашучының гамәлен (эшен) каршылыкка китерәләр.

Марат яхшы укый. Мактанырга яратмыйм дип, кабатларга ярата. Димәк, тыйнак малай. Ләкин уңай сыйфатыңны кат-кат әйтү мактану була.

Маратның сүзе белән эше арасында каршылык туды: ул — яхшы укуы белән яхшы, мактанчык булуы белән начар малай. Шулай итеп, бер персонаж, яхшы да, начар да булып, икегә бүленде. Әгәр шигырьнең әнә шул ике өлешен тапмаган булсак, авторның безгә әйткән теләген (әсәрнең идеясен) белми дә калыр идек. Хәзер беләбез: автор безгә бик матур киңәш биргән икән. Дуслар сайлаганда, бер үк кешенең уңай сыйфатларын да, кире сыйфатларын да күрә белегез. Начар сыйфаты соңыннан ачылса үкенерсез, ди.

Алай гына да түгел әле, «Үзегез дә, Марат кебек мактанып, көлкегә кала күрмәгез»,— дип тә өсти автор.

КАЧЫШЛЫ УЙНАГАНДА.

Кызып уйнаган чагында
Була шулай да —
Шәвәли хәйләләп сорый:
— Вәли, син кайда?

Кат-кат сораудан энесе,
Ахрысы, туя:
— Кая качканны барыбер
Әйтмим! — дип куя...

Шәүкәт Галиев.

?! Бу шигырь дә кызык. Нигә кызык?

ӘТӘЧ ИЛӘ ЭНҖЕ БӨРТЕГЕ.

Чүплек башларында казына торгач, Әтәч ничектер бер энҗе бөртеге тапты: «Энҗе дигән булалар! Бу энҗе нинди юк нәрсә! Әгәр бу табылганчы, миңа казып мәшәкатьләнгәнем өчен бер тары ярмасы табылган булса, мин нинди шат булыр идем».

Габдулла Тукай.

1. Мәсәлдәге көлке каршылыгын табыгыз.
2. Автор нәрсәдән көлә?
3. Автор теләген әйтегез.

КӨЗГЕ ҺӘМ МАЙМЫЛ.

Маймыл, көзгедән үзенең сурәтен күргәч, әкрен генә янындагы Аюга аягы белән төртеп: «Кара әле, иптәш! Көзгедән нинди кыяфәтсез, нинди ямьсез бер

хайван күренә. Кара әле, аяклары нинди кәкре, кара әле, йөзе нинди килешсез! Әгәр мин шул көзгедә күренгән нәрсәгә аз гына охшасам да, хәсрәтемнән буылып үләр идем.

Хәер, әйтергә кирәк, минем иптәш вә дусларым арасында да бу көзгедә күренгән хайван төсле ямьсезләр биш-алтылап бар, хәтта мин аларны бармак берлән санап күрсәтә алам»,— диде.

Габдулла Тукай.

?! 1. Маймыл көзгедәге ямьсез сурәтне таныш маймылларына охшатып көлә. Ә автор нәрсәдән көлә?

2. Без нәрсәдән көләбез?

КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК ХИКӘЯСЕ.

Борын заман бер ир белән хатын торган,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык,—
Болар булган берсеннән дә берсе арык.

Әйтә беркөн ире: «Кара монда, хатын! —
Үзең яхшы беләсең бит печән хакын,—
Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык,
Ашап ята бушка гына алар азык».

Хатын көнде, диде: «Ирем, ярар, ярар,
Бу икене кумаклыкка булсын карар;
Кәҗә белән Сарык хәзер китсен бездән,
Аларны соң асрап торып ни файда бар?»

Нишли инде мискин Кәҗә белән Сарык?
Булмый хуҗа кушканына каршы барып.
Икесенә бер зур гына капчык тегеп,
Китте болар кырга таба сәфәр чыгып.

Китте болар. Бара, һаман бара, бара,—
Күренмидер күзләренә ак һәм кара.
Бара болар. Күпме баргач, Алла белә,
Юл өстендә үлгән бүре башын таба.

Курка башны кузгатырга Кәҗә-куркак,
Күптән инде куркаклыкка Сарык уртак,—
Баш янында болар икәү тора куркып,
Әйтешәләр бер-берсенә: «Син тот, мин тот!»

Кәҗә әйтә: «Сарык абзый, син көчлерәк».
Сарык әйтә: «Син, сакалбай, гайрәтлерәк».
Бүре башын кулга тотып кузгатырга
Юлдашларның берсенең дә җитми йөрәк.

Озак торгач шунда Кәҗә белән Сарык,
Бүре башын тоталмыйча, куллар барып[1],
Башны икәү тотып ике колагыннан,
Юнәлделәр, капчыклары эченә салып.

Бара болар. Тукталмастан һаман бара.
Күрә болар: ерак түгел бер ут яна.
Утны күргәч, иптәшенә әйтә Сарык:
«Әйдә, Кәҗә, куныйк бүген шунда барып.

Ут янына бүреләр дә киләлмәсләр,
Безнең анда кунганлыкны белəлмәсләр».
Сарыкның бу киңәшенә Кәҗә күнде:
«Әйдә, иптәш, ярар, барсак барыйк инде».

Кәҗә, Сарык ут янына якын барса,
Мискиннәрнең күз алдында менә нәрсә:
Өч-дүрт бүре утырганнар каршы утка,
Тыршып-тыршып пешермәктә алар ботка.

Кәҗә, Сарык, күргәч ушбу тамашаны,
Калды куркып, һәрберсенең ярты җаны.
«Исәнмесез, дустлар, бүре әфәнделәр!» —
Диләр болар, күрсәтмичә курку хәле.

[1] Куллар барып — нәрсәнедер эшли алмый.

Куаналар өч-дүрт Бүре, моны күргәч,
Алларына Сарык белән Кәҗә килгәч:
«Ашыйбыз, дип, бу икәвен тотабыз да,
Менә ничек ит таптык, дип, боткабызга!»

Кәҗә әйтә: «Кайгырмагыз, бездә ит күп;
Ул ит берлән һәркайсыбыз булырбыз тук!
Ни карыйсың? Тиз бул әле, тиз бул, Сарык!
Капчыктагы бүре башын китер алып!»

Сарык шунда капчыктагы башны ала,—
Барча Бүре куркуыннан шашып кала;
Өч-дүрт Бүре хәйран калып торган чакта,
Кәҗә һаман гайрәт чәчә, ачулана.

Кәҗә әйтә: «Микикики! микикики!
Капчыктагы бүре башы бит уники!
Ах, уңмаган, җүләр Сарык, надан Сарык,
Моннан зуррак бүре башын китер табып!»

Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны,
Капчыктан ул алып килә шул ук башны.
Өч-дүрт Бүре чынлап инде куркыштылар,
Бер-берсенә күзләрене йөртештеләр.

Түгел хәзер бүреләргә ашау кайгы,
Тиз-тиз генә бу урынны ташлау кайгы.
Ничек качыйк? Ничек табыйк качу юлын? —
Һәрбер Бүре шуңар салган бөтен уен.

Торып әйтә шул арада Өлкән Бүре,—
Картайган һәм күп эшләрне үткән Бүре:
«Туктагыз, ди, мин тиз генә су китерим,
Суы бик аз, безнең ботка пешәр коры».

Шулай итеп, Өлкән Бүре суга китә.
Кайтмый ләкин, озак кына заман үтә.
Кайтмый Бүре — эзе дә юк, исе дә юк,
Мәҗлес халкы арып бетә көтә-көтә.

Бүреләрне тагы каты курку басты,
Чөнки хәзер башлыклары китеп качты.
Тагын берсе суга таба китте торып:
«Туктагыз, мин эзләп кайтыйм»,— дигән булып.

Мәгълүм инде, бу Бүре дә кача шулай,
Хәйлә берлән качарга юл ача шулай.
Кайтмый бу да, әллә ничә сәгать үтә,
Мәҗлес халкы көтә һаман, көтә, көтә.

Өч-дүрт Бүре берсе соңра кача берсе,
Өченчесе, аннан соңра дүртенчесе.
Болар качкач, Кәҗә белән безнең Сарык
Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып.

Утыралар аяк бөкләп каршы утка,
Болар инде тәмләп кенә ашый ботка.
Ашап туеп, рәхәт кенә, тыныч кына
Кәҗә, Сарык бу төннәрен шунда куна.

Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук,—
Кулларында бүре башы салган капчык,—
Тагын болар урман буйлап сәфәр итте.
Нәрсә языйм?.. Хикәям дә шунда бетте.

Габдулла Тукай.

?! Шигырьдә автор көлүен табарга кирәк. Җавапны табу өчен, һәркайсыгыз болай уйлый:

а) «Көлдерә торган урынны табу өчен, мин ни эшләргә тиеш?» — дип сорау бирәм. Мин ул урынның каршылык булуын беләм. Хәтта үзенчәлеген дә хәтерлим: мин әкияттән **яхшы эчендә начар, начар эчендә яхшы** булган урынны эзләргә тиеш.

ә) Каршылыкны табу өчен, әкияттәге төп вакыйганы кыска гына итеп дәфтәргә язып куям яки үземә үзем сөйлим. Әкиятнең иң мөһим вакыйгасы — Кәҗә белән Сарыкның бүреләрне җиңүе. Кыскартып сөйләсәм, болай була: Кәҗә белән Сарык көчсез, куркак, ләкин явыз, көчле өч-дүрт Бүрене җиңәләр.

б) Менә хәзер каршылык күренеп тора. Аз санлы көчсез як күп санлы көчле якны җиңәргә тиеш түгел иде. Ләкин җиңде.

в) «Кәҗә белән Сарык ничек җиңде?» — дип, үземнән үзем сорыйм.

Хәйлә белән җиңделәр. Аларның көчләре акылларында булып чыкты. Нәтиҗә ясыйм: **Кәҗә белән Сарык көчсез, куркак, ләкин шул ук вакытта алар акыл ягыннан бүреләрдән көчлерәк.**

Әкияттәге көлкеле урынның берсен таптым. Көчсез Кәҗә белән Сарык көчле булып чыктылар.



?! Рәсемнәрне карагыз һәм хикәя итеп языгыз. Язарга керешкәнче, ике өлештән торган план төзегез.

ЯШЬ ОСТА.

Уңган да соң бу Якуб,
Булган да соң бу Якуб,
Йомыш кушып торасы юк,
Йокысыннан уятып.

Үзе тора таң белән,
Битен юа кар белән.
«Эшләмәгән эше юк»,— дип
Сөйләмәгән кеше юк.
Самолёт та ясады,
Пароход та ясады,
Хәзер инде ракетага
Таяк юна башлады.
Ышкы ала —
ышкып ала,
Чүкеч ала —
чүкеп ала,
Бәрә-суга —
килә-чыга
Сыерчыклар оясы,—
Карап кына торасы!
Сап ясый ул балтасына,
Тамга сыза тактасына,
Бәрә-суга —
килә-чыга
Менә дигән урындык,—
Карап кына торырлык.
Абыйлар да мактыйлар,
Апалар да мактыйлар,
Якуб сүзе хак, диләр,
Һөнәр белер чак, диләр.

Гамил Афзал.

?!

1. Сез Якуб кебек булырга теләр идегезме?
2. Шигырьдән автор көлүен табыгыз.

ЮРИСҮРИЧҮП.

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер җан иясе.

Кошларга да, җәнлек-җанварларга да охшамаган ул. Җирдә дә йөрмәгән, суда да йөзмәгән, күктә дә очмаган. Елан кебек тә шуышмаган, ятмаган да, тормаган да, утырмаган да — бары тик яшәгән генә.

Аның хәтта исеме дә булмаган. Шуңа күрә мин аңа үзем исем куштым. Юрисүричүп дип.

Менә шундый исем: Юрисүричүп...

Әгәр берәрегез кайда да булса, кайчан да булса менә шул Юрисүричүпне очратса әйтерсез әле, яме?

Кызык, нindирәк җан иясе икән ул Юрисүричүп?

Ләбиб Лерон.

?! Автор көлүен табыгыз.

ТАГЫН БЕР «РӘХМӘТ»...

Кемгә яхшылык эшләгән,
Ярдәм иткән нихәтле —
Сәлимнең барсы санаулы,
Бөтенесе исәпле:

— Ике әби, бер бабайга
Трамвайда урын бирдем.
Ике әби һәм бер бабай
Һәркайсы: «Рәхмәт!» — диде.

Авылдан килгән өч апа
Адрес белмәгәч рәтләп,
Әйтеп бирдем. Менә сиңа
Булды янә өч «рәхмәт»!

Урам аркылы чыгардым
Тагын ике әбине.
Ике әби икесе дә
Ике кат: «Рәхмәт!» — диде.

Күршенең хәлен сораштым,
Безгә кичә кич кергәч.
«Исәнлеккә-саулыкка!» — дип
Әйттем, абзый төчкергәч...

— Тырышкансың, рәхмәт,— дидем...
Сәлимгә ярап куйды:
— Тагын бер рәхмәт булды! — дип,
Шунда ук санап куйды.

Шәукәт Галиев.

?! Автор Сәлимнән көлә. Ничек көлә?

НӘНИ ПРИНЦ.

Автор китабын Леон Верт исемле дустына багышлый. Менә ничек яза ул багышламасын:

«Китабымны өлкән яшьтәге кешегә багышлавым өчен, балалардан гафу үтенәм. Акланып, шуны әйтә алам: бу кеше — минем иң якын дустым. Дөньядагы бар нәрсәне, хәтта балалар өчен язылган китапларны да аңлый ул».

?! **1.** Багышламаны үз вакытында авторның дусты да укыган. «Хәтта балалар өчен язылган китапларны да аңлый» сүзләрен укып, һичшиксез, шатланган. Ни өчен шатланган? Автор аңардан көлгән бит?

Автор үзенең укучыларын да ярата. Алар белән дә көлеп сөйләшә:

«...ул Франциядә яши, ә анда хәзер тормыш бик авыр: көннәр суык, кешеләр ачлы-туклы. Шуңа күрә җылы сүзгә бик мохтаҗ ул. Әгәр инде шушы акланулар гына җитми икән, мин бу китапны дустымның бала чагына багышлыйм. Олы яшьтәге кешеләр дә кайчандыр бәләкәй булганнар бит, тик күбесе моны оныткан гына. Шулай итеп, сүзләремне төзәтәм дә болай дип язам: «Леон Вертка, аның бәләкәй чагына багышлыйм».

?! **2.** Багышлама — яраткан кешегә иң зур бүләк. Автор дустына бүләк биргәнме, юкмы?

Алты яшьлек чагымда «Булган хәлләр» исемле китапта кеше аягы басмаган карурманнар турында укыган идем. Шунда гаҗәеп бер рәсем дә күрдем. Рәсемдә иләмсез зур буар елан ниндидер ерткыч җәнлекне йотып маташа.

Китапта болай дип язылган иде: «Елан үзенең корбанын чәйнәми-нитми бөтен килеш йота. Аннан соң ул, кымшана да алмыйча, ярты ел буе азыгын сеңдереп ята».

Джунгли маҗаралары турында озак кына уйлап йөргәннән соң, төсле карандаш белән үземнең беренче рәсемемне ясарга булдым. Бу, чыннан да, минем иң беренче рәсемем иде. Менә нәрсә ясадым мин:



Рәсемемне тизрәк олыларга күрсәтеп:

— Куркынычмы? — дип сорадым.

— Эшләпәнең нәрсәсе куркыныч булсын?! — диделәр алар.

Ул бөтенләй эшләпә түгел, ә фил йоткан елан рәсеме иде. Шуннан соң мин, зурларга аңлаешлырак булсын өчен, еланның эчке кыяфәтен ясарга булдым. Олыларга барысын да тәфсилләп аңлатырга кирәк бит. Менә минем икенче рәсемем:



Зурлар миңа еланны тышкы ягыннан да, эчке ягыннан да ясап мәшәкатьләнмәскә, күбрәк география, тарих, арифметика һәм матур язу белән шөгыльләнергә куштылар. Шулай итеп, мин алты яшьтә үк рәссам булу хыялыннан ваз кичәргә мәҗбүр булдым. Уңышсыз чыккан бу ике рәсемнән соң мин үземә ышанмый башладым. Олылар беркайчан да бернәрсәне дә үзләре аңламыйлар бит. Ә аларга барысын да туктаусыз аңлатып, төшендереп тору балаларны бик ялыктыра.

?! **3.** Бу өзектә автор кинәт балага әйләнә дә зурларны наданлыкта гаепли. Хаклы гаеплиме?

4. Автор кемнән көлә? Зурларданмы? Үзеннәнме? Үзенең кечкенә чагыннанмы?

Шулай итеп, миңа башка һөнәр сайларга туры килде: мин очучы булдым. Самолётым белән дөньяны

аркылыга да, буйга да иңләп чыктым һәм, дөресен әйтергә кирәк, географиянең бик тә файдасы тиде. Мин бер күрүдә үк Кытайны Аризонадан[1] аера ала идем. Төнлә юлдан язганда, бу бик тә кирәк була.

Үз гомеремдә мин төрле кешеләр белән очраштым. Озак вакытлар олылар арасында яшәдем. Алар белән якыннан таныш идем. Ләкин, моңа карап, алар турындагы фикерем һич тә яхшырмады.

Акыллырак күренгән кеше очратсам, мин аңа һәрвакыт үзем белән йөрткән беренче рәсемемне күрсәтә идем. Бу кешенең, чыннан да, берәр нәрсә аңларга сәләтлеме икәнен бик тә беләсем килә иде. Ләкин алар барысы да: «Бу бит эшләпә»,— дип җавап бирәләр иде. Шуннан соң инде мин алар белән еланнар, джунглилар, йолдызлар турында сөйләшми идем. Аларча ук уйлый, фикер йөртә идем. Сәясәт һәм галстуклар турында сөйләшә идек... Олылар шундый акыллы кеше белән танышуларына бик тә канәгать булалар иде.

?! **5.** Автор бу өзектә дә үзеннән көлә. Ничек көлә?

Чын күңелдән сөйләшергә кеше таба алмыйча, шулай ялгыз гына яшәдем. Һәм менә моннан алты ел элек мин Сахара чүленә төшеп утырырга мәҗбүр булдым. Самолётымның моторында нәрсәдер ватылган иде. Янымда механик та, пассажирлар да юк, шуңа күрә бик авырга килсә дә, самолётны үзем төзәтеп карарга булдым. Мин йә моторны төзәтергә, яисә чүлдә һәлак булырга тиеш идем.

---

[1] Аризона — Америкадагы бер штат.

Беренче кичне ачык һавада йокларга яттым. Тирә-юньдә — меңәр чакрымга сузылган ком чүле. Диңгездә һәлакәткә очрап, бер бүрәнә кисәгенә тотынып калган кеше дә үзен бу кадәрле ялгыз хис итмидер. Таң атканда, кемнеңдер нечкә тавышын ишетеп уянып киткәч, ничек гаҗәпләнүемне күз алдына китерсәгез иде. Ул:

— Зинһар өчен... миңа бәрән рәсеме яса әле! — диде.

— Ә?..

— Бәрән рәсеме яса әле...

Баш очымда күк күкрәгәндәй сикереп тордым. Күзләремне угаладым. Як-ягыма карандым. Шулчак бик җитди итеп миңа карап торучы кечкенә гәүдәле, гаҗәеп кызык бер кеше күрдем... Соңыннан мин аның сурәтен дә ясарга тырышкан идем. Менә монысы — иң яхшысы.

Билгеле, ул үзе мин ясаган сурәткә караганда матуррак иде. Эчке ягыннан ясалган еланны санамаганда, бернәрсә ясарга да өйрәнә алмадым шул мин.

Күземне шар ачып, гадәти булмаган бу хәлне тамаша кыла башладым. Бу малай адашканга, арыганга, курыкканга яисә ачлыктан һәм сусаудан тилмергәнгә һич тә охшамый. Ниһаять, телем ачылып, мин аннан:

— Син монда нишлисең? — дип сорадым. Ләкин ул, әкрен һәм җитди итеп, үзенең соравын кабатлады:

— Зинһар өчен... бәрән рәсеме яса...

Бу шулкадәр серле булып тоелды, мин аңа каршы сүз дә әйтә алмадым. Һәр адымыңны үлем сагалап торган очсыз-кырыйсыз чүл уртасында рәсем ясап утыру никадәр генә мәгънәсез булып күренсә дә, мин кесәдән бер бит кәгазь белән каләм алырга мәҗбүр булдым. Ләкин аңа күбрәк география, тарих, арифметика, матур язу белән шөгыльләнүемне әйттем (хәтта тавышымны бераз күтәрә төшеп әйттем) һәм рәсем ясый белмәвемне аңлаттым. Ә ул:

— Барыбер... Бәрән рәсеме яса,— дип кабатлады. Гомеремдә бер генә мәртәбә дә бәрән рәсеме ясаганым булмавын әйтеп, мин аңа үземнең иске рәсемнәремнең берсен — тышкы яктан ясалган еланны күрсәттем. Ә ул:

— Юк, юк. Миңа елан эчендәге фил кирәкми! Елан бик куркыныч, ә фил артык зур. Минем өйдә бөтен нәрсә дә бик кечкенә. Миңа бәрән кирәк. Бәрән рәсеме яса,— дигәч, мин гаҗәпләнеп калдым.

Аннан ясадым.

Рәсемгә игътибар белән карап торганнан соң, ул:

— Юк, бу бәрән бигрәк хәлсез. Башканы яса,— диде. Мин тагын ясадым. Дустым бу юлы елмаеп куйды.

— Бәрән түгел бит бу. Тәкә. Әнә мөгезләре тырпаеп тора...

Мин тагын бер бәрән ясадым.

Ләкин ул бу рәсемнән дә баш тартты.

— Монысы бигрәк карт. Миңа озак яши торган, яшь бәрән кирәк,— диде.

Шуннан соң бөтен түземлегемне югалтып — миңа тизрәк моторны сүтәргә кирәк иде — кәгазьгә аннан-моннан бер тартма сызгалап куйдым да:

— Менә сиңа тартма. Аның эчендә синең бәрәнең утыра,— дидем.



Гаҗәпкә каршы, минем таләпчән хакимемнең йөзе яктырып китте:

— Менә монысы шәп! Син ничек уйлыйсың, бу бәрәнгә печән күп кирәк булыр микән?

— Нигә?

— Минем өемдә бар нәрсә дә аз-маз гына...

— Аңа күп кирәкми. Мин сиңа бик кечкенә бәрән бирәм.

— Алай ук кечкенә түгел инде...— диде ул, башын бер якка кыйшайтып карый-карый.— Карале, кара! Йокыга китте.

Нәни принц белән мин шулай таныштым.

?! 6. Бу өзектә автор Нәни принц турында яза. Нәни принц — кеше дә, шул ук вакытта түгел дә. Аның яши торган планетасы бар да, юк та. Сарык бәрәне дә Нәни принц өчен бар, ләкин шул ук вакытта юк та. Ни өчен бар да, юк та?

Баштарак мин аның каян килгәнен аңлый алмадым. Нәни принц сорау артыннан сорауны яудырып кына тора, ә мин берәр нәрсә белергә теләп сүз катсам, ишетмәмешкә салыша. Ләкин очраклы гына әйтелгән сүзләрдән эшнең нәрсәдә икәнен тора-бара аңлый башладым. Беренче тапкыр самолётка күзе төшкәч (самолётны ясап маташмыйм, чөнки барыбер булдыра алмыйм), ул болай дип сорады:

— Бу ни?

— Бу «ни» түгел, самолёт. Минем очкычым. Ул оча ала.

Мин, горурланып, үземнең оча белүем турында сөйләргә тотындым. Шуннан соң ул, гаҗәпләнеп:

— Алайса, син дә күктән төшкәнсең. Ә кайсы планетадан? — дип сорады.

Мин эчемнән генә: «Сахарага килеп чыгуының сере менә нәрсәдә икән!» — дип уйлап куйдым һәм турыдан-туры:

— Димәк, син монда чит планетадан килгәнсең? Кайдан килдең соң син, бала? Өең кайда? Минем бәрәнне кая алып китмәкче буласың? — дип сорадым.

Ул сүзсез генә бераз уйланып торды да:

— Миңа тартма биреп бик яхшы иттең, төннәрен бәрән шунда йоклар,— диде.

— Билгеле. Акыллы булсаң, көндезләрен бәйләп куяр өчен, бау да, казык та бирермен.

Нәни принцның йөзе караңгыланып китте:

— Бәйләп куярга? Ә ни өчен?

— Бәйләп куймасаң, ул әллә кайларга китеп барыр да адашыр.

Минем дустым яңгыратып көлеп куйды:

— Кая китсен ди ул?

— Аягы кая атласа — шунда.

Нәни принц, җитди итеп:

— Минем планетада бик кысан,— диде.

Аннан соң, моңсуланып:

— Гел турыга гына барсаң, ерак китә алмассың...— дип өстәде.

* * *

Шулай итеп, мин тагын бер зур ачыш ясадым: ул яшәгән планета бары йорт зурлыгында гына икән...

Мин, бик теләп, бу повестьны тылсымлы әкияткә охшатып язар идем. Менә болай итеп башлар идем: «Борын-борын заманда булган, ди, бер Нәни принц. Ул үз гәүдәсеннән аз гына зуррак планетада яшәгән, бу принцның кем беләндер бик тә дуслашасы килгән...» Тормышны аңлаган кешеләр моның чып-чын икәнен шунда ук күрерләр иде.

Чөнки мин бу китабымны кызык өчен генә укуларын һич тә теләмим. Нәни дустымны искә төшерүгә, йөрәгем авыртып кысылып куя. Аның турында сөйләү бик авыр миңа. Бәрәнен алып, мине ташлап китүенә менә алты ел узды инде. Мин сезгә аның турында күңелемдә онытылмаслык истәлек калсын өчен сөйлим. Дусларны оныту — бик күңелсез хәл

бит. Бар кешенең дә дусты булмый. Саннардан башка берни белән дә кызыксынмый торган кешеләргә охшап калудан куркам мин.

Менә шуңа күрә дә бер тартма буяу белән төсле карандашлар алып куйдым. Шушы яшькә җиткәч, бөтен гомере буена еланны эчке һәм тышкы яктан ясаудан башка эш кырмаган кешегә — әле анысы да алты яшьтә бит! — рәсем ясарга тотыну җиңел нәрсә түгел. Билгеле, мин булдыра алган кадәр охшатыбрак ясармын. Ләкин бу эшне ерып чыгуыма ышанмыйм.

Гаепкә алмассыз инде. Дустым бит миңа бернәрсәне дә аңлатып тормый иде. Бәлки, ул мине дә үзе кебек үк дип уйлагандыр. Тик, кызганыч, тартма эчендәге бәрәнне күрә алмыйм мин. Бәлки, мин бераз олыларга охшаганмындыр. Ахрысы, картаям бугай.

Антуан де Сент-Экзюпери.
(Разил Вәлиев тәрҗемәсе.)

Автор бу әсәрендә бик кечкенә кеше белән зур дуслык урнашуы турында яза. Шундый зур дуслык тусын өчен, җитди сәбәп кирәк. Җитди сәбәп — аларның бер-берсенә охшавында.

Нәни принц — саф күңелле, беркатлы, үз көнен үзе күреп яшәүче бала. Хыялый бала түгел, үзе — бөтен барлыгы белән хыял ул. Автор да — һаман балачактагы уйларыннан аерылмаган, хыял дөньясында яшәүче кеше. Ул да, самолёты ватылып, бик кыен хәлдә калуына карамастан, Нәни принцны кызганып, аңа ярдәм итә. Аны яратырга өлгерә һәм сагына. Гомере буе, Нәни принц кебек, тартма эчендәге юк

бәрәнне күрә алмавына үкенә. Ә бит кечкенә чагында ул да — эшләпәне елан итеп, елан эчендә фил күрә торган кеше.

Зурлар, чыннан да, тартма эчендәге бәрәнне дә, эшләпәнең фил йоткан елан булуын да күз алдына китерә алмыйлар. Һәм бу — аларның бәхетсезлеге. Балаларның бәхете — юкны да бар итеп күз алдына китереп шатлана алуларында.

Автор шул хакта елмаеп-көлеп яза. Ләкин аның елмаюында борчылу да, моңаю да, үкенү дә бар. Ә иң әһәмиятлесе, без автор көлүе эчендә яп-якты балкыш — мәхәббәт балкышы күреп, аның матурлыгына сокланып туя алмыйбыз. Матурлыкны ярата белүчеләр, авторга ияреп, үзләре дә елмаячаклар, ә күзләреннән яшь тамар. Нигә шулай булмасын, без барыбыз да Нәни принцка шактый охшаган бит!

Нәни принц яши торган планетаны күз алдына китерегез. «Анда вулкан да бар, бер генә роза чәчәге дә үсә, баобаб исемле чүп агачы да бар»,— ди Нәни принц. Планета хуҗасының үзен дә бастырып, шул планетаның рәсемен ясагыз.

ТАБИГАТЬ ХАКЛЫ.

Бер укучы бала каникул вакытында авылда ял иткән. Беркөнне, бакчага кереп, алмагач төбенә яткан. Кошлар сайравын тыңлый-тыңлый йокыга баткан.

— Бу табигатьне һич аңлап булмый. Кеп-кечкенә алма биек агачта үсә, ә зур кабак, нечкә, зәгыйфь ботакка ябышып, җирдә үсә. Ә бит киресенчә булырга тиеш иде,— дигән.

Шулай дип уйлап бетерүе булган, бер алма өзелгән дә — шап моның борынына!

— Аңладым, ниһаять, аңладым. Табигатьне аңлап була икән. Алма урынына биек агачта кабак үскән булса, хәзер мин аягымда басып тора алыр идеммени?

?!

1. Әсәр малайның уе турында. Аның уен ике өлешкә бүлегез. Өлешләр арасында каршылык булсын.

2. Малайга үз бәягезне әйтегез. Нинди малай ул?

ҖӘЙ МАТУРЛЫГЫ.

(«Хуҗа Насретдин кызының угылы» хикәясеннән өзек.)

Менә бервакыт җәй җитте. Урамнарда нәфис тузаннар күтәрелде. Кырларда хуш исле кычытканнар өлгереп, зифа буйлы тигәнәкләр үзләренең йомшак җимешләрен үстереп җиткерделәр. Гүзәл каргалар, үзләренең колакка гаҗәеп ягымлы тавышларын төрле-төрле көйләргә салып, адәмнәрне кәефләндерергә керештеләр. Сандугач шикелле матур, ләкин аңар караганда гәүдәләре бераз кечерәк озынборыннар очраган бер кешегә, шәфкать вә мәрхәмәтле тавыш белән:

— Энеммм,— дип, сәлам биреп, инә шикелле борыннары аркылы игътибар вә илтифатларын[1] күрсәтеп йөри башладылар. Кипшенә башлаган сазлыклардан яхшы исләр күтәрелде. Гүзәл кыяфәтле матур бакалар, чыгып, яшелле-зәңгәрле тавышлар белән концертлар бирә башладылар. Зур корсаклы,

---

[1] Илтифат — ягымлылык.

симез гәүдәле юан агай-энеләр тирләп, хуш исләр чәчеп йөрергә тотындылар...

Елның шушындый матур көннәре килеп җиткәч, без Гөлчәһрә белән кырларда, урманнарда сәер итеп[1] керергә уйладык, уйлап кына да калмадык, сәер итәргә чыгып ук киттек.

Фатих Әмирхан.

?! **1.** Автор безнең белән шаярып-көлеп сөйләшкән урыннарны табыгыз.

2. Үзегезне әсәрдәге герой дип күз алдына китерегез. Менә сез җәйнең шундый матур бер көнендә Гөлчәһрә белән кырларда, урманнарда табигать матурлыгын күрергә чыгып киттегез... (Вакыйганы дәвам итегез.)

Ятлау өчен.

Ык.

Авыл җирендә туган һәр кешенең күңеленә газиз булган елгасы, күле яисә чишмәсе бар. Яр буйлары челтерәп ага торган чишмәләр белән тулган, күңелләрне моңга сала торган сихри сагындыру көче, матурлыгы һәм гүзәллеге белән җырларга кергән елгаларыбызның берсе — Ык.

«Ык буйлары» дип исемләнгән җыр юллары бу елганы менә ничек итеп тасвирлый:

Бик сагындым Ык буйларын,
Ашыгып аккан суларын;
Ык сулары басар төсле
Йөрәгем ярсуларын.

---

[1] Сәер итеп — карап, тамаша итеп.

Елгалар, алар ярындагы чишмәләр, куаклыклар, ул куаклыклардагы кошлар — безнең бөтен барлыгыбыз, безне кеше итә торган, күңелләребезгә миһербан һәм шәфкать сала торган чынбарлык, туган як чынбарлыгы.

Ямьле Ык буйларында яшәгән халык үз авылларына, анда көн иткән ата-бабаларына тирән хөрмәт белән караган, намуслы, дөрес күңелле булган.

Фирдәүс Гарипова.

БУРАН.

Ак аю кебек болытлар
Томалый авыл күген.
Бөтерелә тышта өермә,
Котырына буран бүген.

Өркетмә карың белән, кыш,
Лыгырдык җилең белән:
Күземне йомдым исә мин
Каршымда язны күрәм.

Хәсән Туфан.

КОЯШ КЕБЕК.

Тышта суык,
Яңгыр ява.
Бабай әйтә:
«Начар һава».

Күктә ай да,
Йолдыз да юк.
Барыбызның
Күңел боек.

Сеңлем дә
Йөзен чытты.
Шулчак кинәт
Кояш чыкты.

Әниебез
Кайтты, кәлеп.
Аның йөзе
Кояш кебек.

Разил Вәлиев.

Эчтәлек

Иң югары сыйныф. 3

Беренче—өченче сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерик.

Ярты ат. *Эрих Распе* 8
Ядрәгә атланып. *Эрих Распе* 10
Гадәт. *Фәнис Яруллин* 12

Хис темасын искә төшерик.

Халык җырлары 13
Мәктәптән кайтып киләм. *Фәнис Яруллин* 14

Әсәрне катнашучыларга бүлик.

Юлдашым. *Мөдәррис Әгъләмов* 16
Ул дулкыннар. *Сибгат Хәким* 17
Кем яхшы? *(Мәзәк.)* 17
Баланың ата-анасын сөюе. *Габдулла Тукай* 18
Илгә сәлам. *Хәсән Туфан* 18
Көнгә күренмәс Сылу-Көмеш. *(Әкият.)* 19
Эш беткәч уйнарга ярый. *Габдулла Тукай* 26
Ике сабан. *Габдулла Тукай* 30
Идел суы китте кебек. *Фәннур Сафин* 31
Көнчел җил. *Фәннур Сафин* 31
Мосафирлар һәм этләр. *Габдулла Тукай* 32

Төп герой.

Чыпчыклар һәм Кызылтүш. *Габдулла Тукай* 34

Автор.

Күренми. *(Мәзәк.)* 36

Таныш исем. *(Мәзәк.)* 36
Чулпан йолдыз. *Нәби Дәүли* 36
Хәйләнең файдасы. *Шәукәт Галиев* 37
Марат белән Миңнури. *Әминә Бикчәнтәева* 38
Бүленгән өлешләргә исем бирик.
Чәлән белән Сандугач. *(Әкият.)* 42
Кар бөртекләре. *Фәнис Яруллин* 44
Велосипедлы Мөнир. *Нурихан Фәттах* 45
Сертотмас Үрдәк. *Абдулла Алиш* 48
Әллә каян күренеп тора. *Виктор Голявкиннан* 54
«Куркак» батыр. *Вахит Монасыйпов* 57

Автор теләгән табарга өйрәник.

Өйдә юк. *Зәки Нури* 64
Карамарыдагы ишәк. *Элинор Фарджон* 65
Сеңлем ак каен. *Хәсән Туфан* 78
Балыкчы һәм Балык турында әкият. *Александр Пушкин. Әхмәт Исхак тәрҗемәсе.* 79
Мәкальләр. 87
Моңсу бәйрәм. *Резеда Вәлиева* 88
Балта ничек үзенә сап ясаган? *Әхмәт Исхак* 89
Өч сорау. *(Татар халык әкияте.)* 92
Батыр белән малай. *(Кытай халык әкияте.)* 94
Надан. *Шамил Бикчурин* 96
Акыллы кыз. *(Татар халык әкияте.)* 105
Бер хаклык һәм йөз ялган турында. *Хәкимҗан Халиков* 110
Кем эшләми... *(Серб халкы әкияте.)* 112

Автор кәлүе.

Әкият башы. *Мөдәррис Әгъләмов* 117
Башмак. *(Татар халык әкияте.)* 117
Көлке ничек туган?
Җир яралу 122
Җил иясе 123
Тургай һәм Кояш 124

Көлке ничек халык авыз иҗатына килеп кергән?

Карт белән карчык. *(Балалар иҗаты.)* 127
Мәзәкләр. 128

Әдәби әсәрләрдәге көлке.

Менә нинди икән яз. *Нурия Измайлова* 129
Кышка бер сүз. *Габдулла Тукай* 130
Мактанырга яратмый. *Роберт Миңнуллин* 131
Качышлы уйнаганда. *Шәүкәт Галиев* 133
Әтәч илә энҗе бөртеге. *Габдулла Тукай* 133
Көзге һәм Маймыл. *Габдулла Тукай* 133
Кәҗә белән Сарык хикәясе. *Габдулла Тукай* 134
Яшь оста. *Гамил Афзал* 140
Юрисүричүп. *Ләбиб Лерон* 142
Тагын бер «рәхмәт»... *Шәүкәт Галиев* 142
Нәни принц. *Антуан де Сент-Экзюпери (Разил Вәлиев тәрҗемәсе.)* 143
Табигать хаклы. *(Мәсәл.)* 153
Җәй матурлыгы. *Фатих Әмирхан* 154

Ятлау өчен.

Ык. *Фирдәүс Гарипова* 155
Буран. *Хәсән Туфан* 156
Кояш кебек. *Разил Вәлиев* 156

Учебное издание

Яхин Альберт Гатуфович (Гатинович)

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 4 класса начальной
общеобразовательной школы с татарским языком обучения

В двух частях

Часть первая

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатуф улы

ӘДӘБИЯТ

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
4 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

Беренче кисәк

Мөхәррире *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Компьютерда биткә салучысы *Г. Р. Галимҗанова*
Корректорлары *Г. Г. Мөхәммәтҗанова, Т. Н. Сәгъдуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.02.2011.
Форматы 70x90 1/16. Шартлы басма табагы 11,7 + форз.0,29.
Тиражы 3700 д. Заказ Р-611.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 519-45-22.
http: //tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

9 785298 020466